* Күләме: 36б-163а. 36а биттә кәтиб имзасы:
لعبد الجمیل بن عبدالمنان الصلیعوشی («Габделҗәмил бине Габделмәннан әс-Салагыши өчен»).
Колофон 163а биттә урнашкан:



*Рис. 30.* Имя заказчика в рукописи. НМ РТ 18369-21, л. 36а



*Рис. 31.* Колофон рукописи. НМ РТ 18369-21, л. 163а



تمت هذه النسخة الشریفة الدقیقة المسماة بقاضی مبارک ..... در مدرسهء ملا نظام الدین ابن ملا سلیم جان فی ید العبد الضعیف الراجی الی رحمة الباری.... ۱۸۵۱ نچی ده

Иске исемлек буенча – № 17.

**29** (57)

کتاب تحفة الملوک

**«Китабе төхфәтел мөлүк»**
Фикъһел ислам, гарәп телендә. Габделҗәмил Габделмәннан углы, Тирсәдә язылган. Каләме уртача, имлясы дөрес.
*16,5×21. Күләме: 1б–52б. Ярым күн тышлык. Каплавычлары кульязмалардан ясалган. XIX гасыр уртасындагы кәгазь, язу рәвеше нәсех, кара һәм кызыл каралар, гарәп һәм европадагы пагинация, кустодлар бар.
52б биттә өстәмә бар: 1866 نچی یلده
Иске фиһрист буенча – № 28.

**30** (57)

بخار زاده

**«Бохар задә»**
20 сәхифәлек. Фикъһел ислам вә әдәп. Гарәп телендә. Габделҗәмил Габделмәннан углы 1849 елда Тирсәдә язган.
* Колофон 62б биттә:

اتمت اتمام 1849 نچی سنه ده حمل ننک 23 نچی یومنده فی وقت العصر و فی ولایت ترسه و فی مدرسهء داملا یعقوب بن نعمة الله ده توردوقم زمانده یازوب تمام قیلدوم بن الضعیف عبد الجمیل عبد المنان

Иске фиһрист буенча – № 29



*Рис. 32.* Колофон рукописи. НМ РТ 18369-57, л. 62б

**31** (57)

یک حکایت. منظومة تاریخ سیرة

**«Йәк хикәят. Мәнзумә тарих сира»**
8 сәхифәлек. 63а-66б битләр. Мөхәммәд галәйһис сәламнең тарих вафаты. Фарсы телендә. Габделҗәмил Габделмәннан углы язган. Иске фиһрист буенча – №30.

**32** (57)

عبد الجمیل عبد المنان اوغلی مقصود. تفسیر سورهء القدر

**Габделҗәмил Габделмәннан углы Максуд.**
**«Тәфсир сүрәи Кадер»**
10 сәхифәлек. Коръән тәфсире. Төрки телдә. Габделҗәмил Габделмәннан углы язган 1866 миладида. Казый Бәйдави һәм Ягъкуб Чәрхи тәфсирләреннән, «Мәҗалисеш шөһүр» һәм «Тәнбиһел гафилин» китапларыннан файдаланып, төрки телдә, һәркем аңларлык ачык итеп язган.



* Өстәмә язмасы 1б биттә:

صاحبه و مالکه و کاتبه عبد الجمیل بن عبد المنان

«Моның язучысы һәм иясе – Габделҗәмил бине Габделмәннан». Факсимиле III карагыз.

**33** (15)

علی بک بن عثمان الاوشی. قصیدة الامالی منظومة

**Галибек бине Госман әл-Уши. «Касыйдәтел Әмали мәнзумә»**
Һиҗри 1160, милади 1750 елда. Габдеррәхман әл-Фәрит исемле кеше тәрҗемә, шәрех иткән. 10 сәхифәлек. Игътикадел ислам, гарәп-төрки. Габделҗәмил Габделмәннан углы язган, ләкин тәмам түгел.
* 17,2×21. 6 бит.
Тышсыз, аннотация 1а битендә ябыштырылган. Бит саннары соңыннан куелган, кустодлар очрый, төрек телендә. Әүвәлге төрки шигырьләрдә тәрҗемәче Габдеррәхман әл-Газиз исемле кеше турында берничә сүз язылган (2а–3а битләр).
Урыс кәгазе XIX гасырның икенче яртысына карый. Кульязма тулы. Язу рәвеше – татарча тәгъликъ. Кара каралар белән язылган. Иске фиһрист буенча – № 44.

**34** (34)

امام ابو حامد الغزالی. مشکاة الانوار فی لطائف الاطبار

**Имам Әбу Хәмид әл-Газали.**
**«Мишкател әнвар фи ләтаифел әтбар»**
1292 сәхифә, мәүгазә вә әхлак гыйльме. Гарәп телендә. Габделҗәмил Максудов бине Габделмәннан язган. Азагында углы Мөхәммәдшакирның 1888 елда туганы теркәлгән.
*17,5×21. 426 бит. Кәгазе XIX гасыр ахырына карый (фабрика Сергеева № 6 штемпельләре), бит саннары оригиналда бар һәм музейда өстәлгән, кустодлар бар. Кара төстәге каралар, тәгъликъ язуы. Һәр биттә 17 юл. Текстның зурлыгы 15,5×9.



*Рис. 33.* Содержание рукописи и список упомянутых имен. НМ РТ 18369-34, л. 5а

Соңгы сәхифә төшкән. Ахыргы биттә Зәйнәпнең кулы белән язылган өстәмә язмасы бар: لعبد الجميل بن عبدالمنان الصليعوشى («Мулла Җәлаледдин әд-Дәввани»).
Карагыз: GAL, I, 423.
Иске фиһрист буенча – № 22.



**35** (80)

## كتاب عقود المنظومة

**«Китаб гокудел мәнзумә»**
236 сәхифә. Фикъһел ислам вә әдәп, гарәп телендә. Габделҗәмил Габделмәннан углы 1850 елда язган. Азагында угыллары Габделгазиз һәм Габдеррәхманның туган еллары теркәлгән.
* 16×21. 115 бит. Тышлыгы юк.
Иясенең язмасы 1а биттә:

عبد الجميل بن عبد المنان بن نعمة الله بن يعقوب بن عبدالله لن عبد الرحمن بن عبد لرحيم

Автор күрсәтелмәгән, гарәп телендә, кәгазь XIX гасырның беренче яртысына тартым (су билгеләре юк), кара каралар, төп нөсхәсе һәм кулъязманың бит саннары музейда, кустодлар, китап нык, калын җеп белән тегелгән, язу рәвеше тәгъликъ.
Колофон 115а биттә:

كاتبه و مالكه و صاحبه عبد الجميل بن عبد المنان عفر الله ذنوبهم و على سائر المؤمنين امين 1850 سنه ده عنوارننک 18 كوننده

«Моның язучысы һәм иясе – Габделҗәмил бине Габделмәннан, Аллаһы Тәгалә алар һәм башка мөселманнар кылган гөнаһларны кичерсә иде. Амин. 1850 сәнәдә гыйнварның 18нче көнендә».
Өстәмә язма 115б биттә:

1867 نچى يلنده حمل ننک 28 نچى كوننده اوغلوم عبد العزيز وجوده كلدى بقدرة الله تعالى اطال الله تعالى عمره العزيز بالبر و التقوى ماه ذى الحجة ننک اوچونچى كوننده

1881 نچى يلنده سنتبر ننک 15 نچى كوننده اوغلوم عبد الرحمن وجوده كلدى حق تبارك و تعالى توفيق لى هدايتلى اوزون عمر ويرسه ايدى آمين. بحرمت طه و يس ماه ذوالقعده ننک اوننچى كوننده



*Рис. 34.* Колофон рукописи. НМ РТ 18369-80, л. 115а

«1867 елында хәмәлнең 28 нче көнендә улым Габделгазиз вөҗүд-кә килде, Аллаһының кодрәте белән. Аллаһы Тәгалә озын гомер бирсен! Зөлхиҗҗә аенең өченче көнендә.





*Рис. 35.* Колофон рукописи. НМ РТ 18369-80, л. 115а

1881 елында сентябрьнең 15 нче көнендә улым Габдеррәхман вөҗүдкә килде. Хак Тәбарәкә вә Тәгалә тәуфыйклы, һидаятле, озын гомер бирсә иде. Амин. Таһа вә Ясин хөрмәте белән. Зөлкагъдәнең 10 нчы көнендә».
Иске фиһрист буенча – № 9.

---

**36** **(14)**

محمد بن پیر علی (پیر گلی) شارحی – شیخ علی الصدر القونوی
کتاب وصایای پیر علی نک تورکی تلنده گی شرحی

**Мөхәммәд Пиркули шәрихе шәех Гали әс-Садр әл-Көньяви. «Китабе васийайи Пир Галинең төрки телдә шәрхе»**
86 кәгазь, 168 сәхифә. Фикъһел ислам, төрки телдә. Күчереп язучының исеме күрсәтелмәгән. Китапның һамишендә бик күп китаплардан, шул җөмләдән «Нәһҗел-фәрәдис»тән (33 нче кәгазьдә) күчермәләр бар. Кәгазьнең су билгесе XVIII йөзне күрсәтә.

*16,4×21,5. Катыргы тышлык. 1б биттә китапта кулланылган әсәрләр исемлеге китерелә. Яшькелт төстәге кәгазь, XVIII гасыр ахыры (су билгеләре буенча).
Аңлатманың авторы – шәех Гали әс-Сәлләй әл-Мәгънәви (7а биттә).
Колофон 86б биттә:

تم تصنيفه بعون الله تعالى لطيف الله تعالى ننک لطفى واعانتى و
احسانيله بو كتابننک تصنيفى تمام اولدى تقريبا تحمينا طوقوز يوز
يتمش سنه سنده تم الشرح فى سنة اربع و عشر مأية و الف. الله ولى ا
و هو خير المعين...

---

**37** (50)

ابو عبد الله السنوسى الحسينى . شرح عقيدة السنوسية

**Әбу Габдулла әс-Синүси әл-Хөсәйни.**
**«Шәрхе гакыйдатес синусия»**
34 сәхифә. Гакаидел ислам, гарәп телендә. Язучы – Мөхәммәдәмин бине Сәйфулла бине Габделхәмид бине Динмөхәммәд бине Шыгай бине Мөхәммәд бине Акман бине Илкәй бине Дүләтҗан Хафиз бине Әйүб шәех бине Хуҗа шәех бине Юллык шәех әс-Сибави әл-Болгари. 1786/7 елда язган. Вафаты 1848 елда Каһирәдә. Буш кәгазьләрдә «Зәһрәтер рияз» китабыннан күчермәсе бар. Бу китап үземдә сакланырга тиеш. Бер кәгазь Исхак Күшеринең мелла Салих Кәфаригә «Шәрхе шәмсия» китабын сорап язган хаты бар.
* 16,4×21,3. 1а биттә Зәйнәпнең өстәмә язмасы: «Мөхәммәдәмин бине Сәйфулла Әбу Наср Курсавиның Бохарада укыган чакта ук кушылган дусты. З. Максудова».
Кәгазе – XVIII гасыр ахыры (су билгесе болан рәсеме белән, 1785).
4б биттә кыска язма: ملا حسن كتابى («Мулла Хәсән китабы»).
Карагыз: GAL, SII, 352.



**38** (50)

عبد الله بن محمد ابن عمر اين ابراهيم الملالى السلمتانى.
شرح عقيدة السنوسية

**Габдулла бине Мөхәммәд бине Гомәр бине Ибраһим әл-Мәлали әс-Сәләмтани.**
**«Шәрхе гакыйдатес синусия»**
34 сәхифә. Гакаидел ислам, гарәп телендә.
* 28а биттә: كاتبه و مالكه محمد امين بن سيف ال («Моның язучысы һәм иясе – Мөхәммәдәмин бине Сәйфулла»).
Бу кеше турында мәгълүмат Мәрҗани һәм Фәхреддин буенча 2б биттә бирелә.
Язу рәвеше тәгъликъ, кара һәм кызыл каралар.



*Рис. 36.* Аннотация к рукописи. НМ РТ 18369-50, л. 1а

**39** (50)

شرح تعریفات علی بن احمد

**Гали бине Әхмәд. «Шәрхе тәгърифәт»**
64 сәхифә. Истиләхате гыйльмия, гарәп телендә. 28б–64б битләр.

**40** (50)

تحفة المرید (شرح مقدمة التجوید)

**«Төхфәтел мөрид (шәрхе мөкаддимәте тәҗвид)»**
120 сәхифә. Фәне тәҗвидел Коръән, гарәп телендә.
Төрле бидгать турында әсәр, гарәп телендә.
* Җыентыкның 65б–127а битләрдә.
Колофон 127а биттә:

تم النسخة الشریفة المسمی بتحفة المرید فی ید الفقیر الی العنی
محمد امین بن سیف الله



*Рис. 37.* Биографические сведения о переписчике рукописи, собранные З. Максудовой
НМ РТ 18369-50, л. 2б–3а



**41** (50)

احمد بن عبدالقادر الرومی الحنفی. مجالس الابرار

**Әхмәд б. Габделкадыйр әр-Руми әл-Хәнәфи.**
**«Мәҗалисел әбрар»**
Күчермәләр. 12 сәхифә. Бидгатьләр хакында, гарәп телендә.
* Бу әсәр 128а–134а битләрендә.

**42**

نجم الدین عمر بن علی القزوینی المعروف بالکاتب
کتاب شمسیة متن مختصر فی قواعد المنطق

**Нәҗмеддин Гомәр бине Гали әл-Казвини,**
**әл-мәгъруф бил Кәтиб. «Китабе шәмсия.**
**Мәтен Мохтәсар фи кавагыйдел мантыйк»**
Насыйр Тусинең шәкерте иде. Хуҗа Шәмседдин өчен төзегән «Күррәи шәмсия» дип атаган. Гыйльме мантыйктан, тәсәүвәрат, гарәп телендә.
Мортаза бине Хәмзә әл-Җәбәли, 1802 милади, 1217 һиҗри. Бер кәгазьдә Габделхалик бине Әгъламнең мантыйк хакындагы нәзымы да теркәлгән. Буш кәгазьләрдә җырлары да бар. Бер җилддә тупланган.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**43** (115)

خواجه میر سید عیاث الدین محمد بن خواجه سید سلطان
کتاب میر سید شریف – حاشیة السید علی التصورات

**Хуҗа Мирсәед Гыяседдин Мөхәммәд бине Хуҗа Сәедсолтан.**
**«Китабе Мирсәед Шәриф – Хашияс Сәедгали әт-тәсәүвәрат»**
223 кәгазь, мантыйк.
*16×21,2. 118 бит. Яртылаш күн тышлыгы почмаклар белән. Су билгеләре – 1802 ел. Иясенең язмасы өске кулланыш каплавычында:

صاحب هذا الكتاب احمد صفا الضادور اوشبو بير (!) سيد كتابى
طشلاتدوم اون بش تين

«Бу китап иясе – Әхмәтсафа әз-Зәдур. Ошбу Мирсәед китабын тышлаттым унбиш тиен».
Шул ук җирдә Максудова кульязмада файдаланган әдәбият исемлеген күрсәтә. 01 биттә урысча өстәмә куелган: «Мантикской книга нзывайтъся мирьсаидъ и шамсия хашияси». Бу битнең тышында:

1872 سنه ده اوغوست طشلاتدوم 15 تين احمد صفا بن ملا ضادور 1295

«1872 елгы августта тышлаттым, унбиш тиен. Әхмәтсафа бине мулла Задур. 1295».
3а биттә кара түгәрәк мөһер сугылган, диаметры 2 см:
احمد صفا بن فتح الله («Әхмәтсафа бине Фәтхулла»).
Каты күгелҗем төстәге кәгазь XIX гасыр башы, язу рәвеше тәгъликъ, кара һәм кызыл каралар, бит номерлары гарәпчә һәм музейда яңадан куелган, кустодлар бар. Колофон 109а биттә:

تمت الكتابة الكتاب بطريق التعجيل و الاضطراب * بيد فقير من كان فى
قلبه نار الهوى* مرتضى بن حمزه الجبلى* الراجى* من رب الغنى*
فى وسط شعبان
بعد العشاء
1217

Өстәмә язма янәшәсендә:

مالك هذا الكتاب احمد صفا بن ملا فتح الله الضادورى

(«Бу китапның иясе – Әхмәтсафа бине мулла Фәтхулла әз-Задури»).
Шигырьләр төрки телдә, 110а битендә, колофон белән тәгәлләнә:

تمت كاتب هذه الابيات احمد صفا بن ملا فتح الله ضادورى 1872 سنه
ده 5 نجى نويابرده





*Рис. 38.* Колофон и владельческие отметки в рукописи. НМ РТ 18369-111, л. 109а

(«Бу шигырьләрне Әхмәтсафа бине мелла Фәтхуллаһ Задури 1872 елда, 5 ноябрьдә язды»).



*Рис. 39.* Стихи Фатхуллы Задури в рукописи. НМ РТ 18369-111, л. 110а

110–118 битләр – XIX гасыр ахыры – китапка соңрак кушылган. 117б биттә өстәмә язма: من جلال الدين سعد الدين اوغلی تورورمن («Мән Җәлаледдин Сәгъдәддин углы торырмын»).



Түбәндә каллиграфик нәсех белән:

قد تملك هذا الكتاب الشريف (!) ... احمد صفا بن الشيخ الشيوخ سلطان العارفين ... نقشبندی... دملا فتح الله ضادوری

118а биттә алты почмаклы кара мөһер: ...عريف («Гариф...»). Ишан Әхмәтсафа Биккуловны 1930 елда атканнар: Миннуллин И., Минвалеев А. Суфизм в советском Татарстане: к постановке проблемы // Гасырлар авазы. 2007. 1.

**44** (111)

Исемсез теркәмәләр. 8 кәгазь. Җырлар, такмаклар, гарәп сарыфы һәм башкалар, гарәп һәм төрки телләрдә. Әхмәтсафа дамелла Фәтх әз-Задури соңгы гасырда язган.



*Рис. 40.* Владельческая запись Фатхуллы Задури в рукописи НМ РТ 18369-111, л. 117б

**45** (110)

كتاب مولانا سعد الدين تفتازانی النسائی شافع مسعود بن القاضی فخر الدين عمر بن مولا الاعظم برهان الدين عبد الله بن الامام شمس الدين القاری

كتاب شرح شمسية فی قواعد المنطقية

**Китабе мәүлана – Сәгъд әд-Дин Тәфтәзани ән-Нисаи Шафигъ Мәсгуд бине әл-казый Фәхреддин Гомәр бине Мәүлә әл-Әгъзам Борһанеддин Габдулла бине әл-имам Шәмседдин әл-Кари. «Китабе шәрхе Шәмсия фи кавагыйдел мантыйкыйа»**

218 кәгазь, гыйльме мантыйктан, гарәп телендә. Таҗеддин бине Бәшир әл-Болгари әт-Тави әс-Суыксуи, милади 1838 елда Казанда мулла Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри мәдрәсәсендә язган. Карагыз кәгазь, 215. Димәк, бу китап бу мәдрәсәдә дәреслек булган. Укырга һәм сакларга.
* 17,7×22. 220 бит. Каплавычның тышлыгы төшкән.
Язу рәвеше тәгъликъ, су билгеләре 1833 елны күрсәтә, кара һәм кызыл каралар, бит номерлары гарәпчә һәм музейда яңадан куелган, кустодлар бар. Кызыл рамкада 4б-6а битләр. 3а биттә иясенең язмасы: ملك احمدجان داملا تاج الدين مرحوم اوغلى نقى («Милке – Әхмәдҗан дамелла Таҗеддин мәрхүм углыныкы»).



*Рис. 41.* Владельческие записи и оттиск печати. НМ РТ 18369-110, л. 3а

Шул ук җирдә кара алтыпочмаклы мөһер куелган (2,1×2 см): 1840 محمد شاكر بن محمد شريف («Мөхәммәдшакир бине Мөхәммәдшәриф 1840»).
Өстәмә язма 4а биттә:

1886نجی یلده 20 نجی نویابرده شمسية كاتشدم خدا تباركة و تعالی خیرلی علم نافع ویرسون

(«1886 елда 20 ноябрьдә «Шәмсия» катыштым. Ходай Тәбарәкә вә Тәгалә хәерле гыйлем, нәфегъ бирсен»).
Бүтән кул белән шул ук җирдә өстәлгән:



صاحبه داملا تاج الدين بن بشير سلطانف شرح شمسية نام 28 نچی نومیر

(«Китапның иясе – дамелла Таҗеддин бине Бәшир Солтанов. «Шәрхе Шәмсия» исемле. 28нче номер»).



*Рис. 42.* Владельческая запись Тадж ад-Дина б. Башир. НМ РТ 18369-110, л. 4а



*Рис. 43.* Колофон и владельческая запись в рукописи НМ РТ 18369-110. л. 217б

Өченче кул белән шул ук җирдә әсәрнең авторы турында «Кәшфез зөнүн»нән кыска мәгълүмат бирелгән. Колофон 217б биттә язылган:

تمت و قد وقع الفراغ من تحرير هذه النسخة الشريفة فی شهر قزان و فی مدرسه داملا بايمراد بن محرم المنكری و فی يد العبد الفقير الراجی من رحمة الله و قليل البضاعت و كثير البطالت تاج الدين بن بشير البلغاری الطاوی الصوقصوی... فی سنه 1838 رومية مای ننك 7 يومنده.

Өстәмә язмасы: سنه میلادی 1838
(«1838 милади ел»).
Шул ук җирдә башка өстәмә:

1845 نچی یلده 12 نچی فورالده قزاندین بخاری شریف کاچوب
کیتدوم 57 نچی یلده صوقصوغه ایومزکا قایتوب 58 نچی یل غنوارده
ایکنچی مرتبه بخارای شریف کیتدوم بو کتابنی ایکی مرتبه بخارای
شریف الوب باردوم آنده 1860 یلغه چه درس ایتدوم 40 نچی یل ایول
9 نده اولوغ منکار کا قایتدوم کتبه تاج الدین بن محمد بشیر فی سنه
1870 3 نچی برج ایون

(«1845 елда 12 февральдә Казаннан Бохараи Шәриф(кә) качып киттем. 57 нче елда Суыксуга өемезгә кайтып, 58 нче ел гыйнварда икенче мәртәбә Бохараи Шәриф(кә) киттем. Бу китапны ике мәртәбә Бохараи Шәриф(кә) алып бардым. Анда 1860 елгача дәрес иттем. 40 нче ел июль(нең) 9 ында Олуг Мәңгәргә кайттым. Шушыны Таҗеддин бине Мөхәммәдбәшир 1870 ел 3 июнь(дә) язды»).

---

**46**

محمد بن اسعد صدیقی الدوانی. شرح عقاید

**Мөхәммәд бине Әсгад Садыйки әд-Дәввани. «Шәрхе гакаид»**
10 кәгазь. Гакаид, кәлам, гарәп телендә, күчереп язучы билгесез.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**47 (106)**

ابو المتقی ابن صاحب التلویح
شرح فقه الاکبر لامام ابو حنیفه کوفی

**Әбу әл-Мөттәкый ибне сахиб «әт-Тәлвих»**
**«Шәрхе фикъһел әкбар ли-имам Әбу Хәнифә Куфи»**
68 кәгазь, осуле фикъһ, гакаид, гарәп телендә.



* 17×21. 133 бит. Төп нөсхәсе катыргы тышлык, почмаклар белән. 1б–35б битләр. Язу рәвеше нәсех, кара һәм кызыл каралар, кустодлар бар, бит номерлары соңыннан куелган.

---

**48 (106)**

کتاب شرح امالی

**«Китаб шәрхе Әмәли»**
19 кәгазь, гакаид исламия, гарәп телендә, мәнзумә, 90 бәет.
37б–54б битләр. Бер кул белән күчерелгән.

---

**49 (106)**

Төрле язмалар, төрле догалар һәм башкалар. 4 кәгазь, гарәп, төрки һәм фарсы. Күчереп язучының исеме, тарихы күрсәтелмәгән. Китапның һамишендә бик күп китаплардан күчермәләр бар. Кәгазендәге су билгесе 1812 елны күрсәтә.

---

**50 (106)**

عبید الله ابن مسعود ابن تاج الدین الشریعة.
مختصر الوقایة الروایة فی مسائل للهدایة

**Гобәйдулла ибне Мәсгуд ибне Таҗеддин әш-Шәрига.**
**«Мохтәсарел викаяр ривая фи масаилел Һидая»**
Фикъһ фөругел ислам, гарәп телендә. 1844 елда Хәбибулла бине Рәхмәнкол мәдрәсәсендә Кәмаледдин бине Нәҗмеддин бине мелла Рәхмәнкол язган. Каләме бик матур, имлясы дөрес. Шушы ук кеше бер кәгазьгә бәетне керткән. Бу бәет XIV йөз кыпчак шагыйре Котыбның «Хөсрәү вә Ширин» дастанында да бар. Димәк, XIX йөздә шагыйрь Котыб әсәрләре безнең авылларда әле сакланган икән.
Бу кеше Нигъмәтулла бине Мөнасыйпның шәкерте булган. Казанда Әбу Бәкер хәзрәт мәдрәсәсендә укыган чагында.
* Җыентыкның 59б–129б битләрендә: «1846 елда Кәмаледдин бине Нажмеддин бине мулла Рәхмәнгол тарафынан язылган».
59а биттә китап иясенең язмасы:



*Рис. 44.* Владельческая запись в рукописи НМ РТ 18369-106, л. 59а

قد دخل فی ملك ضياء الدين بن ملا كمال الدين الخوجاشی البلغاری

(«Зияддин бине мулла Кәмаледдин әл-Хуҗаши әл-Болгари милкенә керде»).

63б биттә өстәмә язу: كاتبه عطاء الله لاجل اشنای كمال الدين

(«Моны Гатаулла әшнай Кәмаледдин өчен язды»).

111а биттә өстәмә язу:

كاتبه عبد الناصر القللاری لاجل كمال الدين ممد قوجاوی (!) رحمة الله عليهما الباری

(«Моны Габденнасыр әл-Коллари Кәмаледдин Мәмәт Күчәви (!) өчен язды, Аллаһының рәхмәтендә булсыннар»).

98б биттә өстәмә язу:

كتب فخر الدين النارطباشی لاجل اشنای داملا كمال الدين الممت قوجه وی (!)

(«Фәхреддин ән-Наратбашы әшнәй дамелла Кәмаледдин әл-Мәмәт Күчәви өчен язды»).

Колофон 129б биттә:

قد فرغت هذه النسخة الشريفة المسمی بمختصر الوقاية كمال الدين بن ملا نجم الدين بن ملا رحمنقل غفرالله تعالی ذنوبهم و ذنوب جميع المسلمين... كتب فی مدرسه داملا استاذی حبيب الله بن رحمنقل رحمة الله عليهما بحرمة سيد المرسلين سنه 1846

(«Шушы китап «Мохтәсарел викая» исемле Кәмаледдин бине мулла Нәҗмеддин бине мулла Рәхмәнкол тарафыннан язылган. Аллаһы Тәгалә алар һәм бөтен мөселманнар кылган гөнаһларны кичерсә иде... Остазыбыз дамелла Хәбибулла бине Рәхмәнкол мәдрәсәсендә язылган, Аллаһының рәхмәте булсын. 1846 ел»).





*Рис. 45.* Колофон в рукописи. НМ РТ 18369-106, л. 129б

Татар мәдрәсәләре өчен XIX гасырның икенче яртысында хас булган кызу тәгъликъ язуы. Өске каплавычының әйләнешендә Зәйнәп Максудова тарафыннан кулланылган әдәбият күрсәткече тупланган.

Иске фиһрист буенча – № 113.

---

**51** (207)

سيد شريف جرجانی علی بن محمد

كتاب تعريفات

**Сәед шәриф Җөрҗани Гали бине Мөхәммәд. «Китабе тәгърифат»**

Гыйльми истыйляхлар сүзлеге. 84 кәгазьдә, 168 сәхифә. Тәгърифатның 1614 ел Мисырда язылган нөсхә белән мосаннифнең вафаты арасында 200 ел булган.

Гыйлем легатьтән, гарәп телендә. Күчереп язучы Мансур бине Әби Нүх әл-Мәгъриби әл-Гарәби (мәшһүр фәкыйһ), һиҗри 1023,

милади 1614 елда язган. Бу китаптан Ибраһим бине Габделмөхсин бине Әйүб әл-Әнсари файдаланган. Мөхәммәд бине Хәсән әл-Әставани, төрки фәкыйһ, Әставани китабының мосаннифе, Хөсәен бине Габдеррәхман әс-Сәман 1210 һиҗри, 1898 елда файдаланган. 1853 елда ахунд бине мелла Әхтәм сатып алган.
Бу әсәрнең таснифы – XV йөз башында, күчерелүе XVII йөз башында булган. Сакларга кирәк.
* 15×21. Язу рәвеше нәсех. XVII гасырдагы Якын Көнчыгыш кульъязмасы. Бит номерлары гарәп стилендә Зәйнәп Максудова тарафыннан куелган. Көнчыгыш кәгазе, су билгеләре юк. Китапның иясе кайбер сүзләрне татарча тәрҗемә иткән. Кустодлары юк. Гарәп телендә. Китап тулысынча сакланган.
Тышлыкта Зәйнәпнең язмасы: «Зәйнәп Максудова китапханәсеннән. (...) Мосаннифы – Сәедшәриф Җөрҗани Гали бине Мөхәммәд. Вафаты һиҗри 814, милади 1413 елда. Кәтибе [язучы] Мансур ибне Нух әл-Мәгъриби Әгъраби, һиҗри 1023, милади 1614 елда күчереп [язды]. Бу китапны укыган[нар]: Ибраһим бине Габделмөхсин ибне Әйүб әл-Әнсари, Мөхәммәд бине әл-Хөсәен әл-Мәстәвәли (1616 елда аның милкендә булды), Хөсәен бине Габдеррәхмән».
1а биттә өстәмә язма:

هذا تعريفات للسيد الجرجانى اشتريته و تملكته فى سنه خمس و
عشرين و الف فى مصر المحرسه و انا الفقير محمد بن حسن فى عنهم

«Бу Сәед Җөрҗани «Тәгърифат» китабын сатып алдым Мисырда 1025 елда. Мин – фәкыйрь Мөхәммәд бине Хәсән, Аллаһы Тәгалә аларны гафу итсен».
Бүтән өстәмә язма:

قد جاء به التقدير الى ملك الفقير الحقير ... عناق حسين بن عبد
الرحمن السمان 1210 سنه

«Бу китап фәкыйрь ... Гыйнак Хөсәен бине Габдеррәхман әс-Сәман милкенә 1210 елда керде».
Өстәмә язма татарча язуы белән: قد تملك اخوند ابن ملا ... 1853 سن
(«Ахунд бине мулла... милкенә 1853 елда керде»).



Өстәмә язма:

حسبى الله
طالع فيه و تامل معالله و اعيا الصاحبه بالبقا و علوا الارتقا ابراهيم بن
عبد المحسن ابن ايوب الانصارى غفرلهما
امين بحرمة سيد المرسلين

1б биттә язма: قد دخل فى ملك اخوند ابن ملا رصتم بنيع («Ахунд ибне мулла Рөстәм Бәнигъ милкенә керде»).
Колофон 84 биттә:

و حسن توفيقه على يد كاتبه الحقير منصور ابى نوح المغربى فى ثالث
عشر رجب 23

Иске фиһрист буенча – № 82.
Китапның икенче нөсхәсе Братиславада саклана (шифр TF72, күчерү елы 1129/1716). Карагыз: Arabische, türkische und persische Handschriften der Universitätsbibliothek in Bratislava. Bratislava, 1961. P. 211.
Санкт-Петербургта бастырылды: Flügel, Leipzig, 1845.

---

**52** (53)

كتاب عقود منظومة

**«Китабе Гокуд мәнзумә»**
110 кәгазь. Сөннәнел ислам кагыйдәләре, гарәп телендә. Милади 1796 елда Казан юлы Әгерҗе авылында Хөсәен бине Мәскәү исемле мөдәррисенең мәдрәсәсендә Шәмседдин бине мелла Ишмөхәммәд исемле шәкерт язып тәмам иткән.
* 16×21. 116 бит. Кәгазе «VFSI» су билгеләре белән; язу рәвеше тәгъликъ, бит номерлары гарәп стилендә һәм яңадан музейда куелган.
2б–112а битләрдә Пәйгамбәр сөннәте турында сүз бара.
Колофон 112а биттә язылган:

تمت الكتاب بعون الله الملك الوهاب سنة 1796 بتوفيق خداى لا ينام
اين كتاب روزى جمعه شد تمام

(«Бу китапны күчерү, Аллаһы Тәгалә ярдәме белән, 1796 елда, җомга көнне тәмам булды»).

**53 (53)**

Осуле тәгълим вә тәрбия хакында бик матур теләкләр, киңәшләр бар, хәзерге заман өчен дә әйбәт. 4 кәгазьдә. Ислам кагыйдәләре буенча. Төрки һәм гарәп телендә. Шул ук кеше язган. Язуы бик төзек. Шул ук кул белән күчерелгән, 112а–116б битләрдә. Гарәп телендә, татар шигырьләре белән. Колофон 116б биттә:

قد تمت هذه النسخة الشريفة فى طريقة قزان و فى قريء اكرجى و
فى مدره سهء افندى الزمان مولانا و اولانا حسين بن مسكو و فى يد
الضعيف شمس الدين بن ملا يشمحمد غفر الله ذنوبهما...

(«Шушы кулъязма Казан юлында Әгерҗе авылында остазыбыз Хөсәен бине Мәскәү мәдрәсәсендә без, фәкыйрегез – Шәмседдин бине мулла Ишмөхәммәд тарафыннан язылды. Аллаһы Тәгалә алар кылган гөнаһларны кичерсә иде»).
Түбәндә Зәйнәп Максудованың өстәмә язмасы: «1809 елгы «Мәфатихел җинан» кулъязмасында «Шушының иясе – Шәмседдин бине мулла Ишмөхәммәд» дип күрсәтелгән. 1821 елда әле бу кеше исән булган. Зәйнәп Максудова».
Иске фиһрист буенча – № 144.

**54 (85)**

شرح عقايد

**«Шәрхе Гакаид»**

Имам әл-Газали китабына шәрех, мосаннифы билгесез, чөнки башындагы битләре төшкән. 24 кәгазь. Гакаид, каләм, гарәп телендә. Буа шәһәрендә Габделвахид бине Габдеррәхман мәдрәсәсендә 1849 елда Хөснеддин бине Габдулла Янтугани исемле кеше язып чыккан.



* 17,5×22. 49 бит.
Тышлыгы юк, торец лейкопластырь белән ябыштырылган. Иясенең язмасы 1а биттә кырылган. Аннотация: «(Кимияи) сәгадәт» исемле китабына шәрех.
1б–25а битләрдә. 1б биттә болай башлана:

بسم الله الرحمن الرحيم قوله و عذاب القبر للكافرين آه اعلم ان
الترتيب الطبيعى العادى تقتضى تقديم قوله و سوآل منكر و نيكر على
عذاب القبر و التنعيم فيه لان التعذيب و التنعيم بعد السؤال و الجواب
موقوف عليها بمقتضى حكمة الله تعه و على ما نطق به الحديث
كاسيأتى الا انه قدم التعذيب و التنعيم على السؤال للاهتمام ...

Колофон 25а биттә:

سودت هذه السنخة الشريعة حسن الدين بن عبد الله الينطوغانى
فى مدره سة ملانا و استاذنا رفعنا الى درجة العلى فى الدارين بسبب
تعليننا عبد الواحيد بن عبد الرحمن البواويى 1849 سنده

(«Бу китапны Хөснеддин бине Габдулла әл-Янтугани остазыбыз Габделвахид бине Габдеррәхман әл-Буави мәдрәсәсендә 1849 елда тәмамладым»).



*Рис. 46.* Колофон в рукописи. НМ РТ 18369-85, л. 25а

Бит номерлары Зәйнәп Максудова тарафыннан һәм музейда куелган. Кустодлар бар, тәгълыйкъ язу рәвеше, кара каралар, кәгазе XVIII гасыр ахырына яки XIX гасыр башына карый.

**55 (85)**

**Сәгъди. Гөлестан**

24 кәгазь. Кечкенә хикәяләр мәҗмугасы, фарсы телендә. Шул ук кеше язып чыккан. 26б-49б битләр. Ахыры юк.

**56 (78)**

## ابو الليث السمرقندى. كتاب بستان العارفين

**Әбу әл-Ләйс әс-Сәмәрканди. «Китабел бостанел гарифин»**
121 кәгазь. Язуы матур һәм дөрес. Ислам әдәбе хакында, гарәп телендә. Бу китап Пәслаке мулла(сы) Габделваһаб бине Габделмәҗид милкендә дә булып торган. Асансуы буенда Тукай авылында Габделхалик бине Китаб исемле мөдәррис алдында укучы Гайсә бине Тимер Пәслакый милади 1818 елда язып тәмам иткән. Буш калган кәгазьләрдә төрки шигырьләр дә бар. Алар да ислам әдәбе хакында, тыйб хакында, гаилә хәбәрләре дә бар. Бабайларыбызның истәлеге. Сакларга кирәк.
* 17×20,5. 126 бит. Яртылаш күн тышлыгы, аскы каплавычы юк. Аннотация: «№56. (...) Бу китап Габдессәттар мулла бабай китаплары арасыннан чыкты».
Өске каплавычының әйләнешендә төсле кәгазь ябыштырылган. Кәгазь XIX гасырның беренче яртысына карый, күгелҗем төстә. Язу рәвеше тәгъликъ, кара һәм кызыл каралар, бит саннары гарәп стилендә һәм музейдә куелган. Кустодлар бар. Иясенең өстәмә



*Рис. 47.* Владельческие записи в рукописи. НМ РТ 18369-78, л. 1а



язмасы 125б биттә: ملكه ملا عبد الوهاب ملا عبد المجيد اوعلى («Моның иясе – Габделваһаб мулла Габделмәҗид углы»).
Колофон 124б биттә:



*Рис. 48.* Колофон в рукописи. НМ РТ 18369-78, л. 124б



*Рис. 49.* «О венерических заболеваниях». НМ РТ 18369-78, л. 125а

1818 نچی یلنده. کاتبی عیسی بن تیمر
یازولدی اوسان بوبی توقای آولنده استاذ مکرم عبد الحالق ابن کتاب

«1818 елда. Язучы Гайсә бине Тимер. Язылды Асан буе Тукай авылында, остаз мөкәррәм Габделхалик ибне Китаб [тарафыннан]».

---

**57** (109)

سعدی. گلستان

**Сәгъди. «Гөлестан»**
143 кәгазь. Әхлакый-тарихи дастаннар. Фарсы телендә, һәр сәхифәдә 15 юл. Тирсә авылында (Казан юлы) Ягъкуб бине мелла Нигъмәтулла мәдрәсәсендә 1850 елда Габделҗәмил Габделмәннан углы Максудов күчереп язган.
Сакларга. Әтиемнең истәлеге.
* 17×20,6. 144 бит.
Ялтылаш күн тышлык, каплавычы иске кулъязма битләреннән. Тышлыкта аннотация бирелгән. Бу китап башка бер кулъязма бите белән урап куелган.
1а биттә Зәйнәп Максудова кулы белән шәҗәрә төзелгән: «Тәкермән авылының мулласы фәлән. Мулла Бәкир хатыны Гөлзифа. Хәбибулла хатыны. (Гөлзифаның бертуганы) Миңеш. Аның балалары: Шәмсекамар, Сәрвиҗамал, Шәмсениса. Сәрвиҗамалның углы Фазлыәхмәт. Бәкринең улы Хәбибулла, аның кызы Гөлзифа һәм улы Миңеш».
Кулъязма тулы. Язу рәвеше тәгъликъ һәм нәсех, кара каралар, Зәйнәп Максудованың әтисе үз кулы белән язган, бит саннары гарәп стилендә, музейда куелган, калын урыс кәгазе XIX гасыр уртасына карый, су билгеләре юк.
Күчереп язучының язмасы 144б биттә:

بو صوکغی مصراعنی یازوچی صاحب جمال حبیب الله قزی بکری ملا
اوغلی اول حبیب الله تکرمه ن اولنده بونک آناسی گل زیفا ئه بی
بزنک ئه بی یمز میکنش برله ن بر طوغمه





*Рис. 50.* Потомки имама из дер. Тәкермән. НМ РТ 18369-109, л. 1а



*Рис. 51.* Владельческая запись З. Максудовой. НМ РТ 18369-109, л. 16

(«Бу соңгы мисрагны язучы – Сахибҗамал Хәбибулла кызы, Бәкри мулла углы. Ул Хәбибулла Тәкермән авылында, моның анасы Гөлзифа әби безнең абыемыз Миңеш берлән бер тугыма булган»).
Шул ук җирдә Миңешкә туганлык күрсәтә торган Зәйнәп Максудова тарафыннан төзелгән шәҗәрә.
Иске фиһрист буенча – №17. Монда 1846–1852 еллар эчендә Тирсә мәдрәсәсендә күчерелгәне искә алына.

---

**58** (17)

ابو الثنا احمد بن محمد ابی البرکات الزیلی ثم السواسی
زبدة الاسرار فی شرح مختصر المنار

**Әбу әл-Сина Әхмәд бине Мөхәммәд Әби әл-Бәрәкә әз-Зили, соңра әс-Сиваси. «Зәбдәтел әсрар фи шәрхи Мохтәсарел мәнар»**

65 кәгазь. Осуле шәргъ. Гарәп телендә. Күчереп язучы Җәләледдин бине мелла Сәгъдәддин бине мелла Вәли Мөхәммәд әз-Зәдүри Казанда 1886 елда дәмелла Габделвәли бине Габделгаффар бине Яхъя бине Хөсәен Яңачокали әл-Чокали мәдрәсәсендә язып тәмам иткән. Каләме бик матур. Алдагы һәм соңындагы 7–6 кәгазьдә төрле үзәкләр бар.



*Рис. 52.* Аннотация к рукописи. НМ РТ 18369-17



* 17,5×21,5. 70 бит.
Катыргы тышлык. Өске каплавычының тышлыгында № 58 һәм аннотация бар.
Өске каплавычының әйләнешендә карандаш белән язма бар:

این جامع الرموز را وقف خاص کردیم بر شاکردان که در مدرسه اسکی
ضادور تعلیم میکنند اسم واقف خوجه احمد بن ملا مظفر غورنیقاوی

(«Ошбу «Җамигер рөмүз» [китабын] Иске Задур мәдрәсәсендәге шәкертләр өчен махсус вәкыф кылдык. Вакыйфның исеме – Хуҗаәхмәт бине мулла Мозаффар Гурникави»).
За биттә өстәмә бар:

متملك هذا الكتاب بلا ارتياب جلال الدين بن سعد الدين المرحوم
الضادورى

(«Һичшиксез, ошбу китаб – Җәләледдин бине Сәгъдеддин әлмәрхүм әз-Задуринең милкендәдер»).
Урыс кәгазе, XIX гасырның икенче яртысына карый («Медянской фабрики Первушина № 6 в Вятке» дигән штемпельләре куелган).
Язу рәвеше татар тәгълике, гарәп телендә, кара каралар. Кустодлар бар. Бит саннары гарәп стилендә һәм музейда өстәлгән.
Колофон 68б биттә:

قد تمت الكتاب بعون الله الملك الوهاب
فى مدرسة استاذنا داملا عبد الولى بن عبد الغفار الچوقالى فى يد عبد
الضعيف جلال الدين بن ملا سعد الدين بن ملا ولى
محمد المرحوم الضادورى و فى شهر غزان
اين كتابنك حاجينه هر زمان * سن عنايت ايلكل يا مستعان
تمت تمام اولدى فى يوم پنچشنبه و السلام

Колофон кырыенда 1886 نچى يلده
Иске фиһрист буенча № 98.



*Рис. 53.* Колофон к рукописи. НМ РТ 18369-17, л. 68б

Карагыз: GAL, SII, 91. Китап ике мәртәбә Казанда бастырылды (1887, 1900).

**59 (44)**

**Кәлям шәриф**

Зур кулда. Баштагы һәм соңгы битләре тәләф булган. Шунлыктан язылу тарихы читен булып калды. Гарәп телендә. Күчереп язучы – Хәзинә хатын, Ибраһим җәмәгате (элгәреге Вятка губернасы Алабуга өязе Уразай авылы). Язылу тарихы XVIII йөзнең беренче чиреге белән XVII йөзнең соңгы яртысы булырга тиеш, чөнки Хәзинә әби XVIII йөзнең башларында вафат булган. Бу Коръәнне күн белән төреп, Пугачев явы чорында мунча идәне астында куеп саклаганнар. Шул вакыйганы минем әбиләрем һәм әтием сөйли иделәр. Безнең нәселдә бу китап «Хәзинә әби Коръәне» буларак атаклы иде.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.



**60 (172)**

جامع الفتاوى فوائد اسلامية

**Җамигел фәтава Фәваиде исламия**

Мосаннифы билгесез. 559 кәгазьдә, һәр битендә 21 юл. Фикъһе ислам, фөругтан, барлыгы 40 фасыл. Гарәп телендә, сүлс сыгнакый



*Рис. 54.* Рукопись. НМ РТ 18369-172, л. 78а

рәсем хаты белән язылган. Тулы, ләкин беренче һәм соңгы битләр, төзеп, яңадан өстәлгән.
Күчереп язучының исеме, тарихы, урыны күрсәтелмәгән. Шулай да XIV йөз башларында төзелгән һәм XV йөзләрдә күчерелгән булырга охшый: күп җирдә Шәмс әл-Аимә гасыр хөснидән гыйбарәләр китерә. Ул исә XI йөз азагында вафат булган.
Тансык истәлек – борынгылык белән.
* 19,2×25,3. 567 бит. Кара каралар. Язу рәвеше нәсех. Гарәп телендә.
Беренче биттә кечкенә кәгазьдә аңлатмалар бирелде: «Карарга кирәк. تملك عن عبد الكريم بن محمد بن ... (Иясе – Габделкәрим бине Мөхәммәд бине...). Китапларыннан лөгат аңлатмасы алынганы күрсәтелде».
3а биттәге «Бу китапта аталган затлар һәм китаплар» исемлеге Максудова тарафыннан төзелгән. 6б–14а битләрдә – китапның эчтәлеге белдерелгән. Һәр биттә 21шәр юл, кустодлар бар.
1–4, 561–563 бит – Урта Азия кәгазе, реставрацияләнгән. Калган битләре – кустарная бумага ближневосточного производства (Якын Көнчыгышта кустарь рәвештә ясалган кәгазьдә).
567 биттә өстәмә язма: № آلتمش

---

**61** (117)

محمد يازيچي اوغلى كليبولى

محمديه منظومه

**Мөхәммәд Языҗыоглу Кәлибули. «Мөхәммәдия мәнзумә»**
Һиҗри 850дә тәмам иткән, милади 1446 елда. 231 кәгазь, 462 сәхифә. 20шәр юл.
Тарихе Мөхәммәд галәйһиссәлам. Төрки-госманлы телендә. Кайчан, кайда күчереп язылганы күрсәтелмәгән, ләкин кәгазь – Рәсәй кәгазе, су билгесе: 1815 ел.
Сакларга һәм укырга кирәк. Теле бай, шигырь техникасы көчле.
* 15,5×25,3. Каплавычының тышлыгы юк. Су билгеләре: 1813, 1815. Бит саннары музейда куелган, кара һәм кызыл каралар, кустодлар бар, язу рәвеше нәсех.





*Рис. 55.* Разворот рукописи с пометами З. Максудовой. НМ РТ 18369-117, лл. 227б–228а

---

**62** (120)

مولوى نعمان بن امير بن عثمان الثمنى

تفسير مولوى نعمان الثمنى القورصاوى

**Мәүләви Ногман бине Әмир бине Госман әс-Сәмани әл-Курсави. «Тәфсир»**
Әс-Сәмани – Ырынбур өязе Сәман авылныкы, әл-Курсави – Курса авылында Габденнасыйр Курсавида укып, аның үзенә имамәтлек һәм мөдәррислек тә калган иде.
Һиҗри 1236, милади 1821 елда Әбу Наср Курсави хаҗга киткәч язылган. 147 кәгазь, 294 сәхифә, зур кулда. Тәфсир, каләм. Төрки-Казан телендә, бик ачык. Күчерүченең исеме күрсәтелмәгән. Шулай да



*Рис. 56.* Пометки З. Максудовой в списке тафсира Нугмани. НМ РТ 18369-120, л. 104б

мелла Сөендек бине Габделгазиз бине Гайсә әл-Көнари язган булырга тиеш. Язуы бик гади, пөхтә, рәсем хаты Идел буе нәсех-тәгъликъ хаты.
Сакларга һәм дарелфөнүнга тапшырырга.
* 21×32,2. Яртылаш күн европа тышлыгы. Аннотациядә «мулла Габдессәттар бабай китаплары арасында табылды» дип билгеләнә. Язу рәвеше нәсех, кара һәм кызыл каралар, кустодлар бар. Форзацтагы язма: وتكه غوبرنه سنده صاراپول سلسكى اويازينده («Вятка губернасында Сарапул Сәләскә өязендә»).
2а–32б битләрдәге текст кызыл рамка эченә кертелгән. Колофоны юк.
104б бит кырыенда Зәйнәп Максудованың язмасы: «Шушы вакыйганың төрки мәнзумәсе бар. Дәүләт дарелфөнүн хәзинәсендә саклана. Тимәш авылы дигән исем мәтендәге мәҗмуга теркәлгән».



**63** (107)

ابو العلاء الاوشى
كتاب نصايح الاخبار

**Әбу әл-Галә әл-Уши. «Китабе нәсаихел әхбар»**
Бу әсәрдән «Нәһҗел фәрадис» мосаннифы да файдаланган. Баштагы сәхифәләре төшкән. 55 кәгазь. Фикъһ һәм әхлак, гарәп телендә.
* 17×21. 58 бит. Тышлыгы юк. Гарәп телендә, кәгазе XIX гасырның беренче яртысына карый, язма рәвеше нәсех, кара һәм кызыл каралар, җыентыкта 3а–55а битләрне ала.


1
№٦٣
63
زینب مقصودوا مکتبه‌سی کتابلردان
١) نصائح الاخبار کتابی (فقه هم اخلاق کتابی)
مصنف.
٢) وصیة الامام اعظم (عقاید کتابی)
١١٧٦ هجری ١٧٦٢ میلادیده یازلغان.

*Рис. 57.* Аннотация к рукописи. НМ РТ 18369-107

**64** (107)

امام ابو حنيفه بن نعمان بن ثابت

كتاب وصية الامام الاعظم

**Имам Әбу Хәнифә б. Ногман б. Сабит. «Китабе васыятел имамел әгъзам»**
4 кәгазь. Гакаид, каләм. Гарәп телендә. Һиҗри 1176, милади 1764 елда язылган. Исеме күрсәтелмәгән, шулай да Тирсә (хәзерге Әгерҗе районы) авылында язылган булыр, чөнки әткәем анда укыган. Бу китап аннан килгән, шул ук елда язылганы күрсәтелгән. Рәсем хаты зәгыйфь, имлясы хаталы.
Дарелфөнүнгә бирергә, инде бу китапка 200 яшь.
* Җыентыкның 55а–57б битләрендәге аннотациядә мондый мәгълүмат бирелгән: «Хамишендә бик күп шәрык китапларыннан кисәкчәләр алынган. Бу китап Тирсә авылында язылган булыр, чөнки атам Габделҗәмил Габделмәннан угълы Максудовның китаплары белән миңа күчкән иде. Ул үзе Тирсә шәкерте иде. Туган 1832 елда, вафат 1925 елда».
Иске фиһрист буенча – № 64.

**65** (24)

عبيد الله بن مسعود تاج الشريعة

مختصر الوقاية فى مسائل الهداية

**Гобәйдулла бине Мәсгуд Таҗ әш-Шәрига.**
**«Мохтәсарел викая фи мәсаилел һидая»**
Китапны дарелфөнүнгә тапшырырга.
* 17×20,7. Яртылаш күн тышлык. Өске каплавычта аннотация бар. Кәгазьнең су билгесе 1824 елгы. 1а биттә өстәмә бирелгән: اوشبو كتاب ملا عبد الجميل عبد المنان اوغلى («Ошбу китап [иясе] – мулла Габделҗәмил Габделмәннан углы»).
Каты шома урыс кәгазе XIX гасыр башына карый. Язу рәвеше нәсех, кара һәм кызыл каралар, бит саннары гарәпчә һәм европача куелган, кустодлар бар. Һәр биттә 9 юл.



Колофон 140а биттә:

قد وقع الفراغ فى هذه النسحة
الشريفة من يد عبد الضعيف كان
فى شهر رجب و كان منه فى
يوم الاول و كان فى وقت الزوال
دوشنبه كون و فى النجوم و له
١٨٢٧ يلنده كاتله و مالكه عينو
الله بن فيضوالله غفرالله ذنوبهما
فى مدرسه بايلار داملا عبد الغفور
بن سيفوالله غفر الله ذنوبهما و
يدخلهما فى الجنة



*Рис. 58.* Колофон рукописи «Мохтәсарел викая»
НМ РТ 18369-24, л. 140а

Карагыз: GAL, I, 376.
Иске фиһрист буенча – № 24.

**66** (16)

محمد بن محمد چوقراقچى زاده استانبولى

كتاب دلائل النبوت محمدى شمائل فتوة احمدى

**Мөхәммәд бине Мөхәммәд Чокракчызадә Истанбули**
«Китаб дәлаилен нәбүвәт Мөхәммәди шәмаил фөтүәт Әхмәди»
Вафаты һиҗри 1033/ милади 1624 елда.
Бу китап Мөхәммәд б. Исхакның «Китабел мәгазый вә сирр» дигән әсәреннән файдаланган. Бу Исхак Мөхәммәд һиҗри 151дә вафат булган. 95 кәгазь, 190 сәхифә.
Мөхәммәд галәйһиссәламнең тарихы, төрки телдә. Кайда, кем, кайчан күчереп язганы күрсәтелмәгән. Кәгазьнең су билгесе 1816 елны күрсәтә. Бу китапта Сөләйман Саксининең «Зөһрәтер рияз» исемле китаптан алынган өзекчәләр байтак.

Дарелфөнүнгә тапшырырга.
* 16,5×21,5. 95 бит. Переплет (китап тышылыгы) – кустарь катыргыдан. Су билгесе 1816 елны күрсәтә. Язу рәвеше нәсех, урыс кәгазе XIX гасыр башыныкы, кустодлар бар, бит саннары музейда куелган.
Карагыз: Türkische Handschriften. Teil 1. Beschr. von Barbara Flemming. Wiesbaden, 1968. P. 55–56.

**67** (206)

صوفی الله یار خوارزمی

ثبات العاجزین

**Суфый Аллаһияр Хорезми. «Сөбәтел гаҗизин»**
Вафаты Бохарада һиҗри 1116 елда/ милади 1704.
Тәсаувыфтан төрки мәнзумә. 18 кәгазь, 35 сәхифә. Төрки. Тулы түгел. Нәсехи. Тарихы билгесез.
* 15×20,5. 18 бит.
Урыс кәгазе XVIII гасырга карый. Фарсы телендә. Язу рәвеше татар тәгълике. Гарәп телендә сирәк тәрҗемәләр дә очрый. Гарәпчә бит саннары карандаш белән куелган. Ахыры юк.

**68** (88)

ملا خواجه نظر ابن غایب نظر جمیانی هویدا الروشانی

کتاب راحت دل

**Мулла Хуҗаназар б. Гаибназар Җимьяни Һәвидәр Рәүшани. «Рәхәте дәл»**
Күңел тынычлыгы, мәнзумә. 8 кәгазь, 16 бит. Тәсаувыф-әхлак, төрки. Тулы түгел. Нәсехи. Тарихы билгесез.
* 16×21. 8 бит. Кулдан ясалган кәгазь тышлы, җеп белән тегелгән. Аннотациядә андый мәгълүмат бар: «Бу китап Казанда 1838, 1890, 1896 елларда басылган. Идел буе татарлары арасында күп таралган, күп укылган. Теле гарәп, фарсы һәм борынгы төрки алынмалары белән тулы».



Башы һәм ахыры юк, язу рәвеше тәгъликъ, кара каралар, гарәпчә һәм европача бит саннары, кустодлар бар. Бу китап өчен сүзлек: Кулъязма НМ РТ 18369-38. 170×210. 47 кгз. Зәйнәп Максудова. «Рәхәте дел» китапның сүзлеге. مستطاب راحت دل
Автор турында тулырак мәгълүмат: Hofman, III, 1. P. 146.

**69**

Намәгълүм Идел буе төрки галимнең

قصه سیف الملوک و بدیع الجمال

**«Кыссаи сәйфел мөлүк вә бәдигел җамал»**
Чәчмә хикәя. Нәфис әдәбият, төрки телдә. Баштагы битләре төшкән. Күчереп язучы – Хәмит бине Ишимбай. Милади 1784 елда мелла Рәфыйк бине Уразай мәдрәсәсендә дусты Дәүләтшаһ бине Илбәк өчен язган.
Сакларга кирәк: XVII–XVIII йөздә Идел буе төрки әдәби теле үрнәге.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**70**

Мәҗлиси яки башкасы.

قصه سیف الملوک و بدیع الجمال منظومه

**«Кыссаи сәйфел мөлүк вә бәдигел җамал»**
12 сәхифә. Нәфис әдәбият. Төрки телдә. Мәҗлисинең тулы «Кыссаи Сәйфел мөлүк» чагыштырасы бар. Сакларга кирәк.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**71**

Шул ук.
1 кәгазь. Нәфис әдәбият, төрки. Теле харәзмиләр теленә бик якын. Чагыштырасы бар. Сакларга кирәк.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**72** (94)

تاريخ الاسلام – مختصر

**«Тарихел ислам – мохтәсар»**

89 кәгазь, 178 сәхифә. Тарих, тәрҗемәи хәл. Төрки. Борынгы Харәзм.
* 16×25. 93 бит. Кулъязма катыргы урыс кәгазьдә Идел буе җирлегендә төрле шәкелдәге филиграннар белән күчереп язылган. Күн кысалар белән эшләнгән катыргы тышлык. Аннотациядә мондый мәгълүмат бар: «Теле һәм тарихы ягыннан кирәкле китап».
Китап башында ике исемлек куелган: «Исемнәре аталган» һәм «Файдаланылган чыганаклар».



*Рис. 59.* Оттиск печати в рукописи «Тарихел ислам – мохтәсар». НМ РТ 18369-94, л. 4а

Бит санныры гарәпчә һәм европача куелган, кустодлар бар, кара каралар, вак каллиграфик нәсех. Бит кырыйларында кеше исемнәре, аларның туу һәм үлү даталары, шулай ук авторлар исемлеге белән хезмәтләре язылган. Башы юк. 4а битендә озынча түгәрәк кара мөһер эзе. Авторы һәм күчерү урыны күрсәтелмәгән.

**73**

قاضى محمد ابراهيم بن قاضى نور محمد

مجمع الاوراد

**Казый Мөхәммәд Ибраһим бине казый Нурмөхәммәд.**
**«Мәҗмәгел әүрад»**

Басма. 1293 һиҗридә басылган. 241 сәхифә. Салават һәм догалар, гарәп телендә. Искәрмә: бу китап, хаталык белән, кулъязмалар арасына теркәлгән.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**74** (76)

Тыйб китабы. 63 сәхифә. Төрки телдә. Башындагы битләре төшкән. Тел һәм сүзлеге әһәмиятле.
* 16×20,7. 188 сәхифә. Тышсыз. Җыентыкның 1а-32а битләрдә. Башы юк, кара каралар, язу рәвеше тәгъликъ, бит саннары музейдә куелган, кустодлар бар, кәгазе XIX гасырның икенче яртысына карый (штемпельләр).

**75** (76)

Хөтбәләр һәм вәгазьләр мәҗмугасы. 80 сәхифә. Әхлак һәм мәүгазә, гарәп һәм төрки телдә. Тел ягыннан әһәмиятле. 35а–72а битләр. Язу рәвеше нәсех.



*Рис. 60.* Фетвы муллы Валида б. мулла ʻАбд ар-Рахим и ал-хаджж Муртазы эфенде НМ РТ 18369-76, л. 66б–67а

**76** (76)

Билгесез. 30 сәхифә. Фикъһ һәм осуле гыйльме, гарәп телендә. Күчереп язучы һәм тарихы күрсәтелмәгән. Персия һәм Болгарда эшләнгән кайбер товарларның чирмәте (?) хакында сүз бара.

**77** (76)

محمد بركوى. جلاء القلوب

**Мөхәммәд Биргәви. «Җәлаэл колүб»**

84 сәхифә. Тәсаувыф, әхлак; гарәп телендә. Күчерүче һәм тарихы күрсәтелмәгән.

Җыентыктагы 113б–139а битләрдә. Күчереп язучының өстәмә язмасы 139б биттә: هلال الدين بن مرحوم ملا اسد الله («Һилаледдин бине мәрхүм мулла Әсәдулла»).

**78 (76)**

ابن سينا

مختصر من كتاب القانون فى الطب

**Ибн Сина. «Мохтәсар мин китабел канун фит тыйбб»**

62 сәхифә. Гыйльме тыйб, гарәп телендә. Күчерүче һәм тарихы күрсәтелмәгән. 82б–113а битләр.

**79 (76)**

حسام الدين بن شرف الدين البلغارى المسلمى

تواريخ بلغاريه

**Хисамеддин бине Шәрәфеддин әл-Болгари әл-Мөслими. «Тәварихе Болгария»**

90 сәхифә. Тарих, төрки телдә. Күчерүче һәм тарихы күрсәтелмәгән. Теле хәбәрләре ягыннан кирәкле. Җыентыктагы 142б–188 битләр. Ахыры юк.

**80**

**Хикәяте падишаһ Мөлтан һәм аның вәзире**

Гыйлем симия хакында кызыклы хикәя. 14 сәхифә. Нәфис әдәбият, төрки телдә. Күчереп язучы – Хөснеддин бине Габдулла әл-Янтугани. Сакларга. Буа мәдрәсәсендә язган. Хатын-кызга карашы белән әһәмиятле.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**81**

**Үзүм шәһәре патшасының Дәште Кыпчак кызына өйләнүе хакында хикәят**

Үзүм (Изүм) шәһәре хәзерге Харьков өлкәсендә яки Арча ягы Әтнә



районындагы каспә булыр. Әдәбият, төрки телдә. Күчереп язылуы тарихы билгесез. Бу кечкенә үзәкче тарих һәм тел ягыннан бик кызыклы хәбәрләрне белдерә. Сакларга.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**82 (99)**

Хикмәтле сүзләр, ырым-җырлар. Төрки-гарәп.

* 17×21,4. 140 бит. 1а–86 битләр.

Бергә: № 82–87. Бу китаплар Салавыч авылында Низамеддин хәзрәт мәдрәсәсендә 1876-77 елларда һәм бер китап Исмәгыйль авылында (елы күрсәтелмәгән) язылган. كاتبه نور محمد 76 سنه ده («Моны Нурмөхәммәд 76 нчы елда язды») дип язган.

Файдаланган әдәбият исемлеге Максудова тарафыннан төзелде. Кулъязма XIX гасырның икенче яртысына карый. Кара һәм күгелҗем. Язу рәвеше кызу нәсех, кустодлар бар, бит саннары соңрак куелган.



*Рис. 61.* Аннотация к рукописному сборнику. НМ РТ 18369-99

**83** (99)
Мәнзумә. 40 бит. Әхлак-фикъһ, төрки. Күчереп язучысы – Нурмөхәммәд бине Сәйфеддин. 1877 елда язылган.
* Җыентыктагы 9а–27б битләрдә.

**84** (99)

فريد الدين عطار. پند نامه

**Фәридеддин Гаттар. «Пәнднамә»**
58 кәгазь. Әхлак-тәсаувыф, фарсы. 1877–76 елларда, Салавыч авылында Низамеддин бине Сәлимҗан хәзрәт мәдрәсәсендә, бер китапны Исмәгыйль авылында язганын күрсәткән. Китапны Мөхәммәдкәрим әл-Мәчкәрәви әл-Бохари әл-Истанбулиның углы өчен язганы күрсәтелгән.
* 38а–66б битләр. Колофон 66б биттә:

كاتبه نور محمد بن سيف الدين المرحوم 1876 سنه ده 14 نجى ديكابردن غرفه كون

سنه 1876 تاريخ لاجل المخدوم داملا المچكروى داملا محمد كريم التكانشى مولدا و المچكروى تحصيلا ثم البخاره ثم و البتوى مسكنا و تدرسا ثم الاستانبول هجرةً توفى فى الاستانبولى رحمه الله تعالى و جميع المؤمنين و المؤمنات

Иске фиһрист буенча – № 73.

**85** (99)

يک حكايت

**«Йәк хикәят»**
14 бит. Фарсы телендә.
* Җыентыктагы 70а–76а битләр тулы булмаган төрки теленә тәрҗемәсе белән. Тәрҗемәченең колофоны шул ук ел астында.
Иске фиһрист буенча – № 74.



**86** (99)

بخار زاده

**«Бохара задә»**
13 кәгазь. Фикъһ, гарәп телендә.
* Җыентыктагы 77а–84а битләр.
Иске фиһрист буенча – № 75.

**87** (99)

محمد بن احمد سمرقندى. تحفة الملوك

**Мөхәммәд бине Әхмәд Сәмәрканди. «Төхфәтел мөлүк»**
63 кәгазь, Фикъһ, фәтава, гарәп телендә.
* Җыентыктагы 85а–115б битләр. Колофон 115б биттә:

اين كتاب تمام شد در وقت ضحى در مدرسة مولانا و ملا نظام الدين حضرة ده المرحوم قرية صلاوچ. كاتبه نور محمد الف (؟) مائة تسعين الثالث سنة

**88** (99)

تاج الدين بن يالچغل. شروط الصلوة

**Таҗеддин бине Ялчыгол. «Шөрутес саләт»**
10 кәгазь. Фикъһ, гарәп телендә.

**89** (99)
Төрле хәдисләр, риваятьләр. Әхлак, гарәп һәм фарсы телендә.
28а–37б битләр. Колофон 37б биттә:

1877 نجى سنه ده غينوار 14 نجى يومنده دوشنبه كون ساعت 11 نجى ده صلاوچ ده

**90** (90)
Тыйб китабыннан кисәкчә. Гарәп телендә. Мосаннифы, насихе, тарихы билгесез. XVIII йөз кәгазенә охшый. Күчерүче Габделвәһаб бине Мостафа.

* 16,5×20,7. 7 бит. Кәгазь тышлыгы. Җыентыктагы 1а–4б битләр. Калын урыс кәгазе XVIII гасыр ахырына карый, тәгъликъ, кара һәм кызыл каралар, европача пагинация, кустодлар. Су билгеләре күренми. Башы юк.

**91** (90)

Фәкыйрь карт белән фәкыйрь егет – суфилар хакында. Хикәят, мәнзумә. 60 юл. Әдәбият, төрки телдә. Габделваһаб Мостафа углы тарафыннан Минзәлә өязе Дәвек авылында мелла Бикчәнтәй бине Юлдаш мәдрәсәсендә язылган. Кәгазе XVIII йөзнекенә охшый. Фәкыйрь карт белән фәкыйрь (ике сукыр) егет хакында әдәби хикәя. XV–XVI йөз иҗаты булырга охшый.

* Җыентыктагы 4б–5б битләр. Колофон 5б биттә:

این کتاب روز شنبه شد تمام

نوشتم من عبد الواهاب بن مصطافى (!) و فى قرية دوک مدرسة ملا

بیکتچنتاى بن یولداش



*Рис. 62.* Колофон поэмы о суфиях. НМ РТ 18369-90, л. 5б

**92** (90)

Нөхсән (?) көннәр хакында мәнзумә. 11 юл. Төрки телдә әдәбият. 6б бит.

**93** (90)

Гыйлем өйрәнү, мал җыйнау хакында чагыштырма. 1 бит, төрки телдә әдәбият. Су билгесе 1736 елга охшый.



**93а** (90)

Әбҗәд хәрефләрендә кабатлау таблицасы. 1 бит. Гыйльме хисап, гарәп телендә.

**94** (89)

کتاب بهترین

**«Китаб бәһтәрин»**

Тәрҗемәче һәм насихе – Габделҗәмил Габделмәннан углы.

Мәнзумә, 16 бит. Әдәбият, гарәп, төрек һәм фарсы. Тәрҗемәне сүзгә-сүз эшләгән.

* 17×21. 8 бит. Тышсыз. Кулъязма XIX гасыр ахырына карый, бит саннары гарәпчә һәм европача куелган, кустодлар бар, урыс фабрика кәгазе. Сәхифә кырыйлары киселеп түгәрәгәйтелгән.

Иске фиһрист буенча – № 50.

**95** (30)

محمد بهاء الدين العاملى القزوينى.

سوانح الحجاز فى الترقى الى الحقيقة عن المجاز

**Мөхәммәд Бәһаәддин әл-Гамили әл-Казвини.**
**«Сәванихел хиҗаз фит тәрәкъкый иләл хакыйкать ганел мәҗаз».**

Мәнзумә, 36 сәхифә. Тәсаувыф, гарәп һәм фарсы. Алардан аерым сүзләр буенча төркигә тәрҗемә ителгән. Күчереп язучы һәм тәрҗемә итүче – Габделҗәмил Габделмәннан углы.

* 17×21,7. 17 бит. Кулдан ясалган тышлык, аннотация өске тышлыкта: «Идел буенда күп укылган, күп таралган китап. Сакларга». Татар язу рәвеше, кустодлар бар, бит саннары музейда куелган, кәгазе XIX гасыр башына карый, фарсыча поэма юлга-юл татарчага тәрҗемә ителгән. Ахыры юк.

Иске фиһрист буенча – № 49.

Автор хакында: GAL, II, 414-415; SII, 595.

Башка нөсхәләр:

فهرست نسخه های خطی کتابخانه بزرگ حضرت آية الله العطنمی مرعشی نجفی. قم. جلد سی ام. 1422. ص. 609–610

**96** (87)

Хәдис һәм хикәяләр мәҗмугасы. 30 сәхифә. Әхлак, мәүгазә, гарәп телендә. Язучысы һәм күчерү тарихы күрсәтелмәгән. Баштагы битләре төшкән.

* 17×21. 32 бит. Башы юк. Һәр өлеш өчен аерым бит саннары билгеләнгән, кустодлар бар. Кара һәм кызыл каралар. Язу рәвеше XVIII гасыр ахыры стилендәге тәгъликъ. Калын урыс кәгазе, су билгеләре юк. 15б биттә файдаланган чыганаклар язып куелган. Тышлыкны Максудова ясады. 2а биттәге язма каләм белән: «Бу китапны Хәлим абыем укыган икән».

**97** (87)

دله خاتون

**«Диләә хатын»**

Болгар чорыннан калган булырга охшый. 24 сәхифә. Нәфис әдәбият. Төрки телдә. Насихе – «фи карйяи Бәхтияр фи мәдрәсәи мелла Юлдаш бине Мөхәммәд», дип күрсәтелгән. Күчерелүе XVIII йөз башы булыр. Теле бик борынгы, сүзгә бай, тасвирлау чаралары күчле.

Җыентыктагы 17б–29а битләр. Колофон 29а биттә:

تمت تمام بعون الله الملک الوهاب فی قریه باختیار فی مدرسه ملا یولداش بن محمد



*Рис. 63.* Колофон в рукописи. НМ РТ 18369-87, л. 29а



**98** (87)

عمر روشانی چوپان نامه

**Гомәр Рәүшани. «Чупаннамә»**

5 сәхифә. Калган битләре югалган. Мәнзумә. Казан белән бәйләнеш аңлаткан мисраг бар. Нәфис әдәбият. Төрки телдә. Шул ук кешенең каләменә охшый. Күчерелүе XVIII гасырда булырга охшый. 8нче кәгазьдә 1820 елны күрсәткән саны бар – китапның күчерү елымы, укылган елымы. «Мәҗалисеш шәһүр» дән өзекчәләре бар («Мәҗалис» тәмам булган 1707 елда).

* Җыентыктагы 29б–31б битләрдә. Максудова тарафыннан бәетләр тәртибе төзәтелгән.

**99** (86)

بهترین

**«Бәһтәрин»**

Мәнзумә, гарәп телендә, 10 сәхифә. Әхлак, әдәбият. Гарәп, фарсы. Насихе күрсәтелмәгән. Кайбер сәхифәләрдә язучы: «Габделгалләм бине дамелла Фазлулла хаҗҗел хәрамәйн» дип имзалаган җире бар. Күчереп язылу вакыты XVIII йөзнең башында булырга кирәк.

* 16×20. Җыентыктагы 2а–6а битләр. Язу рәвеше нәсех һәм тәгъликъ, кәгазь XVIII гасыр башына карый, су билгеләре юк, бит саннары һәм кустодлар бар.

**100** (86)

قافية

**«Кафия»**

Мәнзумә. Барлык 68 хәрефкә беткән үрнәкләр мәҗмугасы. 18 сәхифә. Әхлак. Гарәп, фарсы. Төрки сүзлеге бар.

* Җыентыктагы 6а–15а битләр.



*Рис. 64.* Аннотация к рукописному сборнику. НМ РТ 18369-86

**101** (86)
Касыйдә. 4 бит. Әхлак, гарәп телендә.
* Җыентыктагы 17б–26б битләр.



**102** (86)
Касыйдәи бурдә. 30 сәхифә. Тәсаувыф, гарәп.

**103** (86)

فريد الدين عطار. پند نامهء عطار

**Фәридәддин Гаттар. «Панднамәи Гаттар»**
60 сәхифә. Тәсаувыф, әхлак. Фарсы телендә. Насихе, тарихы күрсәтелмәгән. Күчереп язулары XVIII йөз башында булырга кирәк. Һәр сәхифәдә 16 юл.
* Җыентыктагы 27б–57б битләр.

**104** (86)

عمر روشانى. چوپان داستانى

**Гомәр Рәүшани. «Чупан дастаны»**
Авторы 1487 миладида вафат булган. Җәләледдин Руминең «Мәснәви»дән тәрҗемә, Казан белән багланышны күрсәткән мисраглар бар. 29 сәхифә. Нәфис әдәбият. Төрки телдә. 99–104 номерлар, барысы да бер төбендә. Барысы да мәнзумә әсәрләр. Бу әсәр Крымок (?) тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителгән.
* Җыентыктагы 57б–71б битләр.

**105** (2)

خواجه مير سيد – عياث الدين محمد بن خواجه سيد.

كتاب مير سيد شريف

**Хуҗа Мирсәед – Гыяседдин Мөхәммәд бине Хуҗа Сәед. «Китаб Мирсәед Шәриф»**
Солтан Ходабәндәнең әмире, вафат һиҗри 766 ел. 180 сәхифә. Гарәп телендә. Күчереп язучы – Габделҗәмил Габделмәннан углы Максудов, Тирсә авылында Ягъкуб бине Нигъмәтулла мәдрәсәсендә 1848–1852 елларда язган. Үземнең әткәем була. Бу китаптан абыйларым Габделхәким, Габдеррәхман Бубидә укыганда файдаланганнар. Бергә төпләнгән, яхшы сакланган.

* 16,5×21,3. Яртылаш күн тышлыгы, өске каплавычы ябыштырылган аннотациядә мондый мәгълүмат бирелә: «Һамишендә Габдулла Бубыйның «Басыйрәт» исемле китабына иснад бар. Зәйнәп Максудова».
Китап каплавычлары төрле кулъязма битләреннән ясалган.
Мәхәббәт дастаны, төзелгән 1411 милади, 813 һиҗридә. Бер нөсхәсе белән музейда саклана. 57 кәгазь. Нәфис әдәбият. Төрки телдә. XV йөз төрки нәфис әдәбиятында сирәк очрый торган хатирә. Кайда, кайчан, кем язганы билгесез. Әмма рәсем хаты буенча Идел Җаек

буе төрки әдипләреннән берсе тарафыннан язылган дип уйларга туры килә. Тарихы XV йөздә булырга охшый.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

195
Еракка киткән кызның сагыну бәете. XIX йөз. 2 сәхифә. Кече кул. Нәфис әдәбият. Төрки телдә. Кайчан, кайда, кем күчереп язганы билгесез. Бу бәетне Мәхбүбә бинте Сөендек бине Габделгазиз Нарат авылыннан Ырынбур губернасы Боры өязе Карабаш авылында Габделкаюм Исламгол углына никахланып киткәч, сагыну тәэсирендә төзегән. Ләкин, ни гаҗәптер, бу шигырь Г.Кандалыйның иҗади мәҗмугасында урнашкан.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

196

عصام الدين بن داملا جمال الدين

**Гыйсамеддин бине дамелла Җамаледдин**
Сәгъдеддин бәете. 25 бәет. 1828 елда төзелгән. 2 сәхифә. XIX йөз. Нәфис әдәбият. Төрки телдә. 1828 елда төзелгән һәм шул елда язылган булыр.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

197 (39)
Мәҗмуга. Нәфис әдәбият. Төрки телдә. Барысы да бер җилддә теркәлгән. Бер кул белән язылган:
а) Такый гаҗәп мәнзумәсе. 13 сәхифә.
б) Фирүшә бине Сатылган. Илаһи бәет мәнзумәсе. 2 сәхифә. Хыянәтче Габдеррәфигъ кантун хакында.
в) Мәрьям ана мәнзумәсе. 2 сәхифә.
г) Мәхбүбләргә сәлам мәнзумәсе. 1 сәхифә.
д) Әүвәл хакны яратылдым, улдым рәхмән. 11 сәхифә.
е) Рузә хасыяте һәм савабы хакында вәгазь. 4 сәхифә.
ж) Хәдисләр мәҗмугасы. 14 сәхифә. 1792 елда дуңгыз елында язылганы күрсәтелгән. Нигъмәтулла бине Сәгыйд өчен дип.
з) Төрле чирләрдән догалар. 30 сәхифә. 1791 елда язылганы күрсәтелгән.



198 (39)
Дарулыклар хакында. 16 сәхифә. Тыйб гыйлеменнән. Төрки телдә. Кайда, кайчан, кем язганы билгесез.
* 17,4×21. صاحب حافظ بوحارين («Сахиб Хафиз Бухарин»). Төрки телдә. Язу рәвеше нәсех.



*Рис. 93.* Сочинение по медицине на татарском языке. НМ РТ 18369-39, л. 16

**199**

## ابن الوردى. خريدة العجائب و خريدة الهرائب

**Ибне әл-Вәрди. «Хәридәтел гаҗәиб вә хәридәтел һәраиб»**
16 сәхифә. XIV йөз. Гомуми география. Гарәп телендә. Кайда, кайчан, кем күчергәне билгесез.

---

**200** (44)
Коръән Кәрим. Кулъязма. 64 кәгазь. 8 дәфтәр. Су билгесе буенча XVII йөз язмасы булырга охшый. Красный Бор районы Уразай авылында мөгаллимлек һәм имамлык иткән Габделҗәмил Габделмәннан углы Максудов (1832–1923 еллар) китапханәсеннән.




*Рис. 94.* Аннотация к списку Корана. НМ РТ 18369-200



* 16,5×19,5. «Әгъраф»тән «Хәҗәр»гә хәтле. Кызыл һәм кара каралар. Хәрәкәтләр бар. Аятләр кызыл түгәрәкләр белән аерылган. Язу рәвеше каллиграфик нәсех.

---

**201** (2113Т)

## منهاج الدين بن سيف الدين البلغارى. تواريخ خاقانيه و بلغاريه

**Минһаҗеддин бине Сәйфеддин әл-Болгари.**
**«Тәварихе Хакания вә Болгария»**
Зәй өязе Бәчук авылы мөгаллиме һәм имамы. XIX йөз.
Бу китапның төп кулъязмасы Казан дәүләт дарелфөнүннең Шәрык язмалары хәзинәсенә бирдем. Тарих. Төрки телдә. 1878 миладида тәэлиф ителгән. 75 кәгазь. Шуннан күчереп, үз кулым белән язылган нөсхә үземдә саклана. Татар-болгар хакында кызыклы хәбәрләр бар.
* 21×35. Бу китапны университетка Максудова 1962 елда тапшырган. Кара каралар, кустодлар юк.
Китапның эчендә:

/1a/ مناقب حضرت ايشان تونتارى
از تحريرات علامة الزمان داملا فحر الدين نورلاطى الجبلى

/1б/
ايجازت نامه
مر حضرت ايشان تونترى از براى تعليم دادن علم ظاهر
... و بعد فان الاخ العالم العامل و الفاضل الكامل و الصديق الصالح
و الحميم المفح المولى على بن سيف الله البلغارى موطنا و التنتارى
مولدا... فاجزت العالم المذكور باسناد المشهور بصحيح الامام البخارى و
مشكوة المصابيح و كتاب الشفا و باقى (؟) الكتاب الستة كما اجازنى
اساتذتنا الكرام و مشايخنا العظام عليهم رحمة الله الملك العلام منهم
سيدى و استادى الحافظ محمد عباس السرهندى الجهانى آبادى من

شيخنا المولوى عبد العزيز الجهان آبادى من شيخه و ابيه شاه ولى
الله المحدث من شيخه نور الحق ابن الشيخ عبد الحق الدهلوى شارح
المشكوة الى آخر الاسناد
و منهم شيخنا و صاحبنا السيد محمد مسعود مفتى دياربكرى عن ابيه
الخاجى (!) صبغة الله افندى عن ابيه المشتهر فى الافاق باحمد كوچك
زاده محشى البيضاوى عن عبد الكريم القينوى الى آخر الاسناد
و منهم شيخ المولى احمد فايز طرابزانى و مدرس سليمانيه فى
القسطنطنية عن حاجى يوسف البحرى عن سيد مرتضى الزبيدى المصرى
شارح القاموس و الاحيا
و منهم شيخنا و صاحبنا سيد السادات و مبنع البركات علامة الورى
ذو النسب و الحسب الباهر النقيب على الاشراف السيد احمد عارف
المشتهر بحكمة الله الحسنى الاستنبولى عن شيخه علامة المكة المكرمة
الشيخ عمر بن عبد الرسول عن شيخه علامة مدينة الرسول الصالح
الفلانى
و منهم شيخى و سيد و سندى و ثقتى و عمدتى الجهبذ النحرير مدرس
مدينة الرسول فى هذا الزمان الشيخ محمد عابد السندى الخزرجى
الايونى عن شيخه صالح الفلانى الى آخر الاسناد.
... كتبه بقلمه و قاله بفمه العبد الحقير المنتقر الى رحمة الله محمد
خليل ابن محمد عفران الله ابن محمد رضوان الله ابن محمد برهان الله
ابن شيخ نور الاحد ابن شيخ محمد فقير الله ابن حضرت شاه محمد
يحى ابن الامام حضرت شيخ احمد فاروقى السرهندى النقشبندى قدس
الله تعالى اسرارهم



/2a/
شجرة ... حضرت نقشبنديه
قدس الله تعالى اسرارهم
بسم الله الرحمن الرحيم
... حضرت خواجه محمد پارسا منه حضرت خواجه محمد رسا منه و من
حضرت شيخ عبد الله جناب قطب الاقطاب حضرت شاه فضل احمد
معصومى منه قطب العارفين غوث السالكين حضرت غلام قادر معصومى
منه حضرت ايشان على محمد تونترى

Түгәрәк мөһернең укылышы:

غلام قادر معصوم
/72a/
... شجرهء صوفيه ايدوب ظهور ايدن سلسلهء عبد الخالق العجدوانى ده
اولان طريقهء نقشبنديه حوجكان حضرتلارى ننك طريقهء حفيه عليه
رضيه مشهوره ده تخليه و تخليه نيتى برله قلبا الله ديب من منهاج
الدين سيف الله اوغلى بچک ده امام اصل وطن ترک جمله سندن
اولان ممادش ايلندن باباى لار اون ايكى كمسنه امام بولوب اوتكانلردور
بر رساله تآليف ايدوب كندو نسل لارمز و همشرلارمزنى بيان و عيان
ايتكماک نيتى برله بو كتاب منتخب فى احوال اتراک المختلفه فى ارض
البلغار و التاتار ديو اسم ويروب تواريخ قديمه دن ايسكى مزازلارده
اولان طاشلار حكاية بوينچه و قديم الفاظ و لغات بوينچه و تاتارلارنک
محاورات استعمال ايتدوک كلمات و الفاظلارندين فهم ايدوب و كتب
تواريخ دن و لغات كتابلارندين و بفض ترجمهء تركدن اخذ و فهم و
تفكر ايدوب جمع و تصنيف ايتدم عربى نصاب الانتهار رساله سى

ترجمهء قاموس اولان او قيانوس كتابى ترجمهء برهان قاطع اولان تابيغ
نافع و معرفة نامه كتاب لاريدر و طبريه تاريخ اولان تواريخ طبريه دور
اما اوزمز تونتر على محمد بن سيف الله مدرسه سنده تعليم آلوب
صرف و نحو و منطق و فلاسوف و حكمة العين و كلام و اصول
توضيح كتابى و باشقه ... و مغان برآز استماع ايدوب تلحيص و مطول
درسلارنده و بويله حاضر و استماع ايدك مسائل فنه دن هدايه شرح
وقايه و مختصر و صديق دن مشكات مصابيح مدة استماع ايدوب فن
تصوف دن طريقه محمديه و حامم و مراد العارفين و مسلك المتقين
كتاب لارون درس آلوب الله الحمد مذكور حضرت ايشان ننک كند و
حياتنده رخصتى برله طاو طرفنه بچک اصل ده بيجک اولنه امام اولوب
تذكرهء خيريه و صدقهء جاريه بولسه ايدى ديو تآليف ايتدم مذكور
حضرت ايشان اوتوز سنه مقدار تحصيل علم الظاهر و الباطن ايتكان
هندوستان مملكتنده و بخارى شريفده قزان مملكتلارينه رجوع ايدوب
قرق ايلى يل مقدار درس ايتكان علم الظاهر دن و علم الباطن دن كنه
اوزى مجاز كمسنه دور حط ارشاد برله علم الظاهر و علم الباطن ايچون
توقسان ياشاب رجب اون بشنده جمعه كون وافات هم مدفوندر كه
تونر قريه سنده رحمة الله عليه رحمة واسعة مدفون صونک مناقب
حضرت ايشان يازلور

**202** (202)

**Сөләйман бине Дауд Сәксини әс-Сувари әл-Болгари** (вафаты XII йөзнең соңгы яртысында).

Хәллаҗ Мансурның үлүе хакында мәнзумә. Баштагы бит төшкән. 30 сәхифә. Һәр биттә 17 юл. Бер мисрагта «Бу Сөләйман мәдех итсен аны» дип үзенең исемен белдергән. Тарихи әдәбият. Болгар төрки теле. Нарат авылы имамы Габдессәттар б. Сөендек бине Габделгазиз бине Гайсә әл-Көнәри китаплары арасыннан табылган. Миңа 1965 елның июль аенда тапшырылды. Теле бик бай, бик борынгы, XII йөз Болгар теле.

* 16,5×21. Язу татар тәгълиге, кара каралар. Ахыры 20б биттә:

چونكه بو سوز بوراده اولدى تمام * دكه رسول الصلوة و السلام
در مدح جلال الدين رمى قدس سره العزيز
تمت تمام شد است

Ахыргы битләрдә булган аңлатмалар: «Бу китап өстендә эшләнәчәк эшләр бәяне:

1) XII йөз болгар-саксин галиме, шагыйрь Таҗелислам Сөйләман бине Даудның «Сиррен нәби» Мөхәммәд галәйһиссәламнең тәрҗемәи хәле хакындагы дастан буенча борынгы болгар теле(нең) сүзлек байлыгының сүз теркемәләре һәм әдәбият мирасы булуы ягыннан әһәмиятле.

2) Шул ук әсәрдә кулланган тел, бизәү сүзләре: синонимнар, антонимнар, чагыштыру, тикләштерү, тәҗсим, тәүсыйф чаралары: фигыль формалары, җөмлә төзелеше, җөмлә төрләре, авазлар составы, XII йөз шагыйре Сөләйман бине Даудның шигърияте урын таба.

Бу китап һәм аның язучысы хакында мәгълүмат: «Мөстәфад», 1 ж., 82–80 с., «Дәлаилен нәбүвәт», «Алты бармак», Мөхәммәд бине Мөхәммәд Чокрый Ғализадә.

Бу әсәр, тәрҗемә буларак, Идел буе төрки шагыйрь Сөләйман бине Дауд Саксининең иҗаты булыр. Төзелү чоры һиҗри VI–VII, ихтимал XII йөзнең азагында булыр. Бу китапны элгәреге Вятка губернасы Сарапул өязе Нарат авылында имам булып торган Габдессәттар бине Сөендек (1793–1878) буыны балалары кулында сакланган. Миңа 1965 ел июль аенда тапшырылды. Бу китап Габдессәттар бабайга үзенең атасының атасы Гайсә мелла Көнәридән калган булган (Гайсә мелла Көнәри, аның углы Габделгазиз Кушлавыч мелласы, аның угыллары: Фәез – Кышкар мөдәррисе, Габид – Орнашбашы авылында мөдәррис, Сөендек Нарат авылында имам һәм мөгаллим булганнар. Алар хакында Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел әхбар»дә, Хөсәен Әмирханның «Тәварихе Болгария»сендә хәбәрләр язылган.

**203** **(202)**

**Сөләйман бине Дауд Сәксини әс-Сувари әл-Болгари**

Мөхәммәд галәйһиссәламнең тарихы – тәрҗемәи хәле хакында мәнзумә. 50 сәхифә. Тарихи-дини әдәбият. Болгар-төрки телдә.

**204** **(186)**

Намаз кагыйдәләре. 8 кәгазь. Дин. Гарәп телендә. Насихе һәм тарихы билгесез. Кәгазьдә су билгесе 1801 елгы.

* 11×17. Кәгазь тышлы. Җизнәбез Габделәхәд бине Фәйзулла Мазарасты имамы күчергән. Бу кулъязмалар Нарат авылыннан Габдессәттар мелла бабай балаларыннан кайтты.

**205** **(186)**

Тормыш әдәпләре мәҗмугасы. 22 кәгазь. Әхлак хикәяләре. Төрки телдә. Насихе һәм тарихы билгесез. Кәгазьдә су билгесе 1815 елгы.

**206**

Нәфел гыйбадәтләр хасыяте хакында. 30 кәгазь. Дини киңәшләр. Төрки телдә. Насихе һәм тарихы билгесез. Кәгазьдә су билгесе юк, бик борынгы.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**207**

Ахыр заман – Тәкый гаҗәп мәнзумә. 7 кәгазь. Насихе һәм тарихы билгесез. Кәгазьдә су билгесе юк, бик борынгы.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**208**

Бәдәвам мәнзумә. 4 кәгазь. Төрки телдә. Әхлак-дини. Насихе һәм тарихы билгесез. Кәгазьдә су билгесе юк, бик борынгы.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.



**209** **(122)**

على القارى بن سلطان محمد الهروى. شرح النقاية

**Гали әл-Кари бине Солтан Мөхәммәд әл-Һәрәви. «Шәрхен никая»**

834 сәхифә. Гарәп телендә. Вакыты ачык күрсәтелмәгән, кәгазьнең су билгесе 1814 елны күрсәтә. Миңа Нарат авылында атам ягыннан бабам Габдессәтар бине Сөендек бине Габделгазиз бине



*Рис. 95.* Аннотация к рукописи. НМ РТ 18369-122

Гайсә әл-Көнаринең 4 нче буын баласы Галимә Закирова аркылы тапшырылды.
Күчереп язучының тулы исеме күрсәтелмәгән. Фәкать ике сәхифәнең һәмишендә: 1) تحرير فقير البلغارى («Тәхрир фәкыйрь әл-Болгари язуы»), 2) كاصايدا اوكازنوى ملا... («Касайда указной мелла...»). Карадым. «Арслан Гали Габдессәттар углының милкендә» дигән сүзләр бар китапның башында. Бу китап 1966 елның 10 мартында Әгәрҗе районы Нарат авылында яшәгән Галимә Закирова тарафыннан җибәрелгән. Мәхсус посылка белән алынды.
* 21,5×33,3. Фикһ. Күн тышлыгы, яхшы сакланган. Язу рәвеше вак нәсех, кара һәм кызыл каралар, кустодлар бар.

---

**210** (100)

محمد بن عثمان البلخى. عين العلم

**Мөхәммәд бине Госман әл-Балхи. «Гайнел гыйлем»**
Әхлак, тәсаувыф. Гарәп телендә. 1854 елда Тирсәдә Ягъкуп бине Нигъмәтулла мәдрәсәсендә мелла Низамеддин Гомәр бине Бикбулат (Мазарасты кешесе) кулы белән күчерелгән. Азагында кызыклы бер әкият бар.
* 175×21. 101 бит. 1а биттә өстәмә язма бар:

1856 نچى يلده حمل ننک (؟) 30 نچى كوننده منزله اويازنده بيک باؤ
آؤلنده عبد العليم حضرة مدرسه سنده توردقم زمانده واتكه غوبرناسى
نک الآبوعه اوكروكا سى ننک ديو ترنه آولى ننک من عمر بک بلاط
اوغلى يازوب قولوم قويدوم

(«1856 елда хәмәлнең 30нчы көнендә Минзәлә өязендә Бикбау авылында Габделгалим хәзрәт мәдрәсәсендә тордыгым заманда Вәткә губернасының Алабуга округасының дию Тирнәнең мин Гомәрбәк Булат углы язып кулым куйдым»).
Язма 2а биттә:

1867 نچى يلده ماى چسله سى نک ايلان ايكى مدينه كشى لارى
يوريديلار برسينک ايسمى حاجى محمد بن حاجى ابراهيم حضرة



*Рис. 96.* Владельческие записи в рукописи. НМ РТ 18369-100, л. 1а



*Рис. 97.* Владельческие записи в рукописи. НМ РТ 18369-100, л. 2а

ایکنجی ننک ایسمی محمود بن حاجی احمد
رسول ننک مسجدنده مجاور هم سید زاده لار دیدی

(«1867 елда май числосының илән ике Мәдинә кешеләре йөрделәр. Берсенең исеме – хаҗи Мөхәммәд бине хаҗи Ибраһим хәзрәт, икенчесенең исеме Мәхмүд бине хаҗи Әхмәд. Рәсүлнең мәсҗедендә мөҗәвир вә сәедзадәләр диде»).
Язу рәвеше нәсех, кара каралар, кустодлар, соңгы пагинация. Калын урыс кәгазе XIX гасыр уртасына карый. Колофон 99б биттә:

تمت الکتاب بعون الله الملك الوهاب فی مدرسه استاذنا و مولانا داملا
یعقوب بن نعمة الله مرحوم قریه تیرسه و فی ید ملا نظام عمر بن
بیک بلاط و فی قریه مذار آستی // 1854 نجی سنه ده

(«Аллаһы ярдәме белән бу китаб остазыбыз Ягъкуб бине Нигъмәтулла мәрхүм карья Тирсә мәдрәсәсендә һәм мелла Низам Гомәр бине Булат Мазарасты карьясендә 1854 елда тәмам булды»).

**211** (105)

عقود منظومه

**«Гокуде мәнзумә»**

Фикъһ, гыйбадәт, гарәп телендә. Кайда, кем тарафыннан күчерелүе, елы билгесез. Кәгазьнең беренче битенең су билгесе 1808 елны күрсәтә.
* 17×21,6. 98 бит. 2а биттә Максудова тарафыннан әдәбият исемлеге төзелгән. Нәсех язу рәвеше, кустодлар бар. Бит саннары соңрак куелган. Кара һәм кызыл каралар.

**212**

صوفی الله یار. مسلك المتقین

**Суфый Аллаһияр. «Мәсләкел мөттәкыйн»**

198 кәгазь, фарсы телендә. Ислам фикъһы. Төхфәтулла бине мелла Җәгъфәр бине мелла Хәлил кулы белән күчереп язылганы күрсәтелгән. Китапның фиһристе алдында һәм азагында, шулай ук, бит араларында бик күп гарәп һәм фарсы телдә язылган фикъһ, фәтва китапларыннан, лөгать китапларыннан күчерелгән искәрмәләр теркәлгән. Тарих тәсанифе һәм тарих нәсхе-китабәте күрсәтелмәгән. Шулай да XVII йөз азагында төзелгән дип уйларга күп мөмкинлекләр бар (файдаланган китаплар буенча). Күчерелүе XVIII йөз башларында булып, Төхфәтулла бине Хәлил бине Сәгыйт әс-Сомаки түгелме икән? Бу кеше вафат булган һиҗри 1283, милади 1867 елда. Бу кеше Уфада казый булып торган.
* Бу кульязма архивларда табылмады.

**213**

Исеме намәгълүм. XVIII йөз әсәре. Төрки, гарәп, фарсы телендә өзекчәләр. Болгар халкының исламият кабул итү тарихы, мәгълүм Хуҗа Хваризминең тәрҗемәи хәле, Сонкыр исемле бер вәзирнең Казан ханәтенә һәм Болгар ханәтенә хезмәт итүе хакында, Болгар шәһәренең төзелүе хакында. 4 сәхифә.
Тарихи хәбәрләр. Мосаннифнең, күчереп язучының исемнәре һәм тарихы күрсәтелмәгән. Кәгазе XVIII йөз эшенә охшый. Күчереп язучы Ишнияз бине Ширнияз исемле остаздан ишеткәнен күрсәткән. Ишнияз бине Ширнияз бине Ярмөхәммәд Үргәнечтә туган, аннан килеп Казаклар авылында, соңра Каргалыга күчеп мөдәррислек иткән һәм шунда һиҗри 1205, милади 1791 елда вафат булган («Мөстәфад», 2, с. 216). Бу кешенең «Гакаид Болгария» исемендә төрки бер тәсанифе булган. Аның шәкертләреннән берсе мелла Сәгыйд бине Ибраһим Барышый Идел буе татарлары арасында мәшһүр мөдәррис булып, вафаты һиҗри 1229, милади 1812 елда («Вәфиятел әслаф»). Бу кешенең әсәрләреннән берсе җирнең түгәрәклеген исбат кылып язган китабы мәшһүр.
* Бу кульязма архивларда табылмады.

**214**

Исеме мәгълүм түгел. Гарәп, фарсы, төрки телләрдәге вак әсәрләр мәҗмугасы. 24 сәхифә. Ислам гакыйдәсе, гыйбадәт кагыйдәләре. Төрки, гарәп. Сибгатулла б. Лотфулла кулы белән гаять ямьсез каләм, хаталы имля белән язылган. Арада кайбер җырлар да бар.

Язу тарихы күрсәтелмәгән, шулай да XIX йөзнең урталарында язылган булуы ихтимал. Барлыгы бер кечкенә кул мәҗмугадә беркетелгән.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**215**
Назыймы бик борынгы зат булыр, чөнки сүзләре һәм сүз төзелеш калыплары шуңар дәляләт кыла.
Исеме билгесез мәнзумә. 8 кәгазь. Әхлак. Төрки телдә, иске сүзләре күп. Назыйме, насихе, тарихы билгесез. Күчерүе XIX йөздә дип чамалана. «Язучы Вәлид» дигән сүзе бар. 7 кәгазьдә кайбер әдәби гадәт юллар да язылган.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**216**
(язылмаган)

**217** (78а)

مجالس الشهور. مصنف شیخ احمد بن شیخ محمد اعرج الواعظ

**Шәех Әхмәд бине шәех Мөхәммәд Игъраҗ әл-Вагыйз. «Мәҗалисеш шөһүр»**
142 кәгазь. Мәүгазәләр мәҗмугасы. Гарәп телендә. 1845 елда Хәбибулла улы Фәзлулла кулы белән күчереп язылган.
* 16,7×20,8. Тышлыгы юк, гарәп телендә, кара һәм кызыл каралар, бит саннары соңрак куелган, кустодлар бар, язу рәвеше нәсех, башы юк, каты урыс кәгазе XIX гасыр башына карый.
Колофон 141б биттә:

فرغتُ من تسوید هذه النسخة الشریفة المسمی بمجالس الشهور فی
سنه 1845 یلده ماه ربیع الاول ننک 9 نچی یومنده فی ید فضل الله بن
حبیب الله الاواجی (؟)
نظام الدین بن ملا فضل الله

(«Бу «Мәҗалисеш шөһүр» нөсхәнең күчерүе Фазлулла бине Хәбибулла әл-Әваҗи (?) кулы белән 1845 елның Рабигыләүвәл аеның 9нчы көнендә тәмам булды. Низамеддин бине мелла Фазлулла»).

**218** (70)

شیخ بن عیسی. فصول عشرة

**Шәех бине Гайса. «Фөсуле гашәрә»**
63 кәгазь. Ике язма белән бергә: Тәсриф. Төрки Казан теле. Күчереп язучының исеме һәм язу тарихы билгесез, ләкин рәсем хат һәм кәгазьнең борынгылыгы аның XVIII йөз мирасы булганын күрсәтә. Имлясы дөрест, каләме гүзәл.
* 16,7×22. 112+1 бит. Катыргы тышлык (өске каплавычы юк).

**219** (70)

فتوحات الهی شیخ صاموری الهندی اثری

**«Фөтүхате илаһи»**
Шәех Самури Һиндидән тәрҗемә. Казан төрки теле. Күчереп язучының исеме, тарихы юк. Соңгы сәхифәләре югалган.
* 64б–80б сәхифәләр, ахыры юк.



*Рис. 98.* Разворот рукописи. НМ РТ 18369-70, л. 2а

**220** (70)

نعمة الله بن عمر الاوتارى القازانى رسالهء مدنية

**Нигъмәтулла бине Гомәр әл-Утарый әл-Казани**
**«Рисаләи Мәдәния»**
Тәрҗемәи хәле Ш. Мәрҗани «Мөстәфад»ында һәм «Вәфия»сендә язылган. Вафаты һиҗри 1232, милади 1820 елда, Истанбул шәһәрендә. Солтан Сәлимхан исеменә багышлап Мәдинә шәһәрендә төзелгән. 32 кәгазь. Тәсаувыф китабы, гарәп телендә. Кем тарафыннан, кайчан күчерелүе билгесез, чөнки соңгы сәхифәсе төшкән. Каләме гаять матур, имлясы бик дөрес.
* 81б–112б битләр. Ахыры юк. Кәгазе XIX гасырның икенче яртысына карый (штемпель Фабрики Кувшинова № 5), язу рәвеше тәгъликъ. Кара каралар, кустодлар бар.

**221** (97)

محشى سيد على بن محمد البخارى. حاشية على الفوائد الضيائية

**Мохши Сәед Гали бине Мөхәммәд әл-Бохари.**
**«Хашия галәл фәваидез зыяия»**
Гарәп нәхүе. Гарәп телендә. Мөнасиб бине мелла Муса тарафыннан күчерелгән.
* 17×21,7. 123 бит. Каплавычның тышлыгы юк.



*Рис. 99.* Колофон в рукописи. НМ РТ 18369-97, л. 10б



**222** (97)

شرح على الفوائد الضيائية

**«Шәрхе галәл фәваидез зыяия»**
Шәрехләүче Мөхәммәд Гыйсмәтулла бине Мәхмүд. Гарәп нәхүе. Гарәп телендә. Күчерүченең исеме, тарихы билгесез, чөнки азактагы битләре төшкән. Кәгазендә 1797 елның су билгесе бар. Каләме гүзәл, имлясы бик дөрес.
* 14б–123б сәхифәләр. Язу рәвеше вак тәгъликъ, кара һәм кызыл каралар. 123б биттә китап хуҗасының исеме бар: ملا علاء الدين («Мулла Галәведдин»).
124а биттә тагын бер хуҗаның кулы куелган:

1855 نچى يل من عبد الرقيب ملا عبد الرشيد اوغلى آلدم

(«1855 ел мин, Габдеракыйб мелла Габдеррәшид углы, алдым»).

**223** (7)

ابو حفظ عمر. عوامل

**Әбу Хифз Гомәр «Гавамил»**
10 кәгазь. Гарәп нәхүе, гарәп телендә. Күчереп язучының исеме күрсәтелмәгән. Тарихы да юк, ләкин кәгазе бик борынгы, XVII йөз кәгазе.
* 16,5×20,5. 3+98+2 бит. 1а биттә китап иясенең язмасы бар:

متملكه عبد الله بن عطأ الله المرحوم القازانى تولداً و توطناً نفعنا الله
تعالى به نفعاً تامّاً آمين بحرمة محمد الامين
صلى الله تعالى عليه و على آله و سلم

(«Габдулла бине Гатаулла әл-мәрхүм әл-Казани тәвәллүдән вә тәваннынан милкенә керде. Аллаһы Тәгалә файдалы гыйлем алырга насыйп итсен...»).
1б биттә: штемпель «Медянск.фаб. Первушина №8». 9б–10а сәхифәләрдә фарсыча аңлатмалар бар.

## 224 (7)

عبد القاهر بن عبد الرحمن الجرجانى. عوامل المائة

**Габделкаһир бине Габдеррахман әл-Җөрҗани. «Гавамилел миъә»**

* Гарәп нәхүе, гарәп телендә. 13б–46б сәхифәләр.

---

## 225 (8)

محمد القدقى .تركيب و عوامل مائة

**Мөхәммәд әл-Кодкый «Тәркиб вә гавамил миъә»**

* 49 кәгазь. Күчереп язучының исеме һәм язу елы күрсәтелмәгән, ләкин кәгазенә һәм рәсем хатына карап, XVIII йөз мирасына охшый. Гарәп теленнән тәрҗемәсе.

Текстның ахырында, 97б сәхифәсендә иясенең өстәмә язмасы:

اوشبو كتاب ابو بكر....

Аннары фарсыча дүрт юллы шигырь язылган.

Китап хуҗасының язмасы 98а сәхифәсендә:

صاحبه عبدالله بن فلان فلانوف تم

(«Моның иясе –Габдулла бине Фәлән Фәләнов. Тәмам»).

98б сәхифәсендә шәех Габделкаһир әл-Җөрҗанигә багышланган шигырьләр язылган.

---

## 226 (8)

محمد بركوى. طريقه محمديه

**Мөхәммәд Бәркәви (Биргиви). «Тарика Мөхәммәдия»**

132 кәгазь. Әхлак. Гарәп телендә. Һиҗри 1163, милади 1750 елда кыпчак төркисе Әкизләр кабиләсеннән Таман шәһәрендә язучы Госман бине Мостафа Трабзони тарафыннан күчереп язылган. Гаять гүзәл, вак сөлес рәсем хаты белән язылган. Һамишендә искәрмәләр күп.

* 14×21. 3+136+4 бит. Юка голланд кәгазе, су билгеләре: CASTRES LANGVEDOC





*Рис. 100.* Примечания З. Максудовой к колофону рукописи. НМ РТ 18369-8, л. 136б

3б сәхифәдә элекке китапханәдә булган номеры куелган:
121 نومر
3б-4б сәхифәләрдә китап эчтәлеге күрсәтелгән. 5а сәхифәдә өч урында кызыл мөһернең эзләре күренә, укылышы:
محمد شاكر القورصاوی («Мөхәммәдшакир әл-Курсави»). Текстның зурлыгы: 7,5×15,2.
136б сәхифәдә колофоны бар:

تمت الكتاب بعون الله الملك الوهاب
فی يد عثمان بن مصطفى الطرابزونی من
قبيلة اكيزلر الآن ساكن فی الطمان
غفرالله له و لوالديه و لاساتيذه
و احسن اليهم و اليه
فی سنة ثلث و ستين
و مائة و الف
فی شهر جمادی
الاول

(«Аллаһының ярдәме белән ошбу китаб Әкизләр кабиләсеннән хәзер Таманда яшәүче Госман бине Мостафа әт-Трабзони кулы белән тәмам булды… 1163 елның Җөмадиәл әүвәл аенда»).
Карагыз: GAL, II, 440-441.

---

**227** (79)

شيخ شرف الدين محمد ابو عبد الله الموصلی. قصيدهء برده

**Шәех Шәрәфеддин Мөхәммәд Әбү Габдуллаһ әл-Мөсалли. «Касыйдәи Бөрдә»**

58 кәгазь. Мөхәммәд галәйһиссәламгә салават һәм мәдхияләр мәҗмугасы. Гарәп телендә. Язучының иseme һәм язу елы күрсәтелмәгән. Кәгазь нәфис, юка. Җефәк чәчәктән эшләнгән әгъла кәгазь. Язуы матур, гади. Идел буе рәсем хаты. XVI–XVII йөздә



язылган булуы ихтимал. Азагында буш калган кәгазьләрдә хуҗа Хафизнең фарсы телендә язган мәкаләте бар. «Касыйдәи Бөрдә»-не ничек укырга кирәклеге хакында.
* 12,5×20,3. 165 бит. 3б биттә мондый сүзләр бар:

استاذی تونتار ايشان حضرتلاری ننک اسم شريفلاری
علی محمد بن سيف الله بن عبد الرشيد بن يار محمد بن اوتكان بن
توق محمد
كياوی ننک اسم شريف شمس الدين بن رحمة الله



*Рис. 101.* Имена ишанов в деревне Түнтәр со ссылкой на «Мустафад ал-ахбар» ал Марджани. НМ РТ 18369-79, л. 3б

(«Остазы Түнтәр ишан хәзрәтләренең исем шәрифләре: Гали Мөхәммәд бине Сәйфулла бине Габдеррәшид бине Ярмөхәммәд бине Үткән бине Тукмөхәммәд. Киявенең исеме шәриф – Шәмседдин бине Рәхмәтулла»).
Урта Азиядә эшләнгән кульъязма, XIX гасырның икенче яртысы. Язу рәвеше почмаклы нәсех, регуляр огласовка, бит саннары музейда куелган, кустодлар бар, кара каралар.

---

**228** (27)

مولوی محمد صادق. حاشية على شرح ايساغوجى

**Мәүла Мөхәммәдсадыйк «Хашия галә шәрхи Исагуҗи»**
Мирза Мөхәммәд Хәким Гази исеменә багышланган. 106 кәгазь. Фәлсәфә, кәлям. Гарәп телендә. Күчереп язучы «1849 елда тәмам иттем. Әхтәм вәләд мулла Габделлатыйф» дип кул куйган, ләкин китапның баштагы сәхифәләре зәңгәр кәгазьдә, 1806 елгы су билгесе, бик дөрест имла, гүзәл каләм белән язылган. Калганы гади язу. Соңыннан Галиулла бине Гәзилбай (?) Казанлы милкендә дә булган.
* 17×21,7. 103+1 бит. Колофон 102а биттә:

تمت الرسالة لمولى صادق على شرح ايساغوجى ١٨٤٩ نچى يلده اوكته
بر ننك يكرمنجى كوننده كاتبه احتم ولد ملا عبد اللطيف

(«Мәүла Садыйк галә шәрхи Исагуҗи» китабы 1849 елда октябрьнең егерменче көнендә Әхтәм бине мелла Габделатыйф кулы белән күчерелде»).



*Рис. 102.* Колофон в рукописи. НМ РТ 18369-27, л. 102а



Өстәмә язма 102б биттә: بر صوم بها ايلان آلندى («Бер сум бәһа илән алынды»).
103б биттә ике турыпочмаклы мөһер 2,3×3,5, тексты укылмый.
1б биттә төп текстган соң язма:

هذا الكتاب ملا صادق صاحبى على الله بن گورلباى القزانى

(«Бу «Мулла Садыйк» китабының хуҗасы – Галиулла бине Гөрелбай әл-Казани»)
Башка хуҗалар турында булган мәгълүмат тырышып бетерелгән.

---

**229** (26)

مولوی حسن. حاشية على شرح سلم

**Мәүла Хәсән. «Хашия галә шәрхе сәлләм»**
58 кәгазь. Каләм, фәлсәфә. Гарәп телендә. Язуы матур, имлясы дөрес.
* 17×20,8. 156 бит. 1а биттә мондый сүзләр бар:

حرره عبد اللطيف الصقمانى بعون الله تعالى

(«Мөхәммәдвәли мелла Мөхәммәдсәгыйдов китабы әл-Казани»).



*Рис. 103.* Владельческая запись в рукописи НМ РТ 18369-26, л. 1а

Кәгазе XIX гасырның икенче яртысына карый. Татар тәгълиге, кара каралар, кустодлар бар. Күчереп язучының исеме 10 һәм 11 битләр арасындагы бер кәгазьдә бар:

محمد ولى ملا محمد يوسف
سعيدوف كتابى القزانى

(«Моны Габделлатыйф әс-Сокмани Аллаһы ярдәме белән язды»).
Бу урында Зәйнәпнең өстәмә язмасы: «Тирсә мәдрәсәсен тәмам иткәч, Әгерҗе районы Сокман авылында әтием Гадбелҗәмил берничә ел мөгаллимлек иткән. Зәйнәп»).

**230** (26)

مولوی حمد الله. شرح سلم لقاضی محب الله

**Мәүләви Хәмдулла. «Шәрхе сәлләм ли-казый Мөхибулла»**
142 сәхифә. Кәлам, фәлсәфә, гарәп телендә. Мәчкәрә авылында мулла Исмәгыйль бине Муса авылы мөдәррисенең мәдрәсәсендә укучы Мөхәммәдьяр исемле шәкерт 1855 елда үзенең остазы мулла Йосыф бине ... ахунд әл-Бистави өчен язып тәмам иткән. Имлясы дөрест, каләме бик гүзәл.
* 89а биттә мондый сүзләр бар:

مولانا حمد الله شرح سلم لقاضی محب الانار ملك محمد علی مخدوم
ابن الاخوند داملا محمد یوسف حضرت البستوی

(«Мәүлана Хәмдулла шәрхе сәлләм ли-казый Мөхиб әл-Әнар» Мөхәммәдгали мәхдүм ибне әл-ахунд дамелла Мөхәммәдйосыф хәзрәт әл-Бистави милкендә»).



*Рис. 104.* Владельческая запись в рукописи. НМ РТ 18369-26, л. 89а

Колофон 161б биттә:

تم هذه النسخة الموسومة بحمد الله علی ید فقیر محمد یار لاجل
ملا یوسف و فی مدرسهء مولانا و ملا اسماعیل ابن موسی المچکروی
غفرالله تعالی ذنوبهما ... 1855

(«Ошбу «Хәмдулла» нөсхәсе фәкыйрь Мөхәммәдьяр кулы белән мулла Йосыф өчен мәүлана вә мулла Исмәгыйль бине Муса әл-Мәчкәрави мәдрәсәсендә 1855 елда тәмам булды»).



**231** (26)

مولوی عبد الحکیم سیالکوتی. رسالة علم فی تحقیق العلوم و المعلوم

**Мәүләви Габделхәким Сәялкүти.**
**«Рисаләт гыйлем фи тәхкыйкел голүм вәл мәгълүм»**
12 кәгазь. Һиндестан кәгазендә. Матур каләм, дөрест имля белән язылган, ләкин кем тарафыннан, кайчан күчерелгәне күрсәтелмәгән. Бу китап Казан ахуны Мөхәммәд йосыфның углы Мөхәммәдвәли һәм Мөхәммәдгали милкендә булган.
* 174б биттә түгәрәк мөһернең эзләре калган.

---

**232**
(тасвирламасы юк)

---

**233** (83)

شیخ نجم الدین کبری. رسالة فی بیان علم تصوف و اهل تصوف

**Шәех Нәҗмеддин Кубра.**
**«Рисаләт фи бәяни гыйлем тәсаувыф вә әһле тәсаувыф»**
53 сәхифә. Тәсаувыф гыйлемнән. Фарсы телендә. Кавал авылында (Казан вилаятендә) Габдәш бине Габдессәлам мөдәрриснең мәдрәсәсендә һиҗри 1229, милади 1814 елда укучы Бикмөхәммәд бине Бикбау тарафыннан күчереп язылган. Фарсы, гарәп, төрки гыйбарәләре бик дөрест имля һәм бик ачык, гүзәл каләм белән язылган. Бик нык сакларга тиешле. Сирәк мирас. Бу мәҗмугада болгар галиме Сөләйман бине Даудның «Зөһрәтер рияз» исемле китабыннан «Мигъраҗен нәби» дигән өлеше бар. Шулай ук, XII йөздә Чыңгыз илбасарларына каршы көрештә шәһит булган шәех Нәҗмеддин Кубраның әсәре бар.
* 17×21. 1б–41а сәхифәләр.
Өске каплавычның тышындагы язма:

اوّل قاسم شیخ غه ینه آننك اوغلی بخشنده شیخ قالا سی ایچنده
شولوق قاسم شیخ ننك اوغلی کول باشنده حسن شیخ قطب اننك
جفتی فرزنداسی ینه آندان غیری ایکی شهید لارکا بارچه تابعین مرحوم

لارغه ینه پچان بضارنده بورندوق شیخ آننک اوغلی عبد الرحمن شیخ
شولوق پچن بضارنده سید قطب (؟) آطاغه ینه یاشل مسجد قاتنداغی
زیارتداغی لرغه ینه اوزطاز یاقداغی لرغه ینه فضلی حضرت زیارتنداغی
لرغه ینه طال لار توبنداکی ایکی خاتون جماعتی ینه ایکی بالغ بولماغان
اوتکان قز ولی بارديب بیان قیلمش لار ینه کافرلار زیاتنده (!) اختیارسز
کرفتار بولغان مسلمانلارغه الله تعالی رحمت ایلسون ینه شولوق کول
باشنده نوعای یولنه کتکان یولداغی عزیزلرکا شهر بلغارغه بارا تورغان
یولداغی بزرک لارکا دیب بغشلغای سز مسموع

(«Әүвәл Касыйм шәехкә, янә аның углы Бәхшендә Шәех каласы эчендә. Шул ук Касыйм шәехнең углы күл башында Хәсән шәех котыбның җәфәте фарзандасы. Янә аннан гайре ике шәһидләргә барча табигыйн мәрхүмнәргә, янә Печән базарында Борындык шәех, аның углы Габдеррәхман шәех, шул ук Печән базарында Сәед Котыб атага, янә Яшел Мәсҗед катындагы зияраттагыларга, янә Озтаз яктагыларга, янә Фазлый хәзрәт зияраттагыларга, янә Таллар түбәндәге ике хатын җәмәгате, янә ике балигъ булмаган үткән кыз вали бар дип бәян кылмышлар, янә кяферләр зияратында ихтыярсыз грифтар булган мөселманнарга Аллаһы Тәгалә рәхмәт әйләсен, янә шул ук күл башында Ногай юлына киткән юлдагы газизләргә, шәһре Болгарга бара торган юлдагы бозоргларга дип багышлагайсез. Мәсмугъ»).
Факсимиле VI карагыз.

---

**234** (83)

**Сөләйман бине Дауд Саксини әл-Болгари** (вафаты милади 1165 елларда).

معراج النبی محمد صلعم

«Зәһрәтер рияз» исемле китабыннан. 54-69 с. Сирен нәби гыйлеменнән. Гарәп телендә.





*Рис. 105.* Хроника (*та'рих*) в рукописи. НМ РТ 18369-83, л. 67а



*Рис. 106.* Колофон в рукописи НМ РТ 18369-83, л. 53а

**235** (83)

Төрле галимнәрдән алынган. Хәдисләр, риваятьләр. 69–70 с. Төрле мәүзугътән. Гарәп телендә.



*Рис. 107.* Хроника (*та'рих*) в рукописи НМ РТ 18369-83, л. 73а

**236** (83)

محمد الغزالى. ايها الولد

**Мөхәммәд әл-Газали. «Әййүһәл вәләд»**

81–104 с. Мәүгазә-әхлак. Гарәп телендә.

**237** (83)

امام صدر الشهيد. رسالهء مهمه

**Имам Садр әш-Шәһид. «Рисалаи мөһиммә»**

Мөһим фәтвалар мәҗмугасы. 111–127 с. Гыйльме фикъһ. Гарәп телендә.

**238** (83)

Календарь камәрия һәм шәмсия еллары буенча. 129–158 с. Риязат гыйлеменнән. Төрки телдә.

**239** (83)

Төрле мәбналәрдән. Өзекчәләр һәм хикәят вә риваятьләр. 158–189 с. Төрле мәүзугъ. Төрки, гарәп, фарсы.

Искәрмә:

1) Габдәш бине Габдессәлам хакында Мәрҗанинең «Мөстәфад» 1дә, 319 сәхифәдә берничә сүз бар.
2) Һиҗри 1205, милади 1790 елларда Хәерби авылында мөдәррислек иткән Габдәш бине Габдессәлам шушы кеше түгелме? Карагыз: № 160.



**240** (5)

عبيد الله بن مسعود بن تاج الشريعة. مختصر الوقاية

**Гобәйдулла бине Мәсгуд бине Таҗеддин әш-Шәрига. «Мохтәсарел викая»**

119 кәгазь. Фикъһ. Гарәп телендә. Күчереп язучының исеме һәм язу елы ачык күрсәтелмәгән, ләкин кәгазьнең су билгесе



*Рис. 108.* Колофон и комментарии к нему З. Максудовой в рукописи. НМ РТ 18369-5, л. 119б

1806/ 7 елларны күрсәтә һәм китапның беренче битләрендә «Низамеддин бине мелла Фазлулла», «Габдессәлам бине Фазлулла» милкендә булганы күрсәтелгән. Кайбер урыннарда шул еллардагы кайбер халык җырлары да язылган.
* 16,5×21. Күгелҗем төстәге кәгазь XIX гасыр башына карый, нәсех, кара һәм кызыл каралар, кустодлар бар.

**241** (136)

سليمان باقرغانى. باقرغان مجموعاسى منظومه

**Сөләйман Бакыргани. «Бакырган мәҗмугасы мәнзумә»**
65 кәгазь. Әхлакый һәм тарихи дастан. Төрки телдә. Күчереп язучының исеме ачык күрсәтелмәгән, язып тәмам иткән елы 1837 милади, матур каләм, дөрест имля белән язылган. Сакларга кирәк.
* 17×21. 81 бит. Тышлыксыз. Колофон 65б биттә:

تمت تمام بولدى 1837 سنه يلده تمت شد است

(«Тәммәт тәмам булды 1837 елда»).



*Рис. 109.* Заставка в рукописи. НМ РТ 18369-136, л. 2б – 3а





*Рис. 110.* Колофон в рукописи. НМ РТ 18369-136, л. 65б

**242** (136)

على بن عثمان اوشى. كتاب التوحيد

**Гали бине Госман Ошый. «Китабет тәүхид»**
66–81 кәгазь. Гакаид. Гарәп телендә. 1832 елда Казан вилаятендә Әләт юлы Казаклар авылында мелла Габдессәлам бине Габделваһабның мәдрәсәсендә Мозаффар бине (исем җуелган) тарафыннан күчереп язылган. Буш калган битләрендә каләм хакында

шигыре, татарча җырлар да язылган. Сакларга кирәк. Каләме начар, имлясы хаталы.
Искәрмә: Габдессәлам бине Габделваһаб һиҗри 1275, милади 1859 елда вафат (Мөстәфад, 2, 117 с.) Казанда.
* 66б–81а бит. Колофон 81а биттә:

اوشبو الكتاب تمت تمام بولدی 1836 سنه ده و فی ولایتی قزان و فی الطریقة الط و فی قریه قزاقلار و فی مدرسة ملا عبد السلام بن عبد الوهاب اوشبو الكتاب مظفر بن ... اوغلی یازدی

(«Ошбу китаб 1835 елда Казан виляяте Әләт юлында Казаклар авылында мелла Габдессәлам бине Габделваһаб тәмам булды. Ошбу китап Мозаффар бине … углы язды»).



*Рис. 111.* Колофон в рукописи. НМ РТ 18369-136, л. 81а

## 243

قاضی زاده رومی. مختصر وصیة البركولی

**Казыйзадә Руми. «Мохтәсар васыятел Пиркули»**
102 кәгазь. Фикъһ китабы, төрки телдә. Кайчан, кем тарафыннан күчерелгәне күрсәтелмәгән, әмма бу китап «Казыйзадә» Нурмөхәммәд Исхак угълы милкендә булганын күрсәткән язулары бар (102 кәгазь).



## 244 (40)

حسام الدين بن شرف الدين البلغاری. تواریخ البغاریه

**Хисамеддин бине Шәрәфеддин әл-Болгари. «Тәварихе Болгария»**
39 кәгазь. Тарих гыйлеменнән. Төрки телдә. 1855 елда күчереп язылган, кем икәне күрсәтелмәгән. Бу китап илне өйрәнү өчен, тел өйрәтү өчен әһәмиятле. Сакларга кирәк. Теле – Болгар-Казан теле, борынгы.
* 21,2×16,5. 134 бит. Язу рәвеше тәгълыйкъ, каралар кара, текст кызыл рамка эченә кертелгән, кустодлар бар. Колофон:

قد تم فی سنة 1855 نچی عنوارننک 25 نچی ده

(«1855 гыйнварның 25ендә тәмам булды»).

## 245 (40)

Төрле мәбнагъләр буенча. «Мәнакыйбел әүлияел гыйзам». 12 кәгазь. Тәрҗемәи хәлләр. Төрки телдә. 1855 елда язылган.

## 246 (40)

نوح. بستان القدس و گلستان الانس

**Нух. «Бостанел кодс вә гөлестанел унс»**
175 сәхифә, фихристе белән. Хикәятләр, тәрҗемәи хәлләр, төрки. XVI йөз татар галиме төзегән, ләкин күчереп язылган елы, урыны һәм язучының исеме күрсәтелмәгән. Бу китапта XII йөз болгар галиме Сөләйман бине Дауднын «Зәһрәтер рияз» исемле китабыннан күчермәләр бирелгән.
Түгәрәк мөһер 50а биттә куелган:

افوض مری الله الی فحر الدين بن عمر

Ахыры юк, кәгазе XIX гасырның икенче яртысына карый.



*Рис. 112.* Оттиск печати в рукописи НМ РТ 18369-40, л. 50а

**247** (6)

هويدا

**Һәвидә. Ибраһим бине Әдһәм дастаны.**
19 кәгазьдә. Төрки телдә. Кайда, кайчан һәм кем тарафыннан язылуы билгесез, чөнки «Тәварихе Болгария»нең соңгы сәхифәләре югалган. Искәрмә: бер сәхифәдә: «Шиһабеддин бине Бәһаэддин» дигән мөһере һәм имзасы бар. Шиһабеддин Мәрҗани түгелме?
* 16,5×21,8. 1+61+2 бит. 1а биттә кара мөһернең өч урында эзе бар. Начар укыла: «Хөсәен б. … ?»

Кайбер урыннарда текст Зәйнәп Максудова тарафыннан төзелде. Кара мөһер 6б биттә: شهاب الدين بن بها الدين («Шиһабеддин бине Бәһаэддин»).
Монда ук күчерүченең исеме куелган: كاتبه شهاب الدين لاجل لطفى («Моны Шиһабеддин Лотфый өчен язды»).



*Рис. 113.* Оттиск печати в рукописи. НМ РТ 18369-6, л. 6б

9б биттәге бүлек башы: ابراهيم مكه كا بارب اوتون صاتقانى ننك بيانى
12б биттәге бүлек башы: زليفا ايتكان عزل ننك بياننده ايتورلار
15а биттәге бүлек башы: ابراهيم ادهم اوغلى اولكانده ايتكان عزلى
16б биттәге бүлек башы:

شيطان فرعون برلهٖ سوز ثنكاسنى ننك بياننده ايتورلار فى بيان مريد شاه

18б биттәге бүлек башы:

حضرة عيسى كورستانعه زيارت بارب تماشا قلعاننك بيانى

Һәвидә Чимъяни хакында карагыз: Hofman, Section III, Vol. 1, 146.

---

**248** (6)

حسام الدين بن شراف الدين البلغارى. تواريخ بلغاريه

**Хисамеддин бине Шәрәфеддин әл-Болгари.**
**«Таварихе Болгария»**



20–61 кәгазь. Болгар тарихи хәбәрләре. Төрки телдә. Бу китап тулы түгел һәм 1855 елгы нөсхә белән чагыштырганда күп аермасы бар.

---

**249** (138)

محمد بن عثمان الاوشى. عين العلم

**Мөхәммәд бине Госман әл-Ошый. «Гайнел гыйлем»**
126 кәгазь. Әхлак, хәдис, риваятьләр. Гарәп телендә. Кайда, кайчан, кем тарафыннан күчерелгәне билгесез. Буш кәгазендә җырлар язылган.



*Рис. 114.* Владельческие записи в рукописи. НМ РТ 18369-138, л. 124а



*Рис. 115.* Стихи об учебе в рукописи. НМ РТ 18369-138, л. 126а

* 20×25. 126 бит. Кара һәм кызыл каралар, текст зәңгәр рамка эчендә язылган, кустодлар бар. Күчерү елы – 1868.

**250** (51)

Мәүгазә. 11 кәгазь. Әхлак. Гарәп телендә. Кайда, кайчан, кем кулы белән күчереп язылганы билгесез. Габделкадыйр Гобәйдулла угълы дигән язма беренче биттә күренде. Язу һәм кәгазе буенча XVIII йөз хатирәсе булыр.



* 17×20. 66 бит. Бу китап 11а биттә мелла Ишмигә нисбәтләнә: اوشبو ملا اشمی ننک ترور

**251** (51)

دقایق الاخبار

**«Дәкаикел әхбар»**

54 кәгазь. Әхлак, гарәпчә. Тәмам түгел. 12б–66б.

**252** (52)

Кырык хәдис мәҗмугасы. 10 сәхифә. Хәдисләр. Гарәп телендә. Шәмседдин тарафыннан 1871 елда язылган.

**253** (42)

مجالس الشهور تفسیر رومی

**«Мәҗалисеш шөһүр»**

292 сәхифә. Мәүгазә, аять, хәдисләр, гыйбрәтле кыска хикәяләр мәҗмугасы. Гарәп телендә. 1856 елда Нократ авылында Мөхәммәдсадыйк бине дамелла Динелислам Качимов кулы белән язылган. 1860 елда мелла Габделвахид Фәйзулла углы милкендә булган. Язуы матур, дөрест, сакларга.

* 17,5×21. Язма өске каплавычының тышында хуҗа тарафыннан язылган сүзләр:

1858 نویابرنک 29نده مخدوم دان آلدم تفسیر رومی نی ملا ابو بکر
نعمة الله اوعلی
ملکت هذه الکتاب بالبیع الصحیح عبد الواحد بن فیض الله المزارآستی
من قریهء نوقراط من المرء المسمی بالملا صادیق المخدوم بن داملا دین
الاسلام فی سنهء 1860 فی شهر ذوالقعده من الایام البیضة

(«1858 ноябрьнең 29ында мәхдүмнән алдым «Тәфсире Руми»не мелла Әбүбәкер Нигъмәтулла углы. Ошбу китабны дөрес бәягә мин Габделвахид бине Фәйзулла әл-Мазарасты Нократ



*Рис. 116.* Аннотация к рукописи. НМ РТ 18369-42, л. 1а

авылыннан мелла Садыйк әл-Мәхдүм бине дамелла Динелисламнан 1860 елның Зөлкагъдә аеның ак көннәрендә сатып алдым»). Кәгазе XIX гасыр ахырына карый («Слободская Кордяжская фабрика»), тәгъликъ, кара каралар, кустодлар бар.
Колофон 145а биттә:

قد تمت هذه النسخة الشريفة فى قرية نوقراط و فى يد اضعق العباد و احقر محمد صادق بن داملا دين الاسلام كچوكوف نوقراطى



تمت الكتاب بعون الملك الوهاب 1856 سنه ده فى شهر شعبان المبارك و فى يوم 2 و فى وقت الضحى

(«Ошбу нөсхә Нократ авылында фәкыйрь Мөхәммәдсадыйк бине дамелла Динелислам Кучукуф Нократый тарафыннан 1856 нче елның Шәгъбан аеның икенче көнендә язылды»).

---

**254** (159)

عبيد الله بن مسعود بن تاج الشريعة. كتاب التوضيح

**Гобәйдулла бине Мәсгуд бине Таҗ әш-Шәрига. «Китабет тәүзыйх»**

524 сәхифә. Осуле фикъһ. Гарәп телендә. 1859 елда күчереп язылган. Насихе ачык күрсәтелмәгән, шулай да бер сәхифәдә (68 нче кгз) «Кәтиб Мифтахеддин ли-әҗли Мөхәммәдсадыйк абзый» дип язылган юлы бар. Мазарсты авылы имамы җизнәбез Габделвахид Фәйзулла углының хосусый китапханәсеннән калган хәлдә, миңа аның углының Мөхәммәдсадыйк кызы тарафыннан җибәрелгән иде.
* 17,2×28. Яртылаш күн тышлыгы.
1а биттә аңлатма:



*Рис. 117.* Колофон в рукописи НМ РТ 18369-159, л. 263б

ساراپول اويازى مازار آستى آولیننک امامى جيزنه مز ملا واحد فيض الله اوغليننک خصوصى كتابخانه سندن قالغان كتاب. ميكا آنک ئوچونچى بوون بالالارى طرافندن بوله ك ايتلدى

(«Сарапул өязе Мазарасты авылының имамы, җизниебез мелла Вахид Файзулла углының хосусый китапханәсеннән калган китап. Миңа аның өченче буын балалары тарафыннан бүләк ителде»).

Штемпельләр «Вятская фабрика» һәм «Ржевской фабрики № 5». Язу рәвеше нәсех, кара һәм кызыл каралар, кустодлар бар, пагинациягарәпчә һәм европача.
Колофон 263б биттә:

1859 سنه ده تم هذا الكتاب بعون ملك الوهاب حمل ننک 28 نچی یومنده فی یوم الجمعة و فی ایام الاربعاء

---

**255** (46)

احمد بن عبيد الله بن ابراهيم مقلب صدر الشريعة.
تلقيح العقول فى الفروق

**Әхмәд бине Гобәйдулла бине Ибраһим.**
**«Тәлкихел гөкул фил фөрукъ»**



*Рис. 118.* Аннотация к рукописи. НМ РТ 18369-46



538 сәхифә. Мәҗмугател фәтава. Гарәп телендә. Күчереп язучының исеме, урыны күрсәтелмәгән, кәгазендә су билгесе 1788 елгы, язуы гүзәл. Бер генә кеше кулыннан язылган. Китапның әүвәлге һәм азаккы битләре төшкән.
* 16,3×21,7. Өске каплавычы юк. Язу рәвеше тәгъликъ. Кара каралар. Башы һәм ахыры юк, китап эчтәлеге 1а–6а битләрдә күрсәтелгән. Кустодлар бар, пагинация гарәпчә һәм европача.
Карагыз: GAL, I, 380.

---

**256** (95)

Исеме билгесез, баштагы һәм азаккы битләре юк. 30 кәгазь. Коръән сүзләре, хәрефләре хакында һәм кайбер пәйгамбәрләр хакында. Гарәп телендә. Кәгазендә су билгесе 1730–1780 елларны күрсәтә. Күчереп язучы «мулла Габд бине мулла Чуракай (يازوچى ملا عبد بن ملا چوراقاى) язды» дип 23 кәгазьдә кул куйган. Үз заманында гаять файдалы киңәшләр биргән, бик яхшы эчтәлекле китап.
* 16×21. 16 биттәге су билгесе: болын һәм «1738». Урыс каты кәгазь, күгелҗем төстә, язу рәвеше нәсех, кустодлар бар, бит санннары гарәпчә һәм европача куелган.

---

**257**

رحمة الله بن امير خان
عقيدهء منظومه

**Рәхмәтулла бине Әмирхан**
(Чыгышы – Кишет авылыннан, вафаты 1875 елда, Казан галиме).
**«Гакыйдәи мәнзумә»**
Һәр биттә 17 юл. 7 сәхифә. Гыйлем гакаид. Казан төрки телдә. Мулла Лотфулла бине Гатаулла Әлмәти кулы белән бик матур каләмдә язылган һәм Казанда 1860 елда Мөхәммәд Вәли Яхиннең литографиясендә ташбасмада басылган. Сакла!
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**258**

علم حال

**«Гыйльме халь»**
Кече кулда, 26 кәгазь. Ислам гакыйдәсе, әхлак һәм гадәт кагыйдәләре. Төрки телдә, саф, бай, матур тел. Кайда, кайчан, кем күчергәне билгесез. Кәгазендәге су билгесе 1718 елга ишарәт кыла. Тел ягыннан бик мөһим. Кайбер сәхифәләре югалган.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**259**

فرض عين

**«Фарзы гайн»**
Кече кулда, 3 кәгазь. Ислам кагыйдәләре. Саф төрки телдә. Күчерүченең исеме һәм тарихы билгесез. Дин тарихын һәм төрки телләрне өйрәнүчеләр өчен кирәге булыр. 260нче номер белән бергә.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**260**
علم حال 9 кәгазь, кече кулда. Саф борынгы төрки телдә.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**261**
اوراد فتحيه 14 кәгазь. Догалар, гарәп телендә. Сөлс каләме белән матур язу.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**262**
Догалар. 7 кәгазь. Борынгы төрки ырымнар, гыйлем нәҗүмнән саналган. Төрки телдә. Күчереп язучының исеме, урыны, вакыты билгесез. Язуы матур.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.



**263**

شاعر سعيد. الهى نظم

**Шагыйрь Сәгыйд. «Илаһи нәзым»**
2 кәгазь, әдәптән. Төрки телдә. Битекченең исеме Сәгыйт була. Елы 1530, Хәмәл аенда дигән.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**264**

بشير منتهى. وقتى سحراچنده

**Бәшир Мөнтәһи. «Вакты сәхәр эчендә»**
22 кәгазь. Төрки телдә, әхлак һәм мәүгазә.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**265**
Догалар. 14 кәгазь. Ырымнар-хорафатлар. Төрки телдә. Кәгазендә су билгесе 1820 елгы.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**266**
Батырша (?) мәнзумә. 10 сәхифә. Әхлак. Төрки телдә. 1791 дуңгыз елында язылган. Бу әсәр әдәбият тарихчылары өчен бик файдалы булыр.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**267** (65)

ابو الليث سمرقندى. تنبيه الغافلين

**Әбу әл-Ләйс Сәмәрканди. «Тәнбиһел гафилин»**
46 кәгазь. Әхлак вә мәүгазәдән хәдисләр мәҗмугасы. Гарәп телендә. Күчереп язучының исеме һәм язылу тарихы күрсәтелмәгән. Нарат авылы имамы – бабабыз Габдессәттар бине Габделгазиз бине Гайсә әл-Көнәри китапханәсеннән мирас. Сакларга.
* 17,5×23. Тышлыгы юк. Урыс кәгазе, XVIII ахыры яки XIX гасыр башы, язу рәвеше тәгълик, кара һәм кызыл каралар, гарәп



*Рис. 119.* Аннотация к рукописи. НМ РТ 18369-65

телендә, кайбер урыннар татарча тәрҗемә ителгән, бит саннары музейда куелган, ахыры юк.

**268**
Мәгъсүм Садыйков. Уфа губернасы Бөри өязе Калмык волосте Чалкан авылының. Татарча нәзым белән төзелгән сугыш еллары хатирәсе. 1914–1918 елгы сугышлар хакында. 44 кәгазь. Кайбер битләрендә язучының иптәшләре хакында мәгълүматлар бар. Соңгы битләрендә дини гыйбадәтләрнең вакытлары, көннәре язылган. Сакларга.
* Бу кулъязма тасвирланмаган хәлдә Мирасханәдә саклана.

**269** **(115)**

كمال امى. ديوان الاشعار

**Өмми Кәмал. «Диванел әшгар»**
85 сәхифә. Төрки-болгар телендәге мәүгазә. Әхлак. Баштагы дүрт бите төшкән. Азагында күп битләре җитешми.





*Рис. 120.* Исправления к тексту рукописи. НМ РТ 18369-115, л. 26б–27а

* 18×22,5. 41 бит. Бу шигырьләр басылган: ديوان رضائى 1899. Кулъязма XIX гасырның беренче яртысына карый, язу рәвеше тәгъликъ, кара каралар, кулъязмадагы хаталар басма буенча Зәйнәп Максудова тарафыннан төзәтелгән.

**270** **(32)**

تحرير الواعد المنطقية فى شرح شمسية

**«Тәхрирел вагыйдел мантыйкыя фи шәрхи Шәмсия»**
Әмир Әхмәт исеменә багышланган. Мантыйк гыйлеменнән. Гарәп телендә. Баштагы сәхифәләр – борынгыдан калган сәхифәләр. 1888 елда Мөхәммәдсадыйк бине мелла Габделвахид бине Фәйзулла (Сарапул өязе) кулы белән күчерелгән.
* 17,6×22. 90 бит. Тышлыгы юк. 46 биттә:

شمسية كتابى يازدم 1888 نجى يلده تمام قلدوم

(«Шәмсия китабы яздым 1888 елда тәмам кылдым»).
Һәр биттә 13 юл, нәсех, кәгазь XIX гасырның икенче яртысына карый (штемпель Гальской фабрики, фабрика Сергеева № 5).

68б биттәге өстәмә:

تحريک قلم عبد الله لاجل دوستم محمد صادق

(«Моны Мөхәммәдсадыйк дустым өчен мин, Габдулла, яздым»). Ахыры юк, Зәйнәпнең язмасы 90б биттә: «Мөхәммәдсадыйк абзый – Мазарасты авылының имамы Габделвахид җизни бине Фәйзулланың улы Булатов. Зәйнәп Максудова».

271

عبدالله نعمة الله اللين بوبى. مدافعة

**Габдулла Нигъмәтуллин-Бубый. «Мөдафага»**
Өзекчә. Дини мәнзумә, төрки телдә. Почта кәгазендә язылган. Бер дәфтәрлек өзекчә.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

272

Мәҗмуга:
А) Бадр сугышында катнашкан сәхабәләр.
Б) «Касыйдәи Бурдә» һәм хасыятләре хакында.
В) «Рисаләи гакыйдә»
Г) Төрле тәһлил гыйбарәләр. 105 кәгазь. Ислам тарихы, әхлак һәм догалар мәҗмугасы. Гарәп, төрки телләрендә. Кәгазендә су билгесе 1806 елгы, язуы матур. Кайда, кем күчергәне күрсәтелмәгән.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

273

Шагыйрь Хәлил Ырынбургый. Мәхәббәт-лирик шигырьләр. 109 юл. 5 кәгазьдә. Автор XVIII йөздә яшәгән булыр. Мәхәббәт-мәдхия юлында язылган. Дини әдәбият. Төрки, гаять матур телдә, гүзәл өслүбтә язылган, төрле кулда күчерелгән. Күчереп язучы һәм язган елы күрсәтелмәгән. Шулай да XVIII йөз иҗаты булыр.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.



274

Билгесез шагыйрь. Зарлану-мөнәҗәт шигырьләре һәм Камал Өммидән алынган мисраглар. 6 кәгазь. Төрки телдә. XVIII йөздә язылган булыр. Каләме гүзәл.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

275

Шагыйрь Батырша. Рамазан аена мәдхия. 10 сәхифә. 136 бәет. Әхлак. Төрки, борынгы матур тел белән язылган. Азаккы битендә «Рәхмәт кылгыл, йә Рәхим, син Батыршага» дип куелган. Язылган елы 1791 ел. № 197, 266 ны карарга, тәкрар түгелме?
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

276

Хөсәен Газиз углы, XVIII йөз. Болгар-Казан дәүләте чорыннан калган булыр. 18 кәгазь. Дини-тарихи хорафат. Борынгы төрки телдә. Кайчан, кем язганы билгесез. Кәгазендә су билгесе 1760 елны белдерә (3 кәгазьдә). Китапның ахыргы битләре җитешми.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

277

Габид, Фәез, Сөендек бәнү Габделгазиз бине Гайсә Көнәриләргә баглый язмалар, шулай ук Габдессәттар бине Сөендек һәм Ризван мулла хакында.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

278

Габделҗәмил Габделмәннан угълына баглый язмалар.
* Бу кулъязма җыентык тасвирланмаган, Мирасханәдә саклана. Факсимиле II карагыз.

279 (287д)

**Габдессәттар.**
* Аннотация: «Элгерөге Вятка губернасы Сарапул (бер вакыт – Алабуга) өязе Нарат авылының имамы һәм учителе Габдессәттар б. Сөендек б. Габделгазиз б. Гайсаның язмалар мәҗмугасы». Эчтәлеге:

«1. 1836 нчы елда рус падшасы Николай Павловичның Казанга килүе хакында мөфти Габдессәлам мелла Габдеррәхим углының мөселманнарга язган хаты. 1 кәгазь.
2. 1834 елда Кышкар мелласы Фәйз б. Габделгазиз б. Гайса Көнәринең Семипалатта үлеп калган бер сәүдәгәрнең мирас малларын варислар арасында өлешеп биргән язуы. 1 кәгазь.
3. Нарат авыл мелласы һәм учителе Габдессәттар б. Сөендек б. Габделгазиз б. Гайса Көнәринең каенатасы Исәнбай авыл мелласы Ризван Утәгүл угылына шул заманның мөселманнар мөфтисе Мөхәммәдҗан Хөсәен углы тарафыннан 1816 елда язылган шелтә һәм кисәтү язуы. 1 кәгазь.
4. 1875 елда Сарапул өязе Девәтернә (Мазарасты) авылының Дәүләтшаһ Җиһаншаһ угылы тарафыннан үзенең туган углы Хуҗа Әхмәдне үзе кыйнап шул авылның Хәмидуллаһ Мәндәй углы үтерде дип ялган яла ябуы хакында авыл җәмагатенең рапорты. 1 кәгазь.
5. Кадибаш авылында табылган бер мәет хакында рапорт (бер бите ертылып югалган).
6. Язучы – мелла һәм учитель Габдессәттар б. мелла Сөендек б. мелла Габделгазиз б. мелла Гайса әл-Көнәри. Язылу вакыты 1831–1839 елларда Нарат авыл кешеләренең үлү, туу, никахлану, аерылышулары хакында метрикә язуының күчермәсе. Барлыгы 66 кәгазьдә.
7. 1865 елларда Габделләтыйф б. Салих авыл мөдәрриснең мәдрәсәсендә Әхмәд Зәки дигән хәлфәнең дәрес бирү тәртибе – төрле фәннәр буенча. 1 кәгазь.
8. Вәришбаш авыл башкорты Әрдәшир Шәмседдин углының вафаты соңында калган мирас малларын варислар арасында өлешү язуы. Бу гаилә ярлыларның җирләрен сатып алып, күп җир бәйләп, күп иген җыеп баеган гаилә икәне ачык күрсәтеп язылган. 1 кәгазь.
9. Китмәс суыннан балык тоту өчен Нарат авыл җәмагате күрше рус авылына арендага бирүләре хакында договор язуы. 1 кәгазь.

Барлыгы – 74 кәгазь».

Факсимиле I карагыз.



**280**

Җыючы Зәйнәп Максудова. Мәдехләр дәфтәре.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**281**

Җыючы Зәйнәп Максудова. Бәетләр мәҗмугасы. 1 дәфтәр. 234 сәхифә.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**282**

Шагыйрь Касыйм. Фәттахеддин китабы. 103 кәгазь. Каһарман дастаны. Борынгы төрки–болгар теле. Милади 1848–1826 ел чамасында язылган кулъязмадан күчереп язучы – Максудова Зәйнәп.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**283**

Шагыйрь Гариб Болгари. Гөл вә былбыл дастаны. 20 сәхифә. Әдәбият. Болгар төрки. Күчермәдән күчерүче – Максудова Зәйнәп.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**284**

Шагыйрь Хәрәзми. Мәхәббәтнамә мәнзумә. Әдәбият. Хвәрәзм төркие. Шулай ук.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**285**

Шагыйрь Сәед Әхмәт. Тәгәшшыкнамә. 839 һиҗри, 1439 миладида төзелгән. Әдәбият. Чагатай теле. Шулай ук.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.

---

**286**

Шигырь. Мелла Балыкбай мелла Баймөхәммәд ахун күчергән. Күчермәдән күчерүче – З. Максудова.

* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**287**
Шигырь. Сөаль вә җавап. Әдәбият. Болгар-төрки телдә. Күчермәдән күчерүче – З. Максудова.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**288**
Шагыйрь Гомәр Рәүшани. «Чопан намә мәнзумә». Җәлаледдин Румидән тәрҗемә. Әдәбият. Болгар-төрки телдә. Күчермәдән күчерүче – З. Максудова.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**289**
Шагыйрь Газай Кырымлы (Гази Гәрәй хан). Лирик шигырьләре-газәлләре. Күчермәдән күчерүче – З. Максудова.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**290**
Зәйнәп Максудова. Кыскача фарсы-төрки лөгат-сүзлек. 309 сәхифә. Тел гыйлеменнән. Фарсы, төрки. Күчерүче дә Зәйнәп Максудова. Сакларга һәм үстерергә. Төрки аңлатманы кушарга.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**291**
Сәгъди. «Гөлестан». Тулы түгел. 36 кәгазь. Әдәбият. Фарсы телдә. Билгесез. Сакларга, тупланган гакаид китаплары белән.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**292**
Мөхәммәдшәриф бине дамелла Мөхәммәдрәхим бине Йосыф (Мәчкән авылында ахун һәм мөдәррис, вафаты 1854 елда).
رسالة فرض الادائمى «Рисалә фардел әдаими»
1 кәгазь. Фикъһе гыйлеменнән, татар телендә. Өзек өчен саклан-ды. Шиһабеддин Мәрҗани тарафыннан бу кеше хакында каты тәнкыйть язылган.
Мөхәммәдрәхимнең вафаты 1848 елда. «Мөстәфад»тә, 2дә 1819 елда дип бирелгән.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**373** (64)

قاضى زاده عثمانلى. وصيت پير گلى

**Казыйзадә Госманлы. «Васыят Пиргули»**
200 сәхифә. Гыйльме халь, төрки телдә. Күчерүченең имзасы һәм язылган елы, урыны күрсәтелмәгән. Пиргули тарафыннан төзелүе. Күчерелүе XVIII гасырда, чөнки 10 нчы кәгазьдә 1781 елны ачык күрсәткән су билгесе бар. Теле бик ачык. Каләме гүзәл, имлясы дөрест, китап таза, матур сакланган.
* 15×20. Кәгазь тышлы. Кустодлар бар, язу рәвеше татар тәгълигы, кара һәм кызыл каралар. Күчереп язучы: Әбу әс-Сәгыйд (89б кгз). Урыс кәгазе XVIII гасыр ахырына карый (су билгесе).
Башка нөсхәләр: Türkische Handschriften. Beschr. von Hanna Schrweide. Wiesbaden, 1974. P. 24.

**374**
Гакаид шәрхе. 87 кәгазь. Гакаид, гарәп телендә. 1213 һиҗри, 1799 миладида язылган. Урта Азия кәгазе һәм андагы тәгълikъ язуы.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.
Тагын бер язма белән бергә:

**375**
Гакаид. 88–361 кәгазь. Гарәп телендә. Мәүлана Бакы кулы белән язылган.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**376** (161)

حکیم ترمذی. کتاب نوادر الاوصول فی معرفة احتار الرسول

**Хәким Тирмизи. «Китаб нәвадир әл-ысул»**
208 кәгазь. Хәдисләр. Гарәп телендә. Билгесез насих хезмәте. Имлясы дөрест, рәсем хаты гүзәл.
* 19,3×29,2. Дермантин тышлыгы. 1б–4б битләрдә эчтәлеге күрсәтелгән, кәгазе XIX гасырның беренче яртысына карый, кара һәм кызыл каралар, язу рәвеше нәсех, музей пагинация, кустодлар бар, колофон юк.

**377**

**Һибәтулла бине Сәет Баттал Салихый (1794–1869). «Мәҗмәгел әдәб»**
90 кәгазь. Тәсаувыф. Төрки мәнзумә. 1856 елда Чабатлы авылы шәкертләре кулы белән күчерелгән.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

**378**

**Ибраһим Кыпчакый. Сөаль вә җавап**
11 кәгазь. Әдәбият. Төрки мәнзумә. 1856 ел нөсхәсеннән Зәйнәп Максудова кулы белән күчерелгән. Тагын 10 кәгазь 1790 елларда күчерелгән нөсхәсеннән Зәйнәп Максудова кулы белән күчерелгән.
* Бу кулъязма архивларда табылмады.

❖

## Зәйнәп Максудова ясаган кулъязмалар исемлегендә табылмаган кулъязмалар

* Кулъязма НМ РТ № 18369-74
15×21. 1 бит.
Колофон: تمت الکتاب بید الفقیر الحقیر احمد بن حسن عفرالله...
XIX гасыр ахыры, язу рәвеше шикәсте.
Тышында язылган:

مولود النبی هم قصیده له ر مجموعه سنده ن کیسه کچه عرب تلنده
ناظمی هم تاریخی بیلگوسز زینب مقصو

* Кулъязма НМ РТ № 18369-93
17,5×21,5. 57 бит.
Аннотация № 481, 481а
1) حاشیة التعریفات. عرب تلنده. عرب نحو درسلک
2) عرب صرفی. فارسی تلنده یازلغان. تولی توغل
Кәгазь тышлы. Кәгазе XIX гасырның икенче яртысына карый (штемпель «Императорской Петербургской бумажной фабрики»). Язу рәвеше нәсех, кара һәм кызыл каралар, кустодлар бар.
30б биттә: کتب عبد الخیر بن موذن زویَ لاجل محر الدین شرباقوی

* Кулъязма НМ РТ № 18369-101
**Панднамеи Гаттар.** 16×20. 21 бит. Кәгазь тышлы.
Башы юк. Су билгесе «1828». Фарсы телендә, язу рәвеше нәсех , кустодлар бар.
Колофон 21а биттә:

این کتاب روز یکشنبه شد تمام
و تمام شد این رساله ماه رمضان * کاتبه المسمی عبد الرحمن طارخان

* Кулъязма НМ РТ № 18369-102
16,5×2,4. 9 бит. Фарсыча. XIX гасырның беренче яртысына карый. Кәгазь тышлы. Башы һәм ахыры юк. Язу рәвеше нәсех. Авторы билгесез.
Кулъязманың башы:

آنچ كفت او در ميان صوفيان * پش شيخ خود بكفتند ان زمان
شيخ دانستش كه هست ان توبكار * هست دنيا را به هشش اعتبار
سه درم دادش بر عطار بر * آن چنان صدار و كه من كويم بحر

Бүлек исемнәре:

فى صيفت سيد المرسلين
قصه اعرابى در آمد نزد رسول عليه السلام
المواعظة فى ترك الدنيا فى الحال
قصه ايمان آوردن مسلمان شدن ترسان
در نصيحت گفتن مر سالك
حكايت سلطان ابراهيم بن ادهم با جبرائيل
حكايت شيخ جنيد رحمة الله عليه

* Кулъязма НМ РТ № 18369-113
**Таҗеддин Ялчыгол. «Рисаләи Газизә»**
15×20,6. 39 бит. № 597. Кәгазь тышлы.
Текст эчендә 1800 елгы басма буенча төзәтмәләр ясалган. Текст кызыл һәм яшел рамка эчендә. Кара һәм кызыл каралар, язу рәвеше нәсех, бит номерлары музейда куелган, кустодлар бар, башы һәм ахыры юк.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-114
Шул ук әсәр.
15×20,5. 38 бит. Башы һәм ахыры юк, язу рәвеше тәгълигъ, кара һәм кызыл каралар, текст кызыл рамка эчендә. Кустодлар бар, бит номерлары музейда куелган. XIX гасырның беренче яртысына карый.



* Кулъязма НМ РТ № 18369-116
**Хикәяте Мөхәммәд Хәнифә**
14,8×19,5. 01+56 бит. Яртылаш күн тышлыгы. Төрки телдә, кызыл рамка эчендә, каралар кара һәм кызыл, язу рәвеше тәгълигъ, бит номерлары музейда куелган, кәгазьдә су билгесе бар («1831»). Колофон 51б биттә:

اوشبو كتاب مضفار بن عبيد الله قرتوكلدى ننك بحق طه و يس
صاحب و مالك سعدين بن ايسحاق المرحوم عريف

Язма 01 биттә:

* Кулъязма НМ РТ № 18369-123
10,5×16,2. 1 бит. XIX гасыр. Хат язу үрнәге.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-124
11×17,6. 39 бит. № 190. 1б бит: шәехләргә багышлау. Калганнары – гарәпчә һәм татарча хөтбәләр. XIX гасыр башы, язу рәвеше нәсех, бит номерлары музейда куелган, кустодлар бар.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-125
10,6×17. 5 бит. № 273а. Аннотация:

18-19 يوز له رده يه شه گه ن تاتار شاعرى خليل نك شعر له رى.
شاعر نك اوزن بلدرگه ن سوزله رى صحيفه له رده اوچرى.

Су билгеләре («1748»), язу рәвеше тәгълигъ, кустодлар бар, кара каралар.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-126
10,7×16,8. 3 бит. № 259.

فرض عين كتابى توركى تلنده
فصول عمادى هدايه

«Фосул гимади һидайа»
XIX гасыр, тәгъликъ, кустодлар, кара каралар.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-127
9×15,5. 2 бит. Ислам диненең нигезләре. Кара каралар, нәсех, кустодлар.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-128

علم حال

**«Гыйльме хәл»**
11×17,7. 26 бит кара һәм кызыл каралар, тәгъликъ, бит номерлары музейда куелган, башы һәм ахыры юк, XIX гасыр башы.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-129
11,5×16,2. 9 бит. XIX гасыр. Шул ук.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-130
10,4×16,3. 6 бит. Догалар.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-131
10,7×16,5. 7 бит. «Ахыр заман китабы».

* Кулъязма НМ РТ № 18369-134
**«Мөхәммәдия»**
17×20. 195 бит. Катыргы тышлыгы күн почмаклары беләен. № 293. Гарәп телендә, кара һәм кызыл каралар, текст кызыл рамкада, бит номерлары музейда куелган, кәгазь күгелҗем төстә, XIX гасыр башына карый, кустодлар бар, язу рәвеше нәсех. Күчереп язучы – Габделмәннан б. Габделкәрим.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-139

الصديقى الدوانى .شرح العقايد الغضدية محمد ابن اسعد

**Мөхәммәд бине Әсгад әс-Садикый әд-Дәввани.**
**«Шәрхел гакаидел газадия»**



17,5×22,3. 10 бит. Тышлыгы юк. Язу рәвеше нәстәгъликъ, кара каралар, колофоны юк, юка кәгазь XIX гасырның икенче яртысына карый.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-140
16×20,5. 13 бит. Тәфкилев архивыннан рус һәм татар телләрендә документлар. Начар хәлдә. Аннотация:

اورنبورغ اولكه سى... رايونى آمالى آولى

XVIII–XIX гасырларга карый. Факсимиле IX карагыз.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-142
20,7×17. XVIII гасырның икенче яртысына карый.
1) فصل فى صفات الحاج, 22б бит – хатым хуҗа тәртибе.
2) Хәрефләрнең сихри мәгънәләре.
3) «Нәсыйхәтес салихин», төрки телдә. 63 бит. Колофон 59а биттә:

اوشبو كتاب نى يازغچى عثمان ننك ترور بن عبد السلم بن عثمان

Язу рәвеше нәсех, кара һәм кызыл каралар, кустодлар бар, каты кәгазь, бит саннары музейда куелган, реставрацияләнгән.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-144
10,7×16,7. 35 бит. XIX гасыр башы, шигырьләр җыентыгы (Әмдами, Мөхәммәдийа), ахыры юк. Кара каралар, нәсех.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-132/133/ 145/146/ 147/ 148/ 149/ 150/ 151/ 152/ 153/ 154/ 156/ 173/ 175/ 176/ 178/ 179/ 180/ 181/ 184/ 185/ 187/ 188/ 189/ 190/
Varia (шигырьләр, догалар)

* Кулъязма НМ РТ № 18369-171
**«Китабе саләт вә бәяне фараизел вакт»**
10×19. 203 бит. № 212. Күн тышлыгы калдыклары. Фарсыча. Кәгазь XIX гасыр башына карый, кара һәм кызыл каралар, кустодлар бар. Язу рәвеше тәгъликъ.
206б биттә: فى يد تخفت الله بن ملا جعفر بن ملا حليل



*Рис. 157.* Колофон рукописи. НМ РТ 18369-171, л. 206б

* Кулъязма НМ РТ № 18369-174
Кулъязманың фотокүчермәсе

هذه رسالة برهانية لمولانا برهان الدين فى حاشية اداب المناظرة

**«Һазиһи рисалә Борһания ли-мәүлана Борханеддин фи хашия әдабел мөназарә»**
Каян икәне билгесез. Күчермәнең датасы 18/12/1968. Авторның тулы исеме: Борһанеддин Ибраһим бине Юныс әл-Болгари.

* Кулъязма НМ РТ № 18369-182
Максудованың туганнары белән бәйле документлар. 8 бит.



* Кулъязма НМ РТ № 18369-203
15,5×22. 4 бит. Татар тәгълигы, кара һәм кызыл каралар, урыс кәгазе XIX гасырның икенче яртысына карый. Аннотация: «Идел буе төрки телдә язылган мәнзумә китаптан өзекләр. Мосаннифы билгесез. Елы билгесез, ләкин күчереп язу елын, кәгазьгә карап, су билгесе буенча табарга мөмкин. XVII–XVIII г. хатирәсе булыр. Бу өзекләр Казандагы Тел, әдәбият, тарих институтының хәдиме Нажия Борһанова тарафыннан Арча районыннан табылган. Ул миңа бүләк иткән иде».
Бүлекләрнең беренче җөмләләре:

قال الله تعالى و ان منكم الاولادهما

قال الله تعالى ان الله يغفر الذنوب جمعا

قال الله تعالى اثم تجى الذين التقو و نذر الظالمين فيها احتيا

* Кулъязма НМ РТ № 18369-204
11×17,5. 24 бит. Төрки телдә шигырьләр. Кәгазе XIX гасырның икенче яртысына карый.
Беренче баб:

اولوم ذكرى

الباب الثانى فى بيان طول امل

بيان السبب فى طول الامل و علاجه

بيان مراتب الناس فى طول الامل و قصره

فى الحديث حُبّ الشيخ شابّ فى طلب الدنيا

الباب الثالث فى سكرات الموت و شدته

بيان ما يستحب من احوال المحتضر عند الموت

بيان الحسرة عند لقاء ملك الموت بحكايت لطيفة

الباب الرابع فى وفات رسول الله صلى الله تعالى عليه و سلم

وفات ابو بكر الصديق رضى الله تعالى عنه

بیان عذاب القبر و سوآل منکر و نکیر
صفة طعام اهل الجنة

Колофон 24б биттә:

تم بعون الله تعالی بفضله و کرامه
... ۱۸۹۳ نچی ۳۰ نچی عنواردا تحریر ایتولدی
من نوشتم صرف کردم روزکار * من نمانم این بماند یادکار

---

* Кулъязма НМ РТ № 18369-208
15,5×21,5. 4 бит.

مولد النبی سلیمان بن داود اثری پیتر اقصو آولندا کوچرگه ن

---

* ВС ОРРК НБ КФУ, 740ф
Нәҗметдин Кубрага нисбатланган әсәрләр җыентыгы. Фарсыча һәм татарча. 1868 елда Ургенч шәһәрендә күчерелгән, кем тарафыннан билгесез.
12,5×21. 110 бит. Урта Азия тышлыгы, кара каралар, тәгълик. Зәйнәп Максудова тарафыннан ясалган комментарийлар очрый. Тышында «№ 3» дип тора. Шунда ук «фарсы телендә иске китап» дип билгеләнгән. 1965 елда хуҗасы тарафыннан Казан дәүләт университетына бүләк ителгән һәм 50 ел дәвамында тасвирланмаган хәлдә шунда саклanган.
Җыентыкның эчтәлеге:

1. 1а–41а, رساله در تصوف
2. 41б–62а, مرأة العابدین
3. 62б–69а, کتاب التصوف و اللحوال لنجم الدین کبری
4. 71б–78б, ابو العازی بن رسول مرأة العابدین
5. 79б–88а, رساله سلوک مبدأ نور



6. 88б–92а, تذکرة الاولیاء
7. 92б–110б, رسالة العازی نجم الدین البلغاری

---

* ВС ОРРК НБ КФУ, 6163Т
Суфичылык белән бәйле җыентык. 186 кгз. Бу китапны 30 декабрьдә 1987 елда китапханәгә Голшат Касыйм кызы Хәмзинә китерде.
48а кәгазьдә иянең язмасы:

اوشبو کتاب ایاسی کافیه بنت عبدالله آخوند سلیمانوف

(«Ошбу китап иясе Кафия б. Габдулла ахунд Сөйләманов»).
Колофон 117б кәгазьдә:

في ولاية البلغار و في قلعة تتوش خادم العلماء امام بیکتاش ابن بیك
محمد الجبلی

(«Фи вилаят әл-Болгар (!) вә фи калга Төтеш хәдимел голәмә имам Биктәш б. Бикмөхәммәд әл-Җәбәли»).
177б кәгазьдә Зәйнәп Максудованың язмасы:

بو سلسلهء مذهب کتابی جامی ننك سلسلة الذهب ندن ترجمة ه
1175 میلادی 1762 یلدا یازلغان

(«Бу «Силсиләи мәзһәб» китабы Җаминең «Силсиләтез зәһәб»еннән тәрҗемә. Һиҗри 1175 нче миляди, 1762 елда язылган»).

# Иске фиһристтә булган һәм архивларда табылмаган кульязмалар

**№ 10**

انموذج

Гарәпчә нәху. Мөхәммәд Әрдебили әсәре. 216 бит. Язучысы كاتبه عبد الحكيم بن ميكلو باى дип имзалаган. Елы күрсәтелмәгән. Кәгазендәге су билгесендә 1821 ел күрсәтелә. 210 нче биттә

ملكت هذا الكتاب بشرا صحيح فقير الحقير عبد الجميل بن عبد المنان

1852 سنه

дип язылган.

**№ 11**

Тәсриф.

بدان اسعدك الله дип башлана. 30 бит. Кайчан һәм кем язганы билгесез. Фәкать, тышлыгында: «Сарыф китабын укырга керештек Зөлкагъдә аеның 2 нче көнендә 1846 сәнәдә» дип язган. Язучысы – Габделҗәмил хәзрәт Максудов. № 11–12 бергә.

**№ 12**

Гарәп сарфы.

شرح عبد الله

Күчереп язучы – Габделҗәмил Габделмәннан углы Максудов. Тәмам иткән елы билгесез.

**№ 18**

ايساغوجى. اثير الدين ابهرى

**Әсир әд-Дин Әбһари. «Исагуҗи»**

Язучысы – Габделҗәмил Габделмәннан углы Тирсә авылында Ягъкуп бине Нигъмәтулла хәзрәт мәдрәсәсендә 1850елда 18 мартта язып тәмам иткән.

**№ 26**

روضة العلماء

**«Рәүдател голямә»**

Кем, кайчан язганы билгесез, фәкать, 50нче биттә «Китап Гомәр бине Габделгазиз» дигән язуы бар. Кәгазендә су билгесендә 1801 ел күрсәтелгән.

**№ 26 (!)**

عبد الحكيم بن شمس الدين

شرح عقائد نسفى

**Габделхәким б. Шәмседдин. «Шәрх гакаид Нәсәфи»**

Язучысы: Габделҗәмил Габделмәннан углы Максудов (1823–1924). Тирсәдә язылган.

**№ 32**

على بن احمد المكى الرازى

شرح قدورى

**Гали б. Әхмәд әл-Мәкки әр-Рази «Шәрх Кодури»**

Күчерүче: «Кәтәбә Габделваһаб бине дамелла...» дип куйган (139 нчы кәгазьнең аркасында).

Ахыргы битендә 1801 елның 9 нчы көнендә дигән, имзасы ертылып төшкән.

### № 35

عبد الحكيم بن شمس الدين. عبد الحكيم فى المنطيق

**Габделхәким б. Шәмседдин. «Габделхәким фил мантыйк»**
Язучы: «Җамаледдин тәзкирәт ли-Габделҗәмил», дип язган. Тарихы билгесез. Китап тулы түгел.

### № 36

حاشية على شرح ايساغوجى

**«Хашия галә шәрх Исагуҗи»**
Язучысы билгесез.

### № 37

Мантыйк китабы. Язучысы:

تم فى شهر بلغار و فى قرية تيرسه فى مدرسة داملا يعقوب بن نعمة الله
فى يد عبد الضعيف عبد الجميل بن عبد المنان البلغارى

дип язылган. Тарихы мәгълүм түгел.

### № 39

نصاب الاخبار لتذكير الاخيار

**«Насабел әхбар ли-тәзкирел әхйар»**
Язучысы: «Габделваһаб бине Мостафа вә фи карйә Дәвек фи мәдрәсә мелла Бикчәнтәй бине Юлдаш», дип язган. 1786 елларда, Пугачев вакытларында.

### № 40

حياة الحيوان

**«Хәятел хәйван»**
Язучысы: Габделваһаб Мостафа углы Дәвек авылында Минзәлә кантоны Бикчәнтәй бине Юлдаш мөдәрриснең мәдрәсәсендә язган.



### № 42

تحفة الفقهاء

**«Төхфәтел фөкаһаэ»**
Язучысы мәгълүм түгел. Салагыш авылында Тулмөхәммәд мелла мәдрәсәсендә язылган.

### № 43

الامالى

**«Әл-Әмали»**
Язучысы: ضاطى بن عبدش («Затый б. Габдеш»).
Салагыш, Алабуга кантонында 1781/1194 елда тәмам иткән Тулмөхәммәд хәзрәт мәдрәсәсендә.

### № 48

**«Бәдәвам китабы»**
Язучысы: Җәләледдин Габделваһаб углы Тирсә авылында Ягъкуп бине Нигъмәтулла хәзрәт мәдрәсәсендә 1851 елда язган.

### № 51

**«Мәрьям ана китабы»**
Элекке Сарапул өязе Исәнбай волосте Нарат авылында имам булып торган Габдессәттар хәзрәт китаплары арасыннан табылды. 15.7.1926. Зәйнәп Газизова (!).

### № 61

**«Гакаид китабы»**
Язучысы: Габделҗәмил Габделмәннан углы Максудов, Тирсә мәдрәсәсендә укыган чакта, 1847–52 елларда язган.

### № 62

Хөтбәләр мәҗмугасы, гарәпчә. Шул ук кеше.

### №77

تحفة الفقهاء

**«Төхфәтел фөкаһаэ»**
Язучысы: Нурмөхәммәд Сәйфеддин углы 1874 елда язган.

---

### № 87

فوائد ضيائية

**(«Фәваид зыяия»)**
Язучысы һәм язылган елы күрсәтелмәгән, фәкать, 1865 елда Урнаш баш авылының Әхмәдҗан Һәмзә бай углы Мәңгәр мелласы Таҗеддин бине Бәшир углына сатканын язган. Китап Дагыстаннан килгән булса кирәк.

---

### № 121

Мәрсия хәзрәт Задури. Тәншид Җәлаледдин бине Сәгъдеддин әл-Багуши әз-Задури Сембери әл-Болгари. Мәрсия иясе 80 ел гомер сөргән, хаҗи булган 1883 миладида.

---

### № 122

انموزج

**«Әнмузәҗ»**
Язучысы: Җәлаледдин бине Сәгъдеддин бине Вәлид бине Биккол бине Әлмөхәммәд бине Кәлаш.

---

### № 137

شرح شمسية

**«Шәрхе шәмсия»**
Язучысы: Таҗеддин бине Бәшир әл-Болгари 1838 ел миладида Казан шәһәрендә Байморад бине Мөхәррәм дигән мөдәрриснең мәдрәсәсен тәмам иткән. Китапның ахырында Таҗеддин бине Бәширнең үз тәрҗемәи хәле турында бераз мәгълүмат бар.



### № 140

**«Мохтәсарел викая»**
Күчереп язучысы: Әбу Бәкр бине Биктимер Казан вилаяте Йоры юлы Илкай бине Мостафа мәдрәсәсендә 1111 һиҗридә язган.



*Рис. 158.* Образец описаний рукописей из библиотеки ʿАбд ал-Джамиля Максуди. ИЯЛИ. Ф. 32. Папка 1. Документ 8

# Список старопечатных книг

## Татарстан Җөмһүрияте Милли музеенда саклана торган китаплар исемлеге

1. بو وعظ نامه رساله سى. قزان: مطبعه كريمى 1907 31 ص.
Максудованың автографы тышлыкта, № 215. Татар телендә.
Шифр 18369-213.
2. Шифр 18369-214а, б, в, г. Аннотация тышлыкта: № 286-289.

1) بلاغت عثمانيه. محمد عبد الرحمن اثرى. 1892 باسماسى 2) بالالار تربيه سى دوقتر بسيم اثرى 1902 يل باسماسى 3) سلطان مراد خامس نك خلعى. حسين حفظى اثرى 1908 يل باسماسى.

Автограф: زينب مقصودوانك صوفيه آپا طاهرواداں بوله ك. 1970 يل
Төрки телдә.
3. Шифр 18369-215. № 255. قزان. محمدية Типография Домбровского, 1909. Төрки телдә. 334 б.
4. Шифр 18369-223. № 58.

مجمع الامثال ياكه گوزل مقال لر. عطا الله فتح الله اوغلى مينييف

Казань: типография Каримовых, 1904. 168 б. Төрки.
5. Шифр 18369-222. № 241. Аннотация:

تحفه وهبى شعرله ر مجموعه سى 42 ص. استانبول

Элекке хуҗаның автографы:
تملكه بالملك الشرعى جمال الدين سلطانف Госманлы телдә.
6. Шифр 18369-221. Аннотация: № 75.

العواطف الحمديه فى السياحات النوريه من اثار الآخوند و المدرس نور على ابن الشيخ حسن القزانى. قزان: مطبعه كريميه قزان 1907 85 ص. قزقلى نرسه له ر بار

Татар телендә.

7. Шифр 18369-220. Аннотация: № 69.

فارابى. كتاب اراء اهل المدينه الفاجنله. مصر باسماسى. زينب مقصودواغه احمد عاسيف طرفندن هديه اتلگه ن.

Зур яшел мөһер титул битендә:
مدرسه محمديه كتبخانه سى قزانده 128 б. Гарәп телендә.
8. Шифр 18369-219. التاريخ الطبيعى Гарәп телендә. 20 г. башы.
Язмалар юк.
9. Шифр 18369-218. Аннотация: №65.

جمال الدين بن وليدى اثرى. تاتار تلينك مكمل تولى سوزلگى سوزلگى 1ج. 160 ص.

10. Шифр 18369-217. №200.

الجز الاول من وفيات الاعيان و آبناء الزمان تآليف القاضى أحمد الشهير بابن خلكان.

Гарәп телендә. Авторның кыскача биографиясе Зәйнәп апа кулы белән титул битенең кырыенда язылган. 526 б.
11. Шифр 18369-216. №189.

فتاوى هنديه 6 جزء عرب تلنده. 1894 مصر باسماسى

№190. فتاوى برازيه 2 جزء. عرب تلنده. 480 ص.
12. Шифр 18369-236. №9 كتاب مفيد العلوم و مبيد المهوم. Каир, 1896.
№10. كتاب المختار من نوادر الاخبار Гарәп телендә. 222 б.
13. Шифр 18369-235. آندن بوندن. ادبى جيه نتيك 94 ص تاتار تيلنده
14. Шифр 18369-234. №140.

رسالة منظومة. ا.فا مضافاتنده يومران قريه سنده امام نعمان افندى ننك اثرى. كندوسيننك حج سفرينه يورديكنى بيان ايلمشدر.

Казань: Типография Б.Л. Домбровского, 1896. 32 с. Титул битендә өстәмә язу:

: نعمان چوالکیب آولندا توعان. بو کتابنک آخرنده سمبر اویه زی طارحان آولندان بارب مدینه ده مجاور بولوب عمر ایتکان ضیأ الدین بلغارینک شعری ترکه لکه ن

**15.** Шифр 18369-233

سمبر اویازی مسلمان جمعتی نک مظامنامه سی. قزان مطبعه کریمیه 1908. 12ص. 177 №.

**16.** Шифр 18369-232. № 262. باقرغان مجموعه سی Шигъри өзекләр.

**17.** Шифр 18369-231. № 224.

تلخیص المفتاح. قسم الثالث. کتاب مختصر المعان (عرب تلنده). 216 ص. معان بیان بدیع علمله ری قاعده سی. مصنف سعد الدین تفتازانی. استانبول باسماسی. اوزبک خان اوغلی جانی بیک سلطان اسمنه باغشلاب یازلغان

**18.** Шифр 18369-230. № 214. فهرست القران. استانبول 1284. 144 ص.

Китап иясенең язмалары беренче биттә:

169 لقد اشتریته و انا الفقیر عطاء الله بن محمدی ...فی سنه 1297 و 20 فی ذی الحجه.

Мулла Абдуллин исеме белән түгәрәк мөһер. Астарак –

ملا محمد ذاکر بن شمس الدین الکویرباشی نک ملکنده 1926 نچی یل

**19.** Шифр 18369-229. № 55.

مصنف ابو المنهی اثری شرح فقه الاکبر الامام الاعظم. قازان باسماسی 1884 یل 186 ص.

**20.** Шифр 18369-228. № 5.

نصیحت الصالحین. قازاندا باسلغان. تولی توگل.54 ص.



**21.** Шифр 18369-227. № 233.

استوافی کتابی علم حال دن. 1894 یل قازاندا حسینفلار باسرغان. 68 ص. ترکی.

**22.** Шифр 18369-226. № 246-47. 16

16 یوز بغداد تورکله ری آراسندا یتشکه ن مشهور شاعر فضولی محمد بن سلیمان اثرله ری نده ن 1) دیوان الاشعار 2) لیلی و مجنون داستانی. استانبول 1898.

**23.** Шифр 18369-225. № 283.

کتاب مفاتح الجنان شرح شرعة الاسلام. یعقوب بن سید علی. 544 ص. عربی.

**24.** Шифр 18369-224. اختری کبیر. 1897. 1203 ص.

**25.** Шифр 18369-260. № 115-118.

1) رضا الدین بن فخر الین ابن بطوطه. اورنبورغ 1917. وقت. 48 ص. 2) امام غزالی. 96 ص. 3) داملا عالم جان البارودی. ی. آقچورا اوغلی. قزان شرف مطبعه سی 1907. 64 ص. 4) شیخ زین الله حضرت نک ترجمه حالی. اورنبورغ 1917 وقت 106 ص.

**26.** Шифр 18369-259. № 282. عاشق عمر داستانی عثمانلی تورکی. 32 ص.

Китап иясенең язмасы:

ملا صادق اوقوماق مناسب کورلدی

**27.** Шифр 18369-258. № 65.

لغات ثلث سه زبان اوچ تیل ملا عالم جان البارودی. بمطبعة الخزانة ببلدة قزان. 1311. 41 ص.

**28.** Шифр 18369-257. № 21

اصول تدریس. مؤلفی: اگرجی قریه سنده مدرسه جبلستانی ننک مدیر و معلم لر جمعتی

Казань: типография Домбровского, 1899. 36 б. Мөһер титул битендә: Указный мулла Сибагатулла Абдрахимовъ въ дер. Узунъ-Кувыкъ Симбирской губ. Буинского уезда.

29. Шифр 18369-256. № 145. قصهء طاهر ايله زهره. قزان 1914. 63 ص
Өстәмә язу титул битендә:

تزوچسى: ملا احمد ملا ظريف اوغلى اوراضايف القزجارى القورماشى 1879 نچى يلدل كوشه ر آولندا يازغان.

30. Шифр 18369-255. А. Васильев. О киргизском языке и его транскрипции. Оренбург: типография П.Н. Жаринова, 1896. № 418.
31. Шифр 18369-254. № 137. بدآ الامالى شرحنه حاشيه
32. Шифр 18369-253. № 47. مستفاد الاخبار الجز الاول. 1885. 267 ص.
33. Шифр 18369-252. № 155. آثار 2 نچى جلد 15 نچى جزء اورنبورغ 1908.
Зәйнәп апа комментарийлары битләр кырында.
34. Шифр 18369-251. Мөстәфад. Т.1. Өзекләр.
35. Шифр 18369-250. № 43. شهاب الدين مرجانى ناظورة الحق Битләр кырында Зәйнәп апаның мөһим өзекләргә төрки теленә тәрҗемәләре (карандаш белән).
36. Шифр 18369-249. № 2.

احمد زكى وليدى. تورك و تاتار تاريخى. 1نچى جزء. قزان: ملت 1912

Автограф титул битендә:

قدرى آبزى عياض افنديگه هديه م مؤلف 6/11 1913

Китап читендәге билгеләр Зәйнәп апа кулы белән гарәп графикасында куелган.

37. Шифр 18369-247. ملت باقچه سى حبيب اسحاقى اثرى. قزان 41 ص.
38. Шифр 18369-245. № 138.

صوفي الله يارنك ثبات العاجزين كتابي قزان 1808

Зәйнәп апа кулы белән китап битләрендә текстта җитешмәгән өзекләр өстәлгән. Шулай ук авторның биографиясе дә язылган.

39. Шифр 18369-244. №84.

عزيربک حاجى بگوف. ترک روسى ترک لغتى ناشرى محمد امين رسول زاده.

Баку, 1907.



40. Шифр 18369-243. №27. كتاب معجزنامه Беренче битендә Зәйнәп апаның аңлатмасы:

چيستاى تيره سنده كوچه رلگه ن بو قوليازما نسخه آزاغندا: كاتبه عينو الله بن فضلو الله بن محمد شريف بن ملا مر صليم بن سيد بن آق بيردى ملا... ديب تمام يتكه ن. كه عه ز نک بوش قالغان خبرنده 1826 يلدا عطاء الله وجوده كلدى. عطاء الله بن عين الله 1856 يلدا وفات بولدى ديب بلدركان. ديمک كتابنى كوچئروچى عين 1800 نچى يللاردا به لكى 1780 يللاردا كوچرگه ن بولور. ز.م. بو قوليازما نسخه قازان آكاديميا آرخيوندا ساقلان.

41. Шифр 18369-242. № 139. باقرغان كتابى 1806 قزان
42. Шифр 18369-241. № 96.

كتاب شرح المتين على عقايد النسفيه مصنف سعد الدين التفتزانى 1891

97. كتاب حاشية المولى مصلح الدين الكستلى

98. خيالى عقايد كلام علمندن

99. حاشيه على شرح عقايد.

43. Шифр 18369-240. № 157. كتاب ام كمال قزان 1899
44. Шифр 18369-239. № 158.

كتاب حضرت يوسف عليه السلام قزان مطبعه كريميه 1909

Ахыры кульъязмадан өстәлеп язылган:

بو صحيفه له رنى قازان آكاديميا فيلياللنداغى نوسخه دن كوچردم. ز.م.

45. Шифр 18369-238. تعبير نامه
46. Шифр 18369-237.

الجزء الثانى من تاريخ الاستاذ العلامة و الاديب زين الدين عمر بن الوردى.

Мөһер امين هنديه مصر № 25. Кызыл төстәге көнчыгыш катыргы төпләнмә басып төшерелгән бизәк белән. Төньяк-көнчыгыш археология һәм этнография музее китапханәсе штампы.

**47.** Шифр 18369-168. № 280.

شاعر سامی نک دیوان اشعاری مصردا 1837/1253

Китап иясенең язмасы:

من کتب الفقیر حافظ حسین راجی الشمنی عفر عنه القنی

Овал формалы мөһер: السید حسین راجی

**48.** Шифр 18369-167. № 161. دیوان رضائی Литография. Казань, 1860. Лотфулла бине мулла Гатаулла әл-Әлмәтинең кулы белән. 107 б. Титул битендә ике кара турыпочмаклы мөһер: محمد جان بن سمین الراجی...

Нахзацтагы язмалар:

1871 نچی سنه ده 21 نچی سنتابرده سه شنبه کون ایکندی دان صونک مکه مکرمه نک مجاور بدر الدین افندی وفات اولدی الله تعه حسن خاتمة ویرکای ایدی آمین بحرمة سید المعر و العجم.

**49.** Шифр 18369-279.

№184 . دیوان اشعار الخماسة و هو کتاب جلیل یحتوی علی ما جل فی هذا الباب من اشعار العرب العربأ جمعه واحد عصره و اشعر شعراء الاسلام ابو تمام حبیب الله بن اوس الطائی الشهیر. بمطبعة جمعیة الفنون فی بیروت سنة 1306.

Зәйнәп апаның кириллица һәм гарәп хәрефле автографлары белән. 88 б. Мөхәммәдия мәдрәсәсенең мөһерләре. Гарәп телендә.

**50.** Шифр 18369-280. № 222.

منیة المصلی. قزان چیرکوف خاتونی ننک ورثه لارییننک طبع خانه سنده 1895

Гарәп телендә. 56 б.

**51.** Шифр 18369-278. № 90. Литография. .کتاب سفینة الرؤساء 1269 /1853. Госманлы телдә. 195 б. Түгәрәк зәңгәр мөһер: «Указной имамъ № 5 кан. мечети в Казани. Абдурахманъ Мухаметжанович Галеев». Шунда ук автограф: احمد عبد الرحمن





*Рис. 159.* Титульный лист книги. НМ РТ 18369-167

Кара түгәрәк мөһернең берничә оттискасы:
محمد عبدالرحمن وف

Зәйнәп апаның битләр кырында яшел каралар белән ясалган язмалары.

**52.** Шифр 18369-275. № 28. .کتاب نهج البلاغة 1321/1903. 2 бүлек. Гарәп телендә, тулы диакритик билгеләр белән. 498 и 206 б. Зәңгәрле-каралы мөһер: یعقوب بن مصطفی

**53.** Шифр 18369-273. № 284, 285.

شرح فوائد ضيائية نور الدين عبدالرحمن الجامى اثرى

حاشية على فوائد ضيائية عصام الدين اسفرائنى اثرى.

Гарәп телендә. Литография. 567 б.

**54.** Шифр 18369-272. № 79.

كتاب افكار الجبروت فى ترجمة اسرار الملكوت. عرب تلنده ن كوچرلكان

علم هيئت درسلگى. مؤلفى باكو شه هر ى عالمى عباس قلى قدسى

محمد خان زاده وفاتى هجرى 1262 ميلادى 1846 يلدا يللى بر يه شنده

مترجمى سيد شرف حليل افندى حياتى زاده

كتاب استانبولدا 1265 ه 1849 م يلدا باسلغان

ز.مقصود

Тышлыкта өстәмә язу: مگل شيخ كتابى ديب بلم

**55.** Шифр 18369-271. № 14.

ترجمة المراد العارفين از تاليفات شيخ الله يار صوفى. قزان

اونيويرسيتينى1890

58 б. нахзацта язма:

اوشبو نى اوقوغوچى شريفه بانو ملا شراف الدين حاجى قزى موللين

Монда ук Зәйнәп апа кулы белән суфи авторлар
һәм аларның әсәрләре исемлеге язылып теркәлгән:
تصوف شاعرله رى هم عالمله رى

**56.** Шифр 18369-270. № 277. 1870 مرأت الاخلاف. قزان كوكوبين 195 б. төрки телдәге шигырьләр. Нахзацта – искә алынган шәхесләрнең исемлеге.

**57.** Шифр 18369-201. №170.

عبد الرحمن سعدى. كشئلك دونياسندا تل ئه ده بيات يازو هه م

الارنك تاريحى ئوسوله رئ

Татар телендә, 244 б.



**58.** Шифр 18369-200. الجزء الاول من تاريخ ابن الوردى 384 б. гарәп телендә, Зәйнәп апа битләр кырында ясаган билгеләр. Төньяк-көнчыгыш археология һәм этнография музее китапханәсе штампы. Кызыл төстәге көнчыгыш катыргы төпләнмә басып төшерелгән бизәк белән. Охшаш: № 46.

**59.** Шифр 18369-199. № 156.

شوريده حال كتابى منظومة شيخ عطار اثرى. شاعر احمد ابن كمال

ترجمه سى 1 باسما 1842 نچى يل قازاندا رحمة الله بن اميرخان

طرفندن باسترلغان. قوليازماسى 1744 ده كوچرلكان

99 б. Төрки телдә.

**60.** Шифр 18369-198. № 188.

الجزء الثانى من الحديقة الندير شرح الطريقة المحمدية للشيخ الامام

سيد عبد الغنى النابلسى الدمشقى الحنفى.

Литография. Гарәп телендә, 508 б.

**61.** Шифр 18369-197а, б. №70-71.

1) تاريخ الكامل 5-6 جلد 2) عجايب الاثار فى التراجم الاخبار

هامشه باسلغان

Гарәп телендә.

**62.** Шифр 18369-195. № 180. كتاب الاشباه و النظائر Гарәп телендә. 1881. 232 б.

**63.** Шифр 18369-196. № 195.

دخيرة العقبى حاشية على شرح الوقاية يوسف بن جنيد التوقاتى.

پيتربورغ 1889

Гарәп телендә, 644 б.

**64.** Шифр 18369-194. № 278. الجلد الثانى من فتاوى البزازية 502 б. Гарәп телендә,

ملک مصطفی بن ملا محمد صفا الاشتراکی استاذ مز اوبال یچ (؟) امامی
ملا محمد ذاکر حضرت جار اللین عالی جناب لرینک هدیه سی 1922
نچی سنه

Мостафа Сафин.

65. Шифр 18369-193. № 251–252. توضیح مع التلویح Казань: ун-т, 1896. 718 б.

تملک بالشرأ الصحیح عبد الحلیم ابن ملا عبد الجلیل الصلیوعوشلی
الاوضانی... 1897 نچی سنه ده 2 نچی دیکبرده 3 صوم ده 10 تین
کمش بهاء ایلان نفعنا الله تعالی به و الجمیع المؤمنین
اوشبو نی یازغان ابطامز ملا عبد الحلیم.
فی ملک محمد شاکر

66. Шифр 18369-192а, б. № 68.

الجز الاول من کتاب المستظرف فی کل فن مستظرف تألیف الامام
الاوحد العالم العلامة اللوذعی الفهامة الشیخ شهاب الدین أحمد
الابشیهری مصر 1320 – 1902. 360 ب

Гарәп телендә.

67. Шифр 18369-212. № 191.

کتاب تاج العروس 7 جزء مصر باسماسی. 426 ب

68. Шифр 18369-211. № 65.

الجزء الثانی من تاریخ الخمیس دیار بکری اثری 392 ب
سوداگیر محمد صفا اوغلی محمد صادق

69. Шифр 18369-269 а, б. № 192–194.

1) چاربردی عرب صرفی نحوی 2) سید عبد الله العجمی جمال الدین
حسینی نقراه کار 3) شیخ زکریا الانصاری الخرزجی اثری مناهج الکافیة
فی شرح الشافیة لابن حاجب 350 ب.



70. Шифр 18369-268а-г. № 54–57.

1) تفسیر الفاتحة محمد عبده
2) کتاب فلسفة القاضی ابن رشد اندلسی ابو الولید محمد
3) القسطاس المستفیم عزالی اثری
4) حجج القرآن احمد الارازی اثری
مصر 1323

71. Шифр 18369-267. № 42.

عملی و نظری تعلیم لسان عثمانی استانبول 1312

72. Шифр 18369-266. № 10.

کتاب تاریخ جریده جدیده قزان اونویرسیتیتی 1889. قربان علی خلیدی

Төньяк-көнчыгыш археология һәм этнография музее китапханәсе штампы. 71 б.

73. Шифр 18369-265. № 2. Baber-nameh Diagataice ad fidem codices petropolitani editit N. Ilminski. Cazani. MDCCCLVII. Китап кырында Зәйнәп апаның язмалары очрый. 508+4 б.

74. Шифр 18369-264. اسلام مجله سی. مای 1926 سان 1-13 اوفا
Шулай ук саннар: 3–15, 4–16, 5–17, 6–18, 7–19, 8–20, 9–21, 10.11–22.23, 12–24

75. Шифр 18369-263. № 95.

الفوائد البهیة فی تراجم الحنفیة مع التعلیقات السنیة علی الفوائد
البهیة ابی الحسنات محمد عبدالحی اللکنوی بن عبد الحلیم قزان
اونویرسیتیت. 1903 . 324 ب

Гарәп телендә.

76. Шифр 18369-261. № 103. ج. ولیدی. تاتار تلی گراماتیکه سی
Казань: Миллят, 1919. 172 б.

77. Шифр 18369-210. № 253-254.

مفاتح الجنان شرح شرعة الاسلام عین العلم
1882 یلغی قازان باسماسی

578 б.:

1908 نچی یلده نجم الدین علم الدین مناف اوغلانلاری صاروقلارنی 11نچی آپریلده صاحراغه چقاردیلار کوتوغه بیردیلار

78. Шифр 18369-209. № 208-209.

الجز الثامن من شرح الهداية و هو تنائج الافكار فی كشف الرموز و الاسرار شمس الدين احمد بن قودر المعروف بقاضی زاده افندی

503 б.

79. Шифр 18369-208. № 202–204.

الجز الاول من شرح فتح القدير كمال الدين بن محمد السيواسی مصر

478 б. мөһер кыршылган.

80. Шифр 18369-207. № 205–207. الجز الخامس من شرح الفتح القدير 547б.

81. Шифр 18369-206. № 48.

القسم الثانی من كتاب المستفاد الاخبار فی احوال قزان و بلغار قزان 1900

Күп сандагы өстәмәләр һәм аңлатмалар. 368 б. Галимнәрнең Зәйнәп апа кулы белән язылган шәҗәрәләре.

82. Шифр 18369-205. № 77.

الجلد الثانی من حديقة الجوامع استانبول مسجدله ری هم آلارنک امالاری حقنده تاريخی معلومات

623 б, 1867 г. Битләр кырында Зәйнәп апаның аңлатмалары.

83. Шифр 18369-203а,б. № 248

الجز الاول من تفسير القرآن جلالين 1319 مصر164 ب.

84. Шифр 18369-202. № 42. الجلد الثانی من مجمع الانهر 1892 г. 608 б.

صاحبه و مالکه امام المسلمين محمد علی شاه احمد اوغلی آيداروف.

85. Шифр 18369-204. № 186.

اصول فقه علمی شرح المنار مصر باسماسی 338 ب



**Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында саклана торган китаплар исемлеге (берсе дә тасвирланмаган)**

86. № 130.

عاليمجان ييراهيمف. املا تل ادابيات. مسه له له لر 1923 – 1911. قزان 1924

87. № 20. جلد اول از ترجمه وديات الاعيان لابن خلكان

88. № 15-17. 1) شيخ سعدی. گلستان تولی توگل Егерменче гасыр башы кульязмасы. Һәр бите европалы пагинация, һәр юл асты – татарчага тәрҗемә, кучерүче билгесез.

2) حاشية رمضان عقايد دن

3) حاشية خيالی باسما

4) متن عقايد لعمر النسفی

Кульязма иясенең язмасы: حاجی محمد ملا نک کتابی

89. № 24-26. علم اشيا

Кульязма иясенең язмасы: عبد الله بن ارسلان گرای اوغلی

90. سلمان باقرغان اثری 1905 قزان

91. № 134. Беренче тел-әдәбият конференциясе. Казан, 1927

92.

النصول الحديدة فی خلاف الاصول الجديدة. علاج الدين بن محی الدين القزانی

Казан, 1899.

93. № 146.

شاعر من اهل تصوف. صوفی الله يار كتاب مستطاب و شريف الماب ثبات العاجزين قزان 1914

94. № 154. Әүлия Челәби. منتخب 1863

Форзацта кульязма хуҗасының язмасы:

№ 112 نچی نومر دن متملكه الحاج محمد جان عليف

95. № 147. كتاب مستطاب راحت دل Казан, 1896.

96. № 141. عبد الرحيم الاوطوز ايمنی مهمة الزمان. 1898

# Биографии татарских *ʻулама*

**Мулла Сәгыйд бине Ибраһим бине Габдулла әл-Барыши (карт Сәгыйд хәзрәт буларак атаклы булган)**

Түбән Тау ягы Тәтеш өязе Барыш авылы халкы арасыннан чыккан. Бу кеше, мәдрәсә тотып, күп шәкерт җыеп, дәрес итеп илгә танылган. «Җирнең түгәрәклеге» хакында гарәп телендә язган китабы да бар. Кышкар авылында һиҗри 1211, милади 1797 елларда имамлык иткәне мәгълүм. Вафаты һиҗри 1229, милади 1814 елда булып, Кышкар авылында Казаклар каберлегендә күмелгән. Үлгән чакта яше 80 ләрдә булган. Туган елы 1734 елларга туры килә, димәк, бу кеше үзенең китабын унсигезенче йөзнең соңгы яртысында язган.

Мулла Сәгыйд бине Ибраһимның бертуган тутасы Кушлавыч мелласы Габделгазиз бине Гайсә әл-Көнәринең никахында булган, димәк, бу абыстай мелла Сәгыйдтән 3–5 яшькә зуррак булып, еллары Габделгазиздән 3–5 яшькә яшьрәк булуы мөмкин. Мелла Габделгазизнең бу хатыннан Фәез, Габид, Сөендек исемендә угыллары булган. Алардан мелла Фәез бине Габделгазиз башта – Сардәр авылында, аннары – Каргалыда, аннан соң – Бохарада, ниһаять, Кабулда укып, бик күп тансык китаплар җыеп, һиҗри 1217, милади 1802 елда Русиягә кайтып, Кышкарда мелла Сәгыйд бине Ибраһимга иптәш мелла булган. 1814 елда ул үлгәч, үзе генә имам булып калган. Зур мәдрәсә тотып, күп шәкерт җыеп, дәрес иткән. Һиҗри 1251, милади 1835 елда кинәт вафат булып, Кышкарда Казаклар каберлегендә җирләнгән. Фәез бине Габделгазизнең Закир, Гата, Лотфулла, Гобәйдулла исемендә дүрт углы калган. Гатаулла бине Фәез бине Габделгазиз бине Гайсә Түбән Көек авылында мелла булып торган. Әле 1888 миладида имамлык иткән. Мелла Лотфулла бине Фәез Иске Әҗем авылында мелла булган. 1888 елда әле исән булган. Гобәйдулла бине Фәез Семипулатта беренче мәхәлләдә Таш мәчеттә имам булган. 1911 (?) елда Семипулатта үлгән. Аның Габдулла исемле углы үзенә алмаш мелла булып торган. Мелла Закир Кышкар авылында мелла булган.

---

**Әш-шәех Бәһадиршаһ бине Сийаркол. Вафаты 1820 милади тирәсендә**

Уфа виляяте Бөре өязе Качмакты авылының мелласы Бәһадиршаһ бине Сийаркол Коръәннең ахыргы өлешен, ягъни сүрәи «әл-Фәтх»тән алып, ахыргы сүрәләргә чаклы төрки теленә тәфсир кылган. Бу тәфсир «Тәфсир Гайнәви» дип атала. Язучының төп чыгышы Гайнә башкортларыннан булуы сәбәпле булса кирәк. Тәфсирнең дибәҗәсе бик матур, гарәп теле белән язылган. Казанда 1275/1859 елда басылган. Бу һәфтияк тәфсире һиҗри 1219 елда, милади 1814 тә язылып тәмам булган икән. Мөфәссирнең кайчан һәм кайда туып вафат иткәне хакында мәгълүмат юк. (М. Рәмзи, Тәлфик. 415 с.)

---

**Әш-шәех Вәлид ахунд бине Сәгыйд әл-Минзәләбаши, аннары Каргалый**

Вәлид бине Сәгыйднең ата һәм бабалары Минзәләбашидән Каргалыга күчеп киткәннәр. Вәлид беренче гыйлемнәрне Карлы авылында шәех Габдессәлам бине Хәсән әл-Карылыдан, аннары Габделмәннан бине шәех Габдеррәхман әт-Тайсуганидән алып, Минзәләбаш авылында мөдәррис буларак урынлашкан (бу авыл Минзәлә өязендә шул ук исемдәге елганың чыганагында утырган). Вәлид ишан бик зур гыйлемле кеше булып, шигырьләр язарга да оста булган. Язган шигырьләреннән берсе бию-җырлауга бәйләнешле булып, фарсы телендә төзелгән. Шиһабеддин әл-Мәрҗани Вәлид бине Сәгыйднең шигырьгә осталыгын тәкъдир итеп, аның бу шигырен «Мөстәфадел әхбар» китабында да урнаштырган. Вәлид бине Сәгыйд (Вәлид ишан) күп еллар дәрес итеп, бик күп галим, меллалар җитештергән. Үзе Минзәләбаш авылында 1221/1806 елда вафат булган. (М. Рәмзидән алынды).

---

**Таҗеддин бине Габдеррәшид әл-Иштирәки, аннары әс-Саснави**

1850 нче елда үлгән. Үз заманының голямаларыннан гыйлем алгач, башта үзенең төп авылы Яңа Иштирәккә (Бөгелмә өязендә)

кайтып, мелла һәм мөдәррис булган, аннары Казан вилаяте Сасна авылына килеп мөдәррис булган. Гарәп телендә кайбер рисаләләр һәм төрки телдә мәнзумәләр язып калдырган. Һиҗри 1256, милади 1850 елда егерме тугыз яшендә үлгән.

### Мелла Ишмөхәммәд бине Заһид әл-Күбаки

Туган 1740, үлгән 1840 миладида. Уфа вилаяте Бәләбәй өязе Күбәк авылында туып, егерме ике яшенә кадәр укый-яза белмәгән. Барлык вакытын төрле уен коралларында уйнап, уен-көлке мәзәкчеләр белән үткәргән. Менә шул яшькә җиткәч, өйләнеп тә, яшь кенә хатыны Фатыйма бинт Гомәрне ташлап, берәүгә дә әйтмичә, йорттан чыгып юк була. Шул чыгудан җәяүләп Мәккә һәм Мәдинәгә барып, хаҗ кылып, андагы галимнәр белән очрашып, укыргаязарга өйрәнә. Күп кенә гыйлемнәр ала. Шуннан соң Мисырга барып, андагы галимнәр белән очрашып, алардан тагын гыйлемнәр ала. Шулай күп еллар (25 ел) төрле шәһәрләрдә, төрле галимнәр арасында йөреп, гали әхлак белән төзәлеп әйләнеп кайта. Элек ташлап киткән хатыны Фатыйма белән никах яңартып, Күбәк авылында мелла һәм мөдәррислек итеп яши. Йөзгә җиткәч, һиҗри 1256, милади 1840 елда вафат булган. (Ш. Мәрҗани. «Мөстәфад әл-әхбар». II).

### Шәех Габделхаликъ бине Ибраһим әл-Курсави

Габденнасыйр Курсавинең зур туганы Габделхаликъ бине Ибраһим башта үз тирәләрендәге голямадан гыйлем алгач, Бохарага китеп, анда хәлифә Ниязколый әт-Төрекмәни дигән шәехкә тапшырылган. Бу шәехтән һәм кече туганы Әбүнасыйр Габденнасыйрдан гыйлем алган. Аннары хаҗга китеп, кайтышлый Мисырга кереп, байтак вакыт тукталып, голүмел кыйраәт, тәфсир, хәдис өйрәнгән. Шуннан соң Диярбәкер шәһәренең мөфтие Мәүлә Әбү әс-Сәгудкә килеп, тагын кыйраәт гыйлеменә өйрәнгән. Шулардан соң Курсага кайтып дәрес иткән. كتاب فى الحديث исемле китап язып басырган. Беренче мәртәбә хаҗга барган. Гыйрак, Хорасан илләрендә сәяхәт кылып йөргән. Ахыр гомерен Курсада уздырып, шунда вафат булган. Үзе белән бертуганнарыннан Габденнасыйр исемлесе – Искедәрдә, Габдеррәшид – Бохарада, Габделкәрим – Мисырда, Габделхаликъ 1818 елда Курсада вафат булганнар. (Ш. Мәрҗани. «Мөстәфад», II).



### Мәчкәрә ахуны Мөхәммәдрәхим бине Йосыф бине Габделкәрим бине Арслан әл-Ашытый

Бу зат, асылда, Ашыт авылыннан булып, башта үзенең атасы мелла Йосыфтан һәм башка голямадан гыйлем алганның соңында, атасына иптәш буларак, Ашыт авылына мелла булган. Өч елдан соң Казанның мелла Ибраһим Хуҗашев белән бергәләп Дагыстанга барып, анда ун ел чамасы гыйлем эстәмәктә булган. Шуннан кайтып, Мәчкәрә авылына имам-хатыйб вә мөдәррис һәм тирә-як меллалары өстенә ахунд итеп билгеләнгән.

Мөхәммәдрәхим бине Йосыф ахунд Мәчкәрә авылында 1234/1819 елда вафат булып, шул ук авылда җирләнгән. Аның урынына Мөхәммәдшәриф исемле улы калган. XVIII–XIX гасырлардагы зур галимнәрдән бик күбесенә Мөхәммәдрәхим ахунд остаз булган. Шулар җөмләсеннән Әбүнасыйр Курсави, мелла Габдулла бине Яхъя әл-Чәртүши, мелла Сөбханкол бине Габделкәрим әл-Мәрҗани (Шиһабеддин Мәрҗанинең ерак бабасы), мелла Мөхәммәдәмин әл-казый, мелла Фәхреддин бине Габдеррәхман әл-Бәхтияри вә мелла Шәрәфеддин бине Зәйнеддин әл-Әстерле, вә мелла Нигъмәтулла бине Биктимер әс-Салавучи (ишан Әстерле), вә мелла Гаделшаһ бине ... әл-Исмәгыйли, вә мелла Таһир бине Сөбхан әл-Курмаши, мелла Хәсән бине Мансур әс-Сәрдеки вә Ихсан бине Гомәр әл-Мәмсәви һәм алардан башка бик күп кешеләр Мөхәммәд Рәхим бине Йосыфның шәкертләре булганнар. (Ш. Мәрҗани. «Мөстәфадел әхбар», 2 җилд).

### Казанда Борнай мәчете имамы Әбулфарук Мөхәммәдшакир бине Габделҗәббар

Вафаты 1921 елда. Кабере Казанда. Галим вә фазыйль имам Мөхәммәдшакир бине Габделҗәббар гарәп, фарсы һәм төрки телләрендә, фикъһедә зур гыйлем иясе булып, күп кенә китаплар язып калдырган. Аның китаплары хакында Ырынбур тәбгасыннан Ахун авылыннан имам вә мөдәррис вә хатыйп Муса бине Фәтхулла бине Хәбибулла бине Рәсүл тарафыннан, Казанда имам вә мөдәр-

рис фәриделгасыр Галимҗан әл-Баруди һәм башкалар тарафыннан күп кенә тәкъризләрне укыганым бар. Мөхәммәдшакир бине Габделҗәббарның язган әсәрләреннән миңа билгеле булганнары:

1. رساله‌ء معین الدین ترکی العبارة. 1299 سنه ده مطبوع

2. التنبیه الصحیح علی التوضیح. عربی العبارة. 1318 یلدا باسلغان

3. المعانی الجلیلة فی المکلمات المنجیة. عربی العبارة

4. الاقوال المعتبرة فی حقیقة المذاهب الاربعة. عربی العبارة

5. الفوائد الصفیة علی من ظن ضررا فی المقدمة الوفیة. عربی العبارة

Мәрҗани әсәрен хуплап язган.

6. التنبیهات المهمة علی بعض اناس خیر الامة. ترکی العبارة. 1910 میلادیده قازاندا مطبوع

һәм башкалар. Бу кеше һәм фәкыйһ, һәм шагыйрь, һәм вагыйз иде.

---

**Казан Госмания мәчетендә имам һәм мөдәррис Әбу Мөхәммәд Гарифулла бине Гыяседдин Мөхәммәди әс-Салихи (Чокрый)**

Әсәре: 1) رسالة فی جواز تعریف قاضی الحنفی بین الزوجین исемендә иҗтимагый мәсьәлә турында. Милади 1898 елда язылган. Бу 11 кәгазь – 22 битлек рисалә Уфада Крупская китапханәсендә саклана. 2) دیوان الصبیان

---

**Татар галиме Мөхәммәдҗан бине Кадырмөхәммәд әл-Вәриши (الورشی)**

Гарәп телендә رسالة الحث علی الایمان بالبعث «Үлгәннән соң терелү-кубарылуга ышану» хакында фәлсәфи бер унбер кәгазь – 22 сәхифәлек әсәре бар. Казан галимнәре арасында мөселман булыр өчен алты нәрсәгәме, җидегәме ышанырга кирәклеге хакында низаглар-ызгышлар барганын ишеткәч, бу китапны язарга булдым, ди мосанниф. Бу китап Уфада саклана. Елы күрсәтелмәгән.



**Казан галиме Сәгыйд бине Хәмиди Бәрәскәви Бистәви**

Вафаты һиҗри 1272, милади 1856 елда Казан шәһәрендә. Беренче мәчетендә имам һәм мөдәррислек иткән. Башлангыч гыйлемнәрне Габдеррәхим бине Бикчәнтәй Бәрәскәвидән, Урада Фәтхулла бине Хөсәеннән, Орнашбашында мелла Габид бине Габделгазиздән, Ашытта Габденнасыйр бине Сәйфелмөлектән укып, Бохарага китеп, күп галимнәрдән укып, тирән гыйлем иясе булып җитешкән. Имам һәм мөдәррислек хезмәтләре белән бергә, китаплар язу белән дә шөгыльләнгән. Мәсәлән, гарәп телендә خلاصة الرسالة فی حق تزویج اهل الکتاب من النصاری و الیهود исемендә иҗтимагый һәм фәлсәфи әсәре бар. Уфада Крупская исемендәге китапханәдә саклана. Мәрҗани белән аралары бик салкын булган (Ш. Мәрҗани. «Мөстәфад әл-әхбар», с. 40).

---

**Мелла Хөсәен бине Нигъмәтулла**

исемле бер татар галиме, шагыйрь, хафиз һиҗри 996, милади 1588 елда төзегән مرآت الاخلاق исемле олуг мәнзумә китабын 1816 елда күчереп язып чыккан. Үзе туган 1792 елда. (Уфа, шифр № 116).

---

**Төрки мосанниф дамелла вә мөхтәсиб вә имамел җамигъ Заһиреддин Әбулфәез Габдеррәхман бине Габбас әл-Бохари тәхсилән сүммә әл-Болгари тәхсилән вә мәүлүдән**

Әсәре: гарәп телендә фикъһ һәм фәраиз дәреслеге. Азагында هذا مسود القر من محتسب داملا... дип үзенең исемнәрен, күнья һәм ләкабләрен төзегән. Елын, урынын күрсәтмәгән. Бу кульязма Уфада Крупская исемендәге китапханәдә саклана.

---

**Бәләбәй өязе Сарай авылында имам, мелла Гыйлаҗеддин мөдәррислек иткән**

Аның милкендә «Мелла Касыйм» исемле гакаид шәрхе булган. Һиҗри 1228, милади 1806 елда Гайсә бине Габдессәлам бине Габделкәрим бине Исхак бине Әзетле кулы белән күчерелгән. Соңыннан Мөхәммәдшәриф Иштирәки кулында, аннан Хәлил бине Зәйнулла милкенә күчкән. Уфа. Мелла Гыйлаҗның Әхмәдзәки исемле улы 1875 елда исән булган. Атасының китапларын саткалап яшәгән.

**Троицки шәһәрендә Җамаледдин бине Сөбханкол**

исемле мөдәррис мәдрәсә тоткан. 1881 елда аның дәресендә дәвам итүче Хәлилулла бине Зәйнулла Ләкәнди исемле шәкерт гарәп теле сарфын язып чыккан, 1885 елда «Фәраиз...» китабын күчереп язган.

**Гөзенфәр хәзрәт (Гөзенфәр бине Фәзаил бине Йортмөхәммәд бине Бикмөхәммәд)**

Әгерҗе районы Тирсә авылында Гөзенфәр бине Фәзаил исемле бер мөдәррис булган. Бу кеше

رسالة داملا عبد الناصر بن ابراهيم القزانى من قرية قورصاً فى بيان فريضية صلوة العشاء فى البلاد التى لا يغيب فيها الشفق

дигән китапны һиҗри 1236 ел 21 мөхәррәмдә, милади 1820 ел җөмадиәлахирнең 20сендә язып тәмам иткән. Китапның ахырында:

كتب عضنفر بن فضائل حين قراره فى قرية ترسا من توابع نهر ايش

дип язып куйган. Борынгы кулъязмадан күчердем. Бу китап Салагыш авылы Гыйнаят абзый Адилов кулында иде. Мин аны 1919 ел җәй көне алар өендә укыдым.

Тирсәдә крепостной бәйлелек вакытында ук Тәфкилев дигән мирзалар тарафыннан мәдрәсә дәвам итеп килгән. Мөдәррисләреннән миңа мәгълүм булганнары: Газәнфәр һәм Ягъкуб хәзрәтләр булып, заманасының мәшһүр голямасыннан саналмаган.

**Уфа ягында Куганакбаш авылында Шәйхелислам бине Тимербәк бине Вилдан**

исемле галим мәдрәсә тоткан. 1871 елда аның янында Хәлилулла бине Зәйнулла исемле шәкерте Әбһаринең «Исагуҗи» исемле китабын күчереп язган. Уфада.

**Уфа ягында Балыклыкүл авылында ахунд Хөснеддин бине Шәмседдин**

исемле мөдәррис мәдрәсә тоткан. Анда Габделкадыйр бине Нияз исемле шәкерте جامع الاهم «Җәмигел әһәмм» исемле фикъһ китабын күчереп язып чыккан. Китапның мосаннифе, язылуы, күчерелү еллары күрсәтелмәгән. Уфа.



**Курса авылының имамы мелла Ногман**

һиҗри 1136, милади 1724 елда (мелла Габдулла дигән кешенең рисаләсенә хашия рәвештә) үзе бер рисалә язган. Шул китапны Гөзнәфәр хәзрәт күчереп чыккан.

**Вятка губернасы Малмыж өязе Урбар карьясендә мелла Ибраһим бине Габдулла әл-Барышый сүммә ән-Нократый**

һиҗри 1193, милади 1779 елда мәдрәсә тотып, шәкертләр тәрбия кылган. Шул мәдрәсәдә укыган шәкертләрдән Габдеррәхим бине Габдеррәшид бине Госман бине Симуш شرح الفرائض مير سيد شريف «Мирсаед Шәриф шәрхел фәраиз» дигән китапны һиҗри 1191, милади 1777 елда Саба авылында язып тәмам иткән. Үземдәге кулъязма китапның ахырыннан күчерелде. Искәрмә: мелла Ибраһим бине Габдулла Нократыйның... исемле кызы безнең ерак бабабыз Габделгазиз Кошлавычның (бине Гайсә Көнәри) никахында булган. Ул кыздан Габид, Фәез, Сөендек исемле уллары дөньяга килгәннәр.

**XIX йөздә татар галиме мелла Җәгъфәр бине Салих Кулаткый (Сукыр ишан)**

Саратов өлкәсе Хвалын өязе Кулатка авылында туып-үсеп, яшь вакытында үз илендәге галимнәрдән (бигрәк тә Спас өязе Баллы күл авылының ишаны һәм мөдәррисе Габделхаликъ әл-Болгаридан) укып, бер дәрәҗә мәгълүмат алганнан соң, Мәвәреннәһер – Урта Азиягә киткән. Анда Бохара һәм Нәсеф шәһәрләрендә берничә ел яшәгән. Соңыннан Хорасан өлкәсе буйлап сәяхәт кылган. Аннары Багдад, Шам, Мисыр илләренә барып, сәяхәт кылып йөргән. Шул илләрнең бик мәшһүр галимнәре, шәехләре белән очрашып, мәгълүмат җыйган. Аннары Һиҗаз иленә чыгып, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренә барып хаҗ кылгач, сәяхәтен төгәлләп, туган иленә кайткан. Туган авылы Кулаткада мөдәррислек һәм шәехлек итеп, сиксән яшенә җитеп, һиҗри 1279, милади 1863 елда вафат булган. Тумышы һиҗри 1200, милади 1783 елларга туры килә. Шәкертләреннән-мөритләреннән мәшһүрләре:

1) Бәрәңге авылының мелла Габделлатыйф ишан бине Халит бине Җәгъфәр бине Алтынбай.

2) Тәлчәй авылының имамы Габделлатыйф бине Биккол.
3) Казан мелласы Хәсәнеддин бине Гомәр.
4) Задур авылы имамы һәм ишаны Фәтхулла бине Вәлид һ.б.

### XVI йөз Казан татар галиме Разыйэддин Әбү Әхмәд әш-Шәфигый

Бу кешенең туган-үлгән еллары, урыннары хәзергә ачыкланмаган. Шулай да خلاصة الاثر исемле биографик тәрҗемәи хәлләр китабында 1598 милади елда вафат булган Җамал әл-Мисрыйның атаклы шәех Әбү Бәкер бине Галинең тәрҗемәи хәлен сөйләү уңае белән аның остазлары да санап үтелгән. Әбү Бәкер бине Галинең остазларыннан берсе итеп шәех Разыйэддин әл-Казани әш-Шәфигый да күрсәтелгән, ләкин шуннан артык мәгълүмат бирелмәгән. Тагын ул шәхеснең Шәфигый мәзһәбе тарафдары булуы гаҗәп, чөнки, белгәнебезчә, Казан кешеләренең күбесе Хәнәфи мәзһәбендә булганнар. Гәрчә чит илләрдә озак гизгән, яшәгән казанлы төркиләр арасында Шәфигый мәзһәбендә булучылар мәгълүм. Мәсәлән, андый кешеләрдән Шәхресәбездә яшәп калган Казан татары. Шулай ук Мөхәммәд Рәмзинең تلفيق الاخبار («Тәлфыйкел әхбар») китабында мосанниф болай яза: «Бер вакыт Мәккә әһеленнән булган минем дустым Мөхәммәдсалих әл-Мәймәни миңа аерым кәгазьләрдә язылган, таркалган берничә шигырьләр кульязмасын бүләк итте. Аның өстәге кәгазендә «дустыбыз Әхмәд бине Разыйэддин әл-Казани әл-Мәкки әйтте...», дип язылган» бер гыйбарә бар. Ләкин ул гыйбарәдә язучының исеме, җенесе, милләте, аннан башка билгеләре берсе дә күрсәтелмәгән иде. Шулай да мин бу Әбү Әхмәд дип күрсәтелгән зат Разыйэддин Казанинең углы булгандыр дип уйладым.

❖



### XIX йөз азакларында яшәгән татар мәдрәсәләре

1. Арча өязе Кармыш волосте Казыйлы авылы мәдрәсәсе.
2. Арча өязе Кармыш волосте Курса авылы мәдрәсәсе. Әбүнасыйр Курсави дәверендә атаклы уку йорты булган.
3. Мамадыш өязе Сатыш авылы мәдрәсәсе.
4. Арча өязе Кышкар авылы мәдрәсәсе.
5. Малмыж өязе Урбар волосте Түнтәр авылы мәдрәсәсе һәм Урбар авылы мөдәррисе – мелла Ибраһим бине Габдулла.
6. Чистай өязе Кизләү авылы мәдрәсәсе.
7. Чистай өязе Мәчкәрә мәдрәсәсе.
8. Чистай өязе Мазара мәдрәсәсе.
9. Сарапул өязе Әгерҗе волосте Әгерҗе мәдрәсәсе. Фәхреддин хәзрәт, Җәгъфәр хәзрәт, Газанфәр хәзрәт, Нигъмәтулла хәзрәт, Ягькуб хәзрәт, Хәсән ахунд, Галиулла, Мөхәммәдгата меллалар. 1730 елда – Мәннакол, 1760 елларда – Иманкол.
10. Сембер губернасы Шәйморза авылы мәдрәсәсе.
11. Сембер губернасы Тау иле мәдрәсәсе.
12. Сарапул өязе Әгерҗе волосте Иж-Бубый авылы мәдрәсәсе. Ул мәдрәсәдә укып чыкканнар: Габделкәрим бине Хәлил, Нигъмәтулла бине Мөнасыйб, Габделгалләм бине Нигъмәтулла, Габдулла һәм Гобәйдулла бине Габделгалләм Бубый.
13. Казанда: Касыймия, Мәрҗания, Мөхәммәдия, Госмания мәдрәсәләре, Закир хәзрәт, Тайиб хәзрәт мәдрәсәләре.
14. Ләбибәи Хөсәиния, Мозаффария, Аитова исемендәге кызлар мәктәпләре.

---

### XVIII йөздә мөдәррислек иткән татар галимнәре

1. Ибраһим мелла бине Габдулла ән-Нократи, Урбар авылында укыткан. 1779 елда шул мәдрәсәдә укып ятучы Габдеррәхим бине Габдеррәшид бине Госман бине Сәмуш исемле шәкерте «Мирсәед Шәриф фи шәрхил фәраиз» исемле китапны күчереп чыккан.
2. Мелла Габдәш бине Габдессәлам Хәерби авылында мөдәррислек иткән. Максуд бине Корбангали исемле шәкерте 1790 елда шул мәдрәсәдә «Фәваидез зияийа» исемле гарәп теле нәһүе китабын язып чыккан.

3. Мелла Йосыф бине Габделкәрим бине Арслан Ашыт авылында мөдәррислек иткән. Аның улы һәм шәкерте Мөхәммәдрәхим бине Йосыф атасы янында мөдәррислек итеп, аннары Дагыстанга барып, ун ел буе укып кайткан. Мелла Йосыфның вафаты милади 1780 елда булыр.
4. Мәннагол мелла бине Имангол Әгерҗе ягы Тирсә авылында мөдәррислек иткән. Аның мәдрәсәсендә 1760–70 елларда укып яткан шәкерте Бәшир бине Габдулланың язган мәҗмугасы сакланган.
5. Мелла Габдулла Оренбург ягы Алмалы шәһәрендә мөдәррислек иткән. Аның шәкертләреннән – Сөләйман бине Локман. Аның 1790 елларда язган шигырьләр мәҗмугасы сакланган.
6. Шәех Габдессәлам бине Хәсән исемле мөдәррис бик озак еллар Кариле авылында мөдәррислек үткән. Вафаты 1768 елда.
7. Шәкертләреннән мәшһүр Вәлид ахунд бине Сәгыйд. Минзәләбашы авылында күп еллар мөдәррислек итеп, 1806 елда вафат булган.
8. Тулмөхәммәд (Тулбай) бине Дусмөхәммәд Алабуга өязе Салагыш авылында озак еллар мөдәррислек иткән. 1790 елны аның хозурында укып ятучы шәкерте «Гокуде мәнзумә» исемле фикъһ китабын язып чыккан.
9. Мелла Салимҗан бине Дусмөхәммәд Кавал авылында күп еллар мөдәррислек иткән һәм китаплар язган. Мәсәлән, Болгардагы ел, ай, көн хисаплары, авырлык үлчәүләре хакында язган хезмәтләре бар. Аның хозурында укып ятучы шәкерте 1772 елда «Нәһҗел фәрадис» китабын остазына бер сум акча хакына күчереп язып биргән. Бу китап Казан Techинститутында саклана.
10. Таҗеддин бине Гыйсмәтулла бине Сатулган бине Сөләйман бине Акманай бине Атай бине Балагуш бине Байсары бине Кадырбакты бине Агҗак бине Бирдебәк бине Аллаһыгаввас бине Тугызак бине Бозуби бине Санкрат. Нуры өязе Чишмә авылында мөдәррислек итеп, китаплар язу, шигырьләр төзү белән шөгыльләнгән. Аллаһияр Суфиның «Морадел гарифин» исемле китабын фарсычадан төркичәгә тәрҗемә иткән. Вафаты 1783 елда Чишмәдә, туган елы – 1720.
11. Мелла Мәсгуд бине Мөхәммәд. Вятка губернасы Янгол авылында мөдәррислек һәм казыйлык иткән. Шәкертләреннән атаклырагы – мелла Әбүбәкер бине Ибраһим бине Йосыф Казанлы. Вафаты 1794 елда.
12. Мелла Мөхәммәдәмин бине Ярмөхәммәд бине Мәмаш. Казанда Яңа Бистәдә Ишкәй мелла мәчете дип аталган беренче агач мәчет хозурында имамлык һәм мөдәррислек иткән. Һиҗри 1146, милади 1734 елда гарәп нәхүе буенча бер дәреслек китабын үз кулы белән күчереп чыккан. Һиҗри 1154, милади 1741 елда шул мәчет мәдрәсә файдасына Морадбакый бине Мәмәкәт әл-Болгари әл-Казани тарафыннан вәкыф (бүләк) ителгән «Гыймадел ислам» исемле китапны рәсми рәвештә теркәп беркеткән. Хатын патша Елизавета хозурына Казан халкының үтенече белән таш мәчет салырга рөхсәт сорап Петербургка барган, анда хатын патшаның прием(ын)да булган. Әйбәт кабул ителгән. Петербург китап хазинәләрендә булган, кирәкле китапларны сайлап алырга рөхсәт алган. Мөхәммәдәмин мөдәррис «Фәтва Казыйхан», «Шәрхе Никая лиш-Шәмни», «Сихах әл-Җәвәһри» (сүзлек) китапларын үзе белән алып кайткан.
13. Мелла Илкәй бине Мостафа. Вафаты 1780 елларда. Арча ягы Зурлы (?) юлы Алушка авылында мөдәррислек иткән. Шәкертләре күп, заманына күрә белемнәре тирән, хөсне хатка оста булганнар. Мелла Илкәй үз кулы белән бик гүзәл хөсне хаттан файдаланып, Хөсәен Вагыйзинең фарсы телендәге тәфсирен язып чыккан. Бу кулъязма Казан педагогия институтында саклана.
14. Мелла Хөсәен бине Габделкәрим бине Ярмөхәммәд бине Җансари әл-Орыви әл-Болгари. Фәраиз гыйлеме остазы. Вафаты һиҗри 1152, милади 1793 елда Ор шәһәрендә. Бу кеше Әгерҗе, Ошмай, Олуг Куллар авылларында озак еллар мөдәррислек итеп, соңында туган авылы Орыга кайтып вафат булган. Хәбибулла, Фәтхулла (ишаннар) һәм Гобәйдулла, Исхак исемле дүрт улы гыйльми остазлык һәм тәрбия эшләре алып барганнар. «Мөстәфад әл-әхбар», 2, с. 190.
15. Мелла Габдеррәзак бине Ишмөхәммәд бине Тимер Кәтернаҗи (?). Вафаты 1770 елларда. Бу кеше Түнтәр авылында кырык ел мөдәррислек иткән. Габдулла бине Надир исемле шәкерте аның алдында 1759 елда Зинҗанинең китабын һәм Мотаразинең

«Мисбах» исемле нәху китабын күчереп язып чыккан («Асар», 2; «Мөстәфад әл-әхбар», 2, с. 202).

16. Мөдәррис, ахунд Габдессәлам бине Урай (Уразмөхәммәд) бине Колмөхәммәд бине Кылычвар. Төп чыгышы – Мәңгәр.

17. Мелла Сәгыйд. Бу кеше Карил исемле авылда мөдәррислек иткән. Аның шәкертләреннән берсе милади 1757 елда шагыйрь Сөләйманның «Мәүледен нәби» мәнзумәсен һәм намәгълүм бер шагыйрьнең «Дастане Касам» исемле мәнзумәсен күчереп язып, тарихи белешмәсен, елын күрсәтеп калдырганнар. Бу кулъязма Казан гыйльми китапханәсендә саклана.

18. Мелла Габдеррәшид бине Мортаза бине Исмәгыйль бине Мәмәт бине Нурмөхәммәд бине Бисуфи бине Муса бине Мамадыш бине Үтәмеш бине Хөсәен бине Җәгъфәр (казый шәһре Болгар – Ус мәхәлләсендә). Төп чыгышлары – шәһре Болгардан. Вафаты һиҗри 1212, милади 1799 елда. Бу кеше Ыспас өязе Акмат (Әхмәт) авылында утыз ел мөдәррислек иткәч, яңа Иштирәк авылына күчеп, анда ун ел мөдәррислек иткән. Аның улы Таҗеддин бине Габдеррәшид Малмыж өязе Сасна авылында мөдәррислек иткән.

19. Габделлатыйф бине Габдесәлам бине Уразмөхәммәд бине Колмөхәммәд бине Кылычвар. Вафаты һиҗри 1194, милади 1780 нче елда. Бу кеше Сәгыйд Каргалысында имам һәм мөдәррислек иткән. Дәресләренең көчлелеге, шәкертләренең күплеге белән шөһрәтле булган.

20. Шәех Габделкәрим бине Балтай. Вафаты 1171 һиҗри, 1757 милади елда. Сәгыйд Каргалысында. Бу кеше Сәгыйд баба белән бер үк елда Каргалыга күчеп килгән һәм беренче салынган мәчеттә имамлык һәм шәехлек иткән. Аның өчен Бохарага барып, шәех Хәбибулла әл-Балхидән тәсаувыф гыйлеме буенча тәгълимат алып, иҗазәтнамә белән кайткан.

21. Аның улы мелла Исхак бине Габделкәрим бине Балтай (Көмешче мелла). Вафат 1212 һиҗри, 1800/1 милади елда. Бу кеше шул ук Каргалыда имам һәм мөдәррислек иткән.

22. Мелла Рафик бине Уразай. Бу кешенең шәкертләреннән Хәмид бине Ишбай Исмаиси 1784 елда шул мәдрәсәдә укыган чагында «Сәйфелмөлек» исемле төрки мәнзумәне күчереп язып, Дәүләтшаһ бине Илбәк исемле дустына бүләк иткән. Кулъязма үземдә саклана.

23. Мелла Шәмседдин әфәнде бине Габдеррәшид бине Габдессәлам әл-Казани. Вафаты һиҗри 1207, милади 1793 елда («Мөстәфад әл-әхбар», 100 б.). Бу кеше Казанда Яңа Бистәдә алтынчы мәхәлләдәге Таш мәчеттә имам һәм мөдәррис булган һәм тирә-як имамнар өстеннән ахундлык иткән. Казанда һәм тирә-як авыл халыклары арасында калыккан иҗтимагый һәм хосусый дәгъваларны чишеп, тиешле карарлар чыгаручы хакимлек вазыйфаларын үтәп йөргән. Бу җәмәгать хадиме буларак, һәрвакыт янында бер язучы сәркатип булган. Үзе Дагыстанда укыган булырга тиеш, чөнки «әфәнде» кушаматын күбрәк Кавказ, Кырым, Анатолиядә укыган кешеләргә бирә торган булганнар. Дәресләре кызыклы, шәкертләре күп һәм иҗтиһадлы булганнар. Мәшһүрләреннән берсе – Күлбаш авылы имамы мелла Максуд бине Корбангали бине Аднакол бине Мәскәү Хәербиви һәм башкалар. Максуд шәкерт шушы мәдрәсәдән соң Хәерби авылында Габдәш бине Габдессәлам мәдрәсәсендә укыган булса кирәк. 1790 елларда «Фәваидез зийаийа» дигән кулъязмасы миндә саклана.

24. Аның бертуганы – Фәхреддин бине Габдеррәшид бине Габд. Вафаты һиҗри 1214, милади 1800 елдан соң. Бу кеше шул ук мәчеттә имам-хатыйб булып, Мәхкәмәи шәргыягә өченче мәртәбә сайлаулар булганда казый итеп сайланган 1800 миладида.

25. Шуларның атасы Габдеррәшид бине Габделәсам (Саңгырау). Вафаты милади 1770, һиҗри 1183 елда, Казанда. Шул ук елда язган васыятьнамәсе сакланган. Һиҗри 1182 елда язылган («Мөстәфад әл-әхбар», 98 б.).

Казан дарелфөнүн хизанәсендә «Нигъмәтулла» исемле бер фарсы-төрки сүзлек саклана. Аның кәгазьләрендә «Мең дә йите йөз дә сиксән йитенче елда, мартның икенче көнендә, Яңа Бистәнең бән, мелла Шәмседдин мелла Габдеррәшид мәрхүм углы ошбу «Нигъмәтулла» китабны көнде ихтыярым илә багышладым вә һиббә кылдым вә һәм кабтыз (قبطز) калдырдым. Казанның Иске Бистәнең тәрҗеман Сәгыйд Хәлфинкә вишкә (ويشقة) үз әлем илә язып вирдем» дигән язма бар. Тагын «Сахибүһ вә маликүһ

Габдеррәшид бине Исмәгыйль» дигән язуы бар. Бу җөмләне укыгач, мелла Габдеррәшиднең атасы Исмәгыйль булганы аңлашыла. Хәлбуки, Шиһабеддин Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар»ның «мелла Габдеррәшид бине Гаед әл-Казани» дип аталган.

26. Мелла Бикчәнтәй бине Ибраһим Сабави Бәрәскәви. Төп чыгышлары Саба авылыннан. Вафаты һиҗри 1215, милади 1800 елда. Бу кеше Бәрәскә авылында егерме сигез ел мөдәррислек иткән һәм Оренбургта Мәхкәмәи шәргыя ачылгач, беренче чиратта, казый булып сайланып киткән. Гыйльми әрәсе киң, дәресләре көчле, шәкертләре күп булган. Мәшһүрләре: мелла Сөбхан бине Габделкәрим (Мәрҗанинең бабасы), мелла Ибраһим бине Арслан бине Туйчы Кимеви һәм башкалар. («Мөстәфад әл-әхбар», 154 б.).

27. Мелла Кадыйр. Бу кеше унсигезенче гасыр урталарында Казан өлкәсе Кышкар авылында мөдәррислек иткән. Аның шәкертләреннән мелла Мортаза бине Габделгазиз бине Бикмөхәммәд исемлесе шул мәдрәсәдә һиҗри 1167, милади 1754 елда укып яткан чагында «Нигъмәтулла» исемле фарсы-төрки сүзлекне күчереп язып чыккан. Укуны төгәлләгәч, Казанга кайтып, икенче мәхәллә мәчетендә имам, мәдрәсәсендә мөдәррислек иткән. Үзе мелла Мортаза Бөгелмә өязе Каратай авылыннан чыгып, анасы Бостан бинте Ярмөхәммәд исемле хатын булган. Мелла Мортаза бине Габделгазиз үзенең остазы мелла Кадыйрга гаять зур ихтирам белдереп, аны «әфәндез заман вә мөдәррисел әван» дип атаган. Мортаза бине Габделгазизнең вафат елы 1211 һиҗри, 1797 милади. («Мөстәфад әл-әхбар», 62 б.).

28. Мелла Мортаза бине Габделгазиз бине Бикмөхәммәд Казанда икенче мәхәлләдә имам, мөдәррис булган хәлдә, җәмәгать эшләренә дә актив катнашып, Куйгани язмаларында очрап тора. Мәсәлән, ул Казанда һиҗри 1200, милади 1786 елда Ратуша исемле мәхәлләнең башлыгы. «Нижний шәһәре ягыннан килгән Намка авылының Котлымөхәммәд мирза бине Ягъкуб иде», дип язып калдырган. («Мөстәфад әл-әхбар», 334 б.).

29. Мелла Сәед бине Мөхәммәд әл-Болгари. Бу кеше نهاية الادراک исемендәге гарәп гыйбарәле фикъһ китабын күчереп язып чыккан һәм азаккы сәхифәсендә



وقع الفراغ من تسويد نهاية الادراک من سيد بن محمد البلغارى فى سنة 1176 بعون الله الملک المعين

дип белешмәсен теркәп калдырган. Милади белән 1763 елга туры килә. Бу китапның кульъязмасы 73 кәгазь 146 биттә урнашкан, хәзерге көндә Казан дәрелфөнүн кульъязмалар хизанәсендә саклана.

30. Мелла Гыйльман бине Үтәш. Бу кеше һиҗри 1155, милади 1742 елда Ташкичү авылында Габдессәлам бине Урай мәдрәсәсендә укып яткан чакларында гыйльме фикъһедән Габдулла бине Мәхмүд әл-Мәүсаллинең «Мохтәр» исемендә гарәбел гыйбарә бер китабын күчереп язып чыккан һәм язылу тарихын һәм урынын күрсәткән, китапның читендә калган буш урыннарында үзләре тарафыннан файдаланылган бик күп китапларның исемнәрен һәм кайбер үзенчәлекләрен теркәгән. («Мөстәфад әл-әхбар», 127 б.).

31. Мелла Гобәйдулла бине Мәүлед. Бу кеше Уфа-Оренбург якларында Әрәмә авылында мәдрәсә тотып, шәкертләр тәрбия кылган. Шул мәдрәсәдә 1793 елда аның янында укучы-шәкерте Суфиян бине ахунд Вәлид «Мәтне Исагуҗи» китабын күчереп язып чыккан. Бу кульъязма Уфада Крупская исемендәге китапханәдә саклана.

32. Мөфти Ибраһим бине Мөхәммәд Түләк – Бәчә ахунд – Кондурави – Каршин шәрифи. Вафаты 1750 еллар тирәсендә. Бу кеше Котлымөхәммәд Мирза бине Тәвәккел бине Мамашның хасс имамы һәм ахунды – мөфтие булып торган, гыйлем даирәсе киң, әхвал галәменнән хәбәрдар булып, тарих гыйлеменнән зур өлешле булган «Рәүзатес сафа» исемле фарсел гыйбарә тарих китабын үз кулы белән язып, һиҗри 1147, милади 1735 елда үзенең нәбирәләреннән берсенә һиббә кылып, кайчан икәнен күрсәтеп кул куйган, үзенә хас олуг түгәрәк мөһерен баскан. Вафаты Алабуга өязе Тирсә авылында. Кунакка килгән җирендә Котлымөхәммәд хан Мамашев-Тәфкилев йортында вафат булган, кабере өстендә язулы ташны туганы Мөхәммәдрәхим куйдырган (мелла Газнәфәр хәбәре). («Мөстәфад әл-әхбар», 311 б.).

33. Шуның бәрадәры – мелла Мөхәммәдрәхим бине Мөхәммәд Түләк. Бу кеше Тирсәгә Котлымөхәммәд мирза Тәфкилев йортына килеп имамлык иткән һәм приказщик булгалаган.

34. Котлымөхәммәд Мирза бине Тәвәккел бине Мәмаш бине Дәүләтмөхәммәд бине Уразмөхәммәд бине Уннан. Туган елы 1670 милади, вафаты 1765 елда. 95 яшендә. Кабере Тирсә авылында, язулы кабер ташлары 1850 елларда исән булган. Ислам гыйлемнәрен Котлымөхәммәд Мирза файда кемнән алгандыр? Билгесез. Ләкин гарәп, фарсы, төрки телләре, ислам фикъһе гыйлемнәрен яхшы белгән, шәркый галимнәренең бик күп әсәрләре аның китапханәсендә булган һәм укылганнар. Котлымөхәммәд мирза рус теле һәм гаскәри хезмәт низамнарын да бик яхшы үзләштереп, үзе яшь чакта ук рус гаскәре хезмәтендә актив катнашкан. 1725 елларда Оренбург кальгасына нигез салуда хезмәт иткән. Һиҗри 1147, милади 1734 елда рус гаскәре командасында килеп, Оренбург шәһәрен салганнар. Шул хезмәтләре өчен генерал-майор дәрәҗәсен алган. Бик күп җир, сулар, авыллар барлык крестьяннары белән аңар кол итеп бүләк итеп бирелгән. Мәсәлән, Алабуга өязе Тирсә, Түбә, Чишмә, Шаршады, Балтач, Начар, Биектау, Мәүдүби, бакыр заводы; Бөгелмә ягында Килем, Акбаш авыллары кебек, ләкин аның хезмәтләре рус әдәбиятында бик үк яктыртылмаган. («Мөстәфад әл-әхбар», 310 б.).

35. Йосыф мирза бине Котлымөхәммәд бине Тәвәккел бине Мәмаш бине Дәүләтмөхәммәд бине Әгъзармөхәммәд хан Чингизи. Вафаты 1773-4 елда, кабере Акбаш авылында (Бәйрәкә дип тә язалар). Бу кеше дә рус гаскәрендә олуг җаваплы эштә булуы белән бергә, бик күп авылларда бик күп крестьян халкын изү, алар көче белән байлык туплау артыннан куып, халык өстендәге җәфалары чикне-хисапны белмәгән. Шунлыктан Пугачев кузгалышында катнашучылар тарафыннан бу мирза Акбаш авылында үтерелгән. Бәйрәкә авылының Мортаза исемле кешенең шәфкате белән Бәйрәкә авылына китерелеп күмелгән. Газнәфәр хәзрәт бине Фәдаил хәбәре.

36. Йосыф мирза бине Котлымөхәммәд мирзаның хатыны Зөһрәбикә. Вафаты 1806 елда. Кабере Тирсә авылында, язулы таш булган. Бу кеше Шаһин Гәрәй мирза бине Йосыфның анасы һәм Сәлимгәрәй мөфти бине Шаһингәрәйнең әбисе була.



37. Сөендек бине Исергәп. Бу кешенең кайда, нинди гыйльми эшләр белән шөгыльләнүе өйрәнелмәгән. Шулай да гыйлеме тирән, хәттатлыкта оста булганы мәгълүм. Бу кеше һиҗри 1094, милади 1780 елларда гарәп телендә رموز حقايق فى شرح كنز الدقايق исемле фикъһ китабын күчереп язып чыккан. Китап зур форматта. Ахырда бу китап Ак Идел буе Алыш волосте Сарай авылында Әхмәтзәки мелла Гыйлаҗ улының милкендә булган. Әхмәтзәки 1875 елда бу китапны Саббахеддин Габдесабур углына саткан. Хәзерге көндә бу китап лаеклы урында: Уфада Крупская исемендәге китапханәдә саклана.

38. Мелла Сәфәр бине мелла Гомәр. Бу кеше һиҗри 1194, милади 1780 елда Алыш авылында «Ләгате Нигъмәтулла» исемле фарсы-төрки сүзлекне күчереп язып чыккан. Бу китап Казан дәрелфөнүн кульъязмалар хәзинәсендә саклана.

39. Мелла Зәйнелгабидин бине Габделкәрим. XVII йөзнең икенче яртысында, XVIII йөзнең беренче яртысында Ыспас өязе Иске Рәҗәб авылында имамлык итү белән бергә, җәмәгать эшләре белән дә шөгыльләнгән. Үзе гарәп, төрки һәм рус телләрен кагыйдәләре белән яхшы үзләштергән булган. Рус телендә булган документларны татарчага тәрҗемә кылу белән шөгыльләнгән. Мәсәлән, җиде мең ике йөз өченче ел (1695 ел була) Петр I тарафыннан крестьяннарның күпме җир биләргә хаклары барлыгы хакында чыгарган указын, татарчага тәрҗемә кылып язып, халыкка аңлаткан. («Мөстәфад әл-әхбар», 8 б.).

40. Бохармәт Хәлил углы. 1718 елда Кол Сөләйман Бакырганның кеше гомерендә ун ел саен килә торган үзгәрешләр хакындагы шигырен күчереп язган. Аннан башка һәм байтак китаплар күчереп язган.

41. Мелла Бәшир бине Уразай Биги. Бу кеше Бәрәскә авылында беренче имам һәм мөдәррис булган. Аның мәдрәсәсендә һиҗри 1180, милади 1766 елда мелла Ишбай бине Ишмирза исемле шәкерт «Бостанел фәкыйһ» исемле китапны күчереп язып чыккан. («Мөстәфад әл-әхбар», 153 б.).

**42.** Мелла Габдеррәшид бине Мөхәммәд Казан өлкәсендә Бай уланнар авылында мөдәррислек иткән. Шәкертләреннән Сәйфелмөлек бине Мозаффар (Шиһабеддин Мәрҗанинең бабасы) шул мәдрәсәдә 1171, милади 1758 елда Сәгъдинең «Гөлбостан» исемле нәфис әсәрен күчереп язып чыккан. Сәйфелмөлек бине Мозаффар Иске Чокалы авылында мөдәррислек итеп, йөз яшькә җитеп, 1240/ 1825 елда вафат булган.

**43.** Мелла Мозаффар бине Мортаза бине Гали бине Йосыф 1210/1796 елда Бизнә авылында имам һәм мөдәррис булган.

**44.** Аның атасы мелла Мортаза бине Мөхәммәд бине Йосыф. Бу кеше атаклы галим мөфти һәм хаҗи Мортаза бине Котлыгуш Суфый Симетинең олуг шәкерте булган. Аның хозурында укып яткан чакта һиҗри 1102, милади 1691 елда гарәп нәхүе дәреслеге – مختصر الزنجانى исемле китапны күчереп язып, азагында остазы һәм үзе хакында кыскача белешмә күрсәтеп калдырган. Бу кеше бөтен гомерен Бизнә авылында мөдәррислек итеп, монда вафат булган. Елы ачык билгеле түгел. 1750 еллар тирәсендә булуы мөмкин, чөнки остазы Мортаза хаҗи Симети 1720 еллардан соң вафат булган. («Мөстәфад әл-әхбар», II, 148 б.).

**45.** Мелла Ибраһим бине Йосыф бине Ишбулат бине Ишморад Казани әл-Болгари. Бу кеше Казанның беренче мәхәлләсендә имам һәм мөдәррис булган. Шәкертләреннән Хөсәен бине Бикмәмәт дигәне һиҗри 1136, милади 1723 елда аның катында جامع الرموز исемле фикъһ китабын күчереп язып, үзе, остазы һәм тарихы, елы хакында белешмәсен теркәп калдырган.

**46.** Аның улы Әбүбәкер бине Ибраһим бине Ишбулат бине Ишморад Казанлы. Вафаты милади 1794 елда. Бу кеше атасы урынында имам һәм мөдәррис һәм җәмәгать хадиме, хәтта Оренбургта Мәхкәмәи шәргыя ачылгач, Мөхәммәдҗан мөфти янында өч нәүбәт казый булып торган. Шәкертләре: 1) Гобәйдулла бине Мортаза, 2) Бикбау бине Мортаза, 3) Габделкәрим бине Мөхәммәдрәхим бине Юныс һәм алардан башка күп кешеләр («Мөстәфад әл-әхбар»).

**47.** Габделваһаб бине Мостафа. Дәвек авылында мелла Бикчәнтәй мәдрәсәсендә язган. Кулъязмасы миндә бар.



**48.** Нигъмәтулла бине Бәшир. Бикчәнтәй бине Ибраһим исемле мөдәрриснең Бәрәскә авылындагы мәдрәсәсендә язган. Бу мөдәррис 1775 еллардан башлап казый булып торган. 1800 елда вафат булган. Шагыйрь Нигъмәтулла хакында мәкалә «Казан утлары»нда басылды. Бу кеше Буа шәһәре купецларында булып, 1825 елларда Бизнә авылында имам булып торган.

**49.** Мелла Габдеррәхим бине Яркәй. «Олуг агага үтенеч» шигыре. 1786 елда Ярмөхәммәд авылында Габделгазиз бине Хөсәен мәдрәсәсендә язган. Шагыйрьнең атасы мелла Яркәй Корыч авылында имам булып хезмәт иткән.

**50.** Сәгъдеддин бине Габделмәҗит бине Габделмәннан бине Габделкәрим бине Арслан бине Урман. «Илаһи бәет». «Казан утлары»нда басылды.

**51.** Казан имамы һәм мәшһүр галим Хәмид бине Мортаза бине Нурмөхәммәд (төп чыгышы: Казан ягы Әлдермеш авылы). Вафаты 1223/1808 елдан соң. Яшьлектә Кариле авылында Габдессәлам бине Хәсән исемле мөдәрристән һәм башкалардан укыган. Бервакыт үзе дә Кариле мәдрәсәсендә дәрес иткән. Шул вакытларда аннан дәрес алып-укып яткан шәкерте Мөхәммәдгали бине Зәйнелгабидин исемле кеше гарәп теле нәхүеннән мелла Җами китабын күчереп язган. Шуннан соң булса кирәк, Хәмид бине Мортаза Казанга күчеп, анда беренче буларак мәдрәсә ачып дәрес итә башлаган. Имамлык иткән. Башта указсыз буларак дәрес биргән, аннары, Мәхкәмәи шәргыя ачылгач, 1210/1794 елда имтихан биреп указ алган. 1223/1808 елларда әле исән булган («Асар», II, 86 б.).

---

### Әҗәл авылында мелла булып торган галимнәр

1) 1625 елларда – Җәмад мелла.
2) Габдеррәшид мелла. 90 – 100 яшендә үлгән.
3) Габдеррәзак.
4) Ишим мелла. 95 яшендә үлгән.
5) Зур галим Бикмәт мелла. 80 яшендә үлгән. Аннан соң Әҗәге авылында олуг галим булган. Мамадыш авылына ияргән бер мәхәллә булып кына калган.

### Мамадыш авылында мелла булып торганнар

Бикмәмәт мелланың углы Таҗеддин мөдәррис. Бу кеше Каюм Насыйриның замандашы һәм дусты булып, җәй көннәрендә тарихи мәгълүматлар җыеп йөргәннәр, бигрәк тә 1873 елда. Ярым билгесез галимнәреннән Габдеррәзак һәм Атнахуҗа Бәйрәк углы дигән кешеләр.

1773 елда Буклавыч авылының мирзасы һәм аның углы Мостай үз авылларындагы гарип карт, мелла Габбас өстеннән мыскыл итеп, төрле золымлыклар кылып, ел саен көнгә 50 тиен хисап ясак түләтеп рәнҗеткәннәр. Бу хакта рәсми мәгълүматлар булса кирәк.

Канай авыл меллалары: 1) Хаҗи, 2) Баймәт бине Хаҗи, 3) Мөхәммәдкол бине Баймәт, 4) Дәмин бине Мөхәммәдкол, 5) мелла Әмин бине Дәмин, 6) Мөхәммәдшаһ бине Әмим (Каюм Насыйринең кардәше), 7) Хәсәнҗан бине Мөхәммәдшаһ.

### Алабуга өязе Көчек авылы мәхәлләләре

1нче мәхәлләдә имам Фәттах хәзрәт Галиев. Соңыннан аның углы Габдеррәуф.

2нче мәхәлләдә: Нурелгаян Фәттах углы, мөәзин Мөхәммәд Зәки.

3нче мәхәлләдә: Хөснеддин мелла, Гыйлмелгаян Фәттах хәзрәт углы, мөәзин; ахунд Гатаулла бине Яһүдә (Яһудин) – аның соңгы хатыны минем әнкәемнең туганнан туган сеңлесе Мөнирә бинте мелла Нәҗмеддин Тукаев. Анасы Маһисорур бинте мелла Габдессәттар.

Искәрмә: Фәттах хәзрәтнең бер кызы Садыйк мөәзингә, 90 яшьлек картка бирелгән булган (Хөснеҗиһан Хәмидуллина хәбәрләре).

### Шиһабеддин әл-Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар» китабының һәмишендә Зәйнәп Максудова тарафыннан язылган сүзләр

XVIII йөздә Иске Бистәнең беренче (агач мәсҗед) мәхәлләсендә имам вә мөдәррис хезмәтен үтәүче Ибраһим б. Йосыф б. Ишболат Казани дигән кеше булган. Аның мәдрәсәсендә һиҗри 1136 миләди 1724 елда Хөсәен б. Бикмәмет дигән шәкерт «Җәмиг әрромүз» китабын күчереп язып, тарихын бүкеткән. Ибраһим б. Йосыфның вафаты 1770 еллар тирәсендә булыр. Аның соңында улы Әбү Бәкер б. Ибраһим б. Йосыф б. Ишболат имам мөдәррислек иткән.





*Рис. 160.* Комментарии З. Максудовой к книге ал-Марджани «Мустафад ал-ахбар»
НМ РТ 18369-206

XVIII йөздә Казанда мелла Габдерәшит б. Йосыф б. Кадер б. Бикмәмет б. Тәтеш әл-Каргалый имам вә мөдәррис булган. Вафаты 1188 һиҗри 1774 миләди.

XVIII йөздә Казанда беренче мәсҗеддә имам-хатыйб, мөдәррис боларак Әбү Бәкер б. Ибраһим б. Йосыф хезмәт иткән. Атасыннан

башлангыч белемнәрне алгач Янгыл иленә барып мелла Мәсгүд б. Мөхәммәд исемле галимгә килеп гыйлем алган. Казанда 1774 – 1794 елларда дәрес биргән. Оренбургта Мәхкәмәи шәргыяда казыйлык иткән. Вафаты 1794 елда.

XVIII-XIX йөздә Казанда беренче мәсҗеддә имам вә мөдәррис булып Ибраһим б. Хуҗаш (эфенде) хезмәт иткән. Бу кеше башта үзенең атасыннан һәм якташ галимнәрдән башлангыч белемнәр алгач, Дагстанга барып Гали эфенде Ширванидан дәрес алган. Һиҗри 1195 миләди 1781 елда язган китабы Мәрҗани кулында сакланган. Һиҗри 1196 миләди 1783 елда Русияга кайтып Утар авылында, аннары Кишет авылында имам булган. Миләди 1794–1825 елларда Казанда имам-хатыйб, мөдәррис һәм ахундлык иткән. Вафат 1825 (һиҗри 1241) елда.

XVII-XVIII йөзләрдә Вятка губернасы Янгыл иле дигән авылда мелла Мәсгүд б. Мөхәммәд исемле мөдәррис мәдрәсә тотып шәкертләр тәрбия кылган. Аның шәкертләреннән берсе – Казанда беренче мәсҗеднең беренче имамы һәм Мәхкәмәи шәргыянең беренче казыйсы мелла Әбү Бәкер б. Ибраһим б. Йосыф б. Ишболат б. Ишморат әл-Казани. Казанның беренче мәсҗеден салдыруда башлап йөргән. Вафаты 1794 елда. Аның бик күп язмалары Ш. Мәрҗани кулында сакланган.

Минзәлә өязе Байлар авылында дамелла Габделгафур б. Сайфулла дигән мөдәррис XVIII-XIX йөздә мәдрәсә тотып шәкертләр тәрбия кылган. Ул мәдрәсәдә 1827 елда Гайнулла б. Файзулла дигән шәкерт (соңыннан Уразай авылында мөәззин иде) кулы белән язылган «Мөхтәсәрел-викая» китабы үземдә саклана (№ 65 кулъязма).

Казанда XIX йөздә Габделвали б. Габделгаффар әл-Чокали дигән бу дамелла (бохари мөдәррис) мәдрәсә тотып шәкертләр тәрбия кылган. Аның мәдрәсәсендә 1886 елда укыган чагында Җәлалетдин б. мелла Сагъдетдин б. мелла Вәли Мөхәммәд дигән кеше «Зөбдәтел-әсрар» исемле китапны язып чыккан (каталог, № 58 кулъязма). Габделвәли б. Габделгәффар 1821 елда туган.

Әгерҗе авылында (Сарапул өязе) XVIII йөздә Хөсәен б. Мәскәү атлы мөдәррис мәдрәсә тотып шәкертләр тәрбия кылган. Аның мәдрәсәсендә укыган чакта 1796 елда Шәмсетдин б. мелла Ишмөхәммәд дигән кеше (соңында Сарапул өязе Нарат авылында мөәззин булып хезмәт иткән) гарәп телендә «Гокүд мәнзүмә» исемле китапны кулдан язып күчереп чыккан (каталог № 52 кулъязма).



Буа шәһәрендә XIX йөздә Габделвәхит б. Габдулла дигән мөдәррис мәдрәсә тоткан. Аның мәдрәсәсендә 1846 елда укучы Хөснетдин б. Габдулла Янтугани дигән шәкерт «Шәрх гакаид» китабын күчереп язып чыккан (каталог кулъязма № 54).

Асан суы буенда Токай авылында XVIII-XIX йөзләрдә Габделхалик б. Китап атлы мөдәррис мәдрәсә тоткан. Аның мәдрәсәсендә 1818 елда укыган чагында Гайса б. Тимер дигән шәкерт (соңыннан Сарапул өязе Нарат авылында имамлык иткән) «Китап бостанел-гарифин» исемендәге гарәпчә китапны күчереп язып чыккан (каталог кулъязма № 56).

Болгар иле Казаклар авылында мелла Ибраһим б. Габдулла исемле мөдәррис XVIII йөздә мәдрәсә тоткан. Аның мәдрәсәсендә укыгында 1768 елда Баттал б. Җортый атлы шәкерт бик матур каләм белән «Мөхтәсарел-викая» китабын күчереп язып чыккан (каталог кулъязма № 19).

Сарапул өязе Бубый авылында XVIII–XIX йөздә Габделкәрим б. Хәлил атлы мөдәррис мәдрәсә тоткан. Аның мәдрәсәсендә укыган чагында 1816 елда Габдесәттар б. Сөендек (шулук өяздә Нарат авылында имам вә мөгаллим булган) атлы шәкерт «Хашия әл-Аккирмари» исемле китапны язып чыккан (каталог кулъязма № 15).

Кече Тархан авылында Шәмсетдин хәзрәт имамлык иткән. Аның угылларыннан берсе Галәветдин. Шул авылда имам булып торды. Зәйнәп атлы кызы миндә укыды. Шәмсетдин хәзрәтнең икенче улы Зияэтдин Әхмәд элек авылда, аннары Буа шәһәрендә, аннан соң Истамбулда һәм Хиҗазда укып, Мәдинәдә мөдәррислек һәм мөҗәвирлек итте. Шигырьләрне язды. Бу китапта («Бәян әл-хак») һәм аның кайбер шигырьләре басылган.

Болгар вилаяте Уфа юлы Ташлыяр авылында XVIII-XIX йөзләрдә мөдәррис Әбү Бәкер Шәмгун углы мәдрәсә тоткан. Аның мәдрәсәсендә укыган чагында, 1812 елда, Зәйнетдин б. Мөнасиб ән-Нуркави дигән шәкерт бик гүзәл каләм белән «Мөхтәсәрел-викая» китабын язып чыккан (каталог, кулъязма № 7).

Арча ягы Карил (Карый иле) авылында XVIII йөздә мөдәррис мелла Габид б. Габделгазиз б. Гайса әл-Көнәри мәдрәсә тоткан.

Аның мәдрәсәсендә укыган чагында, 1787 елларда, Сөендек б. Габделгазиз б. Гайса әл-Көнәри дигән укычы «Шәрх фараиз сиражия» исемле китапны бик матур каләм белән күчереп, язып чыккан (каталог, кулъязма № 16).

XVIII йөздә мелла Рәфыйкъ б. Уразай дигән мөдәррис мәдрәсә тоткан. Шул мәдрәсәдә укыган чагында, 1784 елда, Хәмид б. Ишимбай дигән шәкерт үзенең дусты Дәүләтшаһ б. Илбәк өчен шагыйрь Мәҗлисинең «Кыссаи Сәйфел-Мөлек» дигән төрки китабын күчереп язып чыккан. Каләме бик зәгыйф.

XIX йөздә Салавыч авылында Низаметдин б. Сәлимҗан исемле мөдәррис мәдрәсә тоткан. 1877 елда шул мәдрәсәдә укыган чагында Нурмөхәммәд б. Сәйфетдин исемле шәкерт берничә китапны эченә алган мәҗмүганы күчереп язып чыккан (каталог, кулъязмалар, № 82–89).

Минзәлә өязе Дәүк авылында XVIII йөздә мелла Бикчантай б. Юлдаш исемле мөдәррис мәдрәсә тоткан. Анда укыган чагында Габделвәһаб Мостафа углы дигән шәкерте бер мәҗмүганы күчереп чыккан (каталог, кулъязмалар № 90-93а).

Алабуга өязе Тирсә авылында XVIII йөздә Мәннанкол б. Иманкол исемле мөдәррис дәрес иткән. Аның мәдрәсәсендә укыган чагында, 1760–1790 елларда, Бәшир б. Габдулла дигән укучы шагыйрь байтак рисаләләрне эченә алган бер мәҗмүганы күчереп чыккан (каталог, кулъязмалар № 128–135).

Урбар авылында XVIII йөздә мелла Ибраһим б. Габдулла Нократый дигән мөдәррис дәрес иткән. Аның Габдерәхим б. Габдерәшид б. Симуш әл-Болгари исемле шәкерте шул мәдрәсәдә укыган чагында, 1779 елда, «Шәрх фәраиз» китабын гаять матур каләм һәм таблицалары белән күчереп язып чыккан (каталог, кулъязма № 157). Мелла Ибраһим 1768 елларда Казаклар авылында дәрес иткән.

Казан вилаяте Хәерби авылында XVIII йөздә Габдәш б. Габдесәлам дигән мөдәррис мәдрәсә тоткан. Аның мәдрәсәсендә укыганда, 1790 елда, Максуд б. Корбангали дигән укучы бик матур каләм белән «Мелла Җами» китабын күчереп язып чыккан (каталог, кулъязма № 160).

# Материалы к биографии Зайнап Максудовой

## Олуг шәҗәрә

Габдулла бине Габдессәлам бине Хәлил бине Йосыф бине Ишмән бине Тукнаргали бине Көчек бине Кабач бине Кодәш бине Сөләйман әл-Кирмани.

Кодәш һәм Сөләйманның кайда, кайчан яшәүләре билгесез.

1) Тәбәч бине Кодәш Бөрбаш авылында йорт салып, тимерчелек белән яшәгәнгә, бу урын Йорт елга дип мәшһүр.
2) Көчек бине Тәбәч Бөрбаш авылында ½ чакрым югарырак менеп йорт корган һәм шунда гомер иткән: шулай авыл барлыкка килгән.
3) Туктаргали бине Көчек сәүдә эшенә бирелеп, Каргалы-Оренбург халыклары арасында йөргән. Алардан мал китереп, Русиядән хәзер товарлар илткән. Гасыр ахырында кайтып һ. 1080 – милади 1670 елда вафат булган. Кабере – Бөрбашлы авылында. Язулы ташы озак сакланган.
4) Ишмән бине Туктаргали. Бу кеше Бөрбаш авылыннан күчеп, Мәчкәрә авылы(н) нигезләгән, шунлыктан бу авылны Ишмән иле дип тә атаганнар. XVII гасырда элгәре бер ар авылы булган икән. («Мөстәфад әл-әхбар», җилд 2, 156 б.).

Кайбер хәбәрләргә караганда, Ишмәннең: Гаид, Габдессәлам, Габделмәннаф, Сәгыйд, Бәшир, Нәзир, Үтәмеш исемнәрендә җиде углы булган, имеш

Үтәмешнең Габдессәлам исемле углыннан – Мөхәммәдрәхим, аннан Габдулла исемле угыл дөньяга килгән, имеш.

XIX гасыр Габдулла бине Габдессәлам бине Үтәмеш Мәчкәрә авылында мөдәррис Габделмәҗид бине Үтәгән мәдрәсәсендә һ. 1173, м. 1759 елда «Гыймадел ислам» исемле китапны үз кулы белән күчереп язган. Соңыннан зур байлык иясе булып, күп авылларга мәсҗед һәм мәдрәсәләр салдырган. Коллыкта булган бик күп татар крестьяннарын хуҗаларыннан сатып алып, азат иткән. Үзе йөз

яшькә җитеп, һ. 1248, м. 1832 елда вафат булган. Хатыны – Әбүнасыйр Курсавиның бертуган апасы.

Габдулла бине Габдессәлам, туган 1732 елда.

Даниил Исхак учитель из Учительской школы

Зәкиҗан Шәңгәрәев.

Әсәрләре: 1) «Төрмә хатирәләре»; 2) «Диңгез асты».

Хатыны – Рөкыя Бәдрелгаян кызы (авыл мулласы). Шунда атасыннан укып, төрки, гарәп, фарсы телләрен өйрәнгән. Шигырьгә сәләте көчле иде. Бервакыт сөйләде вә укыды. Вафаты 87/1967 елда. Шигъри әсәрләре күп калган.






Дәү әнкәмнең атасы мелла Габдессәттар бине мелла Сөендек Сарапул өязе Нарат авылында 1792 елда туган, вафаты 1880 елларда.

Аның балалары:

1) Хөсниҗамал – Уразай авылы Габделҗәмил Максудов никахында булып, 1883 елда вафат булган. Аның 9 баласы булып: (Зәйнәп, Гайнеҗамал, Габделгазиз, Мөхәммәдгариф, Гыйльмекәмал 1, Гыйльмекәмал 2, Габделкаюм, Өммегөлсем, Габдеррахман). Үзеннән соң 7 баласы калган.
2) Сахибҗамал 1832 елда туган. Нарат авылында Нигъмәтулла Сәйфулла углы никахында булып, Гобәйдулла, Фаризә, Зарифә, Шәрифә, Фәрхиназ, Ибраһим – 6 баласы булган. Вафаты 1900 елларда.
3) Мөхәммәдшакир 1828 елда туган. Нарат авылында мелла булып хезмәт иткән. 1872 елда кырык дүрт яшендә сачында аклык беленә башлаганын язган. Аның балалары Гыйрфанеддин, Зияддин, мелла Мөхәммәд, Хөснеддин, Вафирә, Мәгъфүрә. Гыйрфанеддин һәм мелла Мөхәммәд игенче булып, Зияддин имам булып, Нарат авылында яшәгәннәр.

Хөснеддин кече яшендә вафат булган. Вафирә Уразай авылында Җиһаншаһ Әхмәди углы никахында торып, баласыз вафат булды. Мәгъфүрә Сарапулда Габделхәким тәшрих ханәдә эшләүче… авылы берәүнең никахында иде. Мелла Зияддиннең [балалары:] Таҗеддин, Габдулла, Нәкыя (1 нче хатыннан), Хәнифә, Лотфеҗиһан (икенче хатыны Фатыйма бинт мелла Җәббардан). Зияддин мелла абзыйның беренче хатыны – Рәсүл бабайның кызы. Сибгатулла, Хикмәтулла, Гөлҗиһан белән бертуган.

4) Маһисорур башта Нарат авылы имамы Нәҗмеддин Хафиз углы Тукаев никахында булып, аннан Мөнирә һәм Мәрьям исемендә ике кыз тапты. Аннан соң Мазарасты авылы кешесе никахында булып, Мәгъсүмә кызы белән тол калды. Аннан соң Гали Пүчинкәсе авылының Тимершаһ исемле меллага никахланып, аннан Зәки, Габдулла исемле угылларны дөньяга китерде.
5) Хөснеҗан исемле кызы Нарат авылында Шәйхелислам авылы кешесенең никахында булды.
6) Әткәмнең беренче иптәше дәү әнкәбез Хөснижамал бинте Габдессәттар милади 1883 елда вафат булган.



7) Габделлатыйф бине Габдессәттар Нарат авылында мөәзин булган. Аның хатыны Шәмсебана Уразай авылының Габделмәннан бине Максудның кызы булган.

Тутабыз Зәйнәп Габделҗәмил кызы 1863 елда (тәхминән) туган, вафаты 1896 елда.

Тутабыз Гайниҗамал Габделҗәмил кызы 1865 елда (чама белән) туган.

Иң зур абыем Габделгазиз Габделҗәмил углы 1867 елда туган, хәмәлнең 28 нче көнендә.

Аннан кече абыем Мөхәммәдгариф 1нче, 1869 елның 12 декабрендә туган.

Аннан кече абыем Гыйльмекәмал бине Габделҗәмил 1872 елның 9 декабрендә Туган. 1961 елда Шаршады авылында вафат булды.

Аннан кече абыем Габделхәлим Габделҗәмил углы 1876 елның 24 декабрендә туган.

Аннан кече тутам Өммегөлсем 1874 елда туган, вафаты 1956 елның 15 июлендә.

Аннан кече абыем Габдеррахман Габделҗәмил углы 1881 елның 15 сентябрендә туган.

Аннан кече тутам Газизә Габделҗәмил кызы 1886 елда туган, вафаты 1925 елда.

Аннан кече абыем Мөхәммәдшакир Габделҗәмил углы 1888 елның 1 октябрендә туган. Вафат 28.5.1956.

Аннан кече абыем Мөхәммәдзакир Габделҗәмил углы 1891 елда туган, вафаты 1922 елда.

Аннан кече тутам Мәгъсүмә Габделҗәмил кызы 1894 елның 15 июнендә туган.

Миннән кече энем Мөхәммәдгариф 1900 елда туган, 1942 елның мартында үлде.

Аннан кече сеңлем Наҗия 1903 елда туган, вафаты 1949 елның 8 маенда.

Аннан соңгы иң кече сеңлем Сәнимә 1906 елда туган, вафаты 1908 елда.

Әткәмнең атасы Габделмәннан бабай 1776 елда туган, 1861 елда 85 яшендә вафат булган.

Әткәем Габделҗәмил бине Габделмәннан бине Максуд бине

Ибраһим бине Миңлебай бине Түкәч 1832 елда Алабуга өязе, элгәреге Вятка губернасы Салагыш волосте Уразай авылында туып, шул ук авылда 1924 елда вафат булды. Әткәем Габделҗәмил Габделмәннан углы 1871 елда, февральнең 15 нче көнендә Шаршады авылына күчеп барган. Милади 1887 елда әткәемнең бертуган агасы Габделлатыйф Габделмәннан углы исән булган. Бабабыз милади 1861 елның 22 декабрендә вафат булган. Бу елда әле Габдессәттар бине Сөендек исән булган.

Үзем, Зәйнәп Габделҗәмил кызы Максудова, 1897 елның 15 мартында Вятка губернасы Алабуга өязе Салагыш волосте Уразай авылында мулла-мөгаллим гаиләсендә дөньяга килгәнмен.

Әнкәем Шәрифә Нигъмәтулла кызы Нарат авылында милади 1867 елда туган, вафаты – Казанда милади 1939 елның 8 августында.

**[Гаисә бабай балалары]**[1]

1. Габдессәттар б. Сөендек Сарапул өязе Нарат авылында имам-учитель булып, аның угыллары Мөхәммәдшакир шулук авылыда имам, Габделлатыйф исемле углы мөәззин һәм могаллим булган.
2. Мөхәммәдшакир б. Габдессәттарның углы Зияддин шулук авылда имам иде. Аның угылларыннан Таҗеддин абзый Беренче империалистик сугышта һәлак булды. Габдулла исемле углы революциядан соң Эстерлетамак һәм Уфа шәһәрләрендә китап сатуы белән шөгелләнеп, Уфада үлде. Фамилиясе Сөендеков иде.
3. Габдессәттар мелла бабайның Хөснеҗәмал исемле кызы минем әткәм Габделҗәмил Габделмәннан углы никахында булып 48 яшендә вафат булган. Кабере Уразай авылында. Габдессәттар бабайның Сахибҗәмал атлы кызы Нарат авылының Нигъмәтулла б. Сәйфулла б. Сәедкол б. Айткол б. Кадрәч б. Зайтлы дигән балчы бер крестьян никахында булып, аның Шәрифә исемле кызы минем әткәм Габделҗәмил Габделмәннан углына тол калган 50 яшьлек җизнисендә җиде бала өстенә 16 яшьлек кыз хәлендә никахландырылган. Минем әнкәм һәм башлап миңа ак өстенә караны катышып укырга-язарга өйрәтте. Остазым шушы Шәрифә абыстай иде. 1939 ел 10 августта трамвайга тапталып һәлак булды. Кабере Казанда. Сугыш вакытында бу каберне югалтып, шушы көнгә чаклы җаным ачынып яшим.

Әниемнең анасы ягыннан бабалары һәм аларның туганнары, балалары барысы да сәвадле, укышылары тирән булганнар. Шулай ук кулларында һөнерләре дә булган. Алар тегүче, игенче, укытучы, токучы, язучы һәм шундый күп һөнәрләрнең белгече булганнар.

4. Габдессәттар бабайның атасы Сөендек б. Габделгазиз Нарат авылында имам булган. Үзе Урнашбаш һәм Карил исемле авылларда 1760–75 еллар тирәсендә үзенең бер туган агасы Габид хәзрәттә дәрес алган. Гыйлеме бик яхшы, каләме гүзәл булган. Үз кулы белән язган (гарәп телендә) төрле фәннәрдән дәреслек булып хезмәт иткән китаплары әле үземдә саклана. Сөендек мелла бабайның Габдессәттар атлы углы Нарат авылында Габденнәфыйкъ атлы углы Кадыбаш авылында имам һәм мөгаллим булганнар. Сөендек бабайның Габделхалик, Габделкәрим, Габделвәһаб, Габдулла атлы угыллары укымышлы булсалар да, үз авылларында иген эше белән көн кичергәннәр. Аларга якын тирәдә меллалык урыны табылмаган. Еракка җибәрергә әби риза булмаган. Сөендек бабайның Рәйханә атлы кызы Мәнзәлә өязе Савис авылында мелла Габдессалих мелла Гөбәйдулла [углы] атлы кешегә никахландырылган. 1839 нче елда. Аның язган мөнәҗәтләре, сагышу җырлары үземдә саклана. Рәйханә абыстай 28 яшендә ире мелла Габдессалих 52 яшендә булган. Димәк, Рәйханә абыстай 1811 нче елда туган.

Сөендек мелла бабайның Мәхбүбә исемле кызы Оренбург губернасы Бөре өязе Карабаш авылында игенче Габделкаюм Исламгол угылына никахландырылган 1835 елда.

Сөендек мелла бабайның Гафия исемле хатыны 1834 елда вафат булган, 67 яшендә. Кабере Нарат авылында. Туган елы 1767 елга туры килә.

Сөендек мелла бабай үзе 1830 еллар тирәсендә вафат булган булуы ихтимал. Туган елы 1755–1760 еллар тирәсендә булыр.

5. Габденнәфыйкъ мелла бабай Казыйбаш авылында имам һәм мөгаллим булып торган. Аның балаларыннан Мөхәммәдшакир дигәне Әгәрҗедә, аннары Какшан заводында ахунд булып хезмәт итте. Үзе байтак китаплар язды. 1890 елларда яңа осул

белән әлифба төзеп бастырды. 1897 елларда «Васыятьнамә» исемле китабын, аннары «Әхлак рисаләсе» исемле өч кисәктән гыйбарәт китапларын һәм башкаларны бастырды. Әхмәд Закир атлы углы Казыйбаш авылында мөәззин иде. Габденнәфыйкъ-нең Хөснежиһан атлы кызы Әгәрҗенең миллионер сәүдәгәре Ибраһим Тимкин никахында иде. Шунда вафат булды. Шакир ахундның балалары калмады.

6. Сөендек мелла бабайның атасы Габделгазиз (вафаты 1779 еллар тирәсендә) Кушлавыч авылында (Казан арты) имам һәм мөдәррис булган. Аның угылларыннан Фәез б. Габделгазиз башта атасыннан укып, аннары Бохарада, аннан соң Кабулда (Афганистан), аннары Һиндустанда укып, 1802 елда кайткач Кышкарда мөдәррислек иткән. Габденнасыйр Курсавиләр белән замандаш булган. Аның вафаты 1835 елда (кинәт үлгән). «Мөстәфад әл-әхбар», II. Аның Гобәйдулла исемле углы Семипалат шәһәрендә ахунд иде. Аның Габдулла исемле углы революциягә хәтле Семей шәһәрендә имам булып торды. Гатаулла исемле Киме авылында имам булган, Лөтфулла дигән Иске Әҗем авылында мелла булган.

Габделгазизнең Габид исемле углы Урнашбаш авылында, Карйил авылында имам һәм мөдәррислек итте. Аның хакында Мәрҗанинең «Мөстәфад»ында һәм Хөсәен Әмирхановның «Тәварихе Болгария» китапларында күп кенә мәгълүматлар бар.

Габделгазизның Сөендек исемле углы Нарат авылында имам һәм могаллим булып торды.

Габид мелла бабай 1835 елда хаждан кайткан чакта Кара диңгездә вафат булган. Кабере Синуп шәһәрендә.

7. Габделгазиз мелла бабайның атасы Гайса мелла. Арча ягы Кәнәр исемле авылда мелла булып торган. Вафат 1730 еллар тирәсендә. Туган елы 1660 еллар тирәсендә. Аның 3–4 нче буын бабалары Казан ханлыгы вакытында хансарай кашындагы мәдрәсәдә мөдәррислек иткәннәр. Үкенечкә каршыш аларның шәҗәрәләре 1928 ел Нарат авылындагы кардәшләрне раскулачивать иткән кешеләр тарафтан күп китаплар белән бергә әрәм ителгән.



## Максудия шәҗәрәсенә аңлатма

Әгерҗе төбәге Максудиларның тамырлары ата ягыннан да, ана ягыннан да бик ерак дәверләргә тоташа. Габделҗәмил бабай сөйләгәнчә, нәселнең хәтерендә калган иң ерак бабай – Төкәч (Түкәч) исемле булган. Яшәгән ди әллә Казан ханлыгында, әллә аннан да элек – Болгар заманында. Кызганычка, аннан соңгы ничәдер буын бабайларның исемнәре сакланмаган.

Шәҗәрә башлана Ибраһим бабай исеменнән, ул XVII гасырда яшәгән. Габделҗәмил Максуди бабайның хатыннары Хөснижамал һәм Шәрифә әбиләрнең нәселе дә бик борынгы. Шәҗәрә башында Гайсә хәзрәт тора. Ул әле Казан ханлыгы исән чагында Казан арты Кенәр авылында имам була һәм атаклы Кенәр мәдрәсәсендә мөдәррис булып хәзмәт итә. Аның исемен Ш. Мәрҗани «Мөстәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабында искә ала. Гайсә бабайның 1576 елда үз кулы белән язган китабы әле дә саклана. Татарстанның Үзәк музеенда З.А. Максудованың архивында. Гайсә хәзрәтнең улы Габделгазиз шул ук Арча төбәгендә Кушлавыч авылында имам булган. Казан харап булгач, алар Әгерҗе якларына качып китәләр. Анда качкан казанлыларга арлар (удмуртлар) ярдәмгә киләләр, урнашырга җир бирәләр. Шулай итеп, шул төбәктә (хәзерге ТР Әгерҗе районы) «Тугыз буй» исемле тугыз татар авылы барлыкка килә: Кадыбаш, Девятерня (Мазарасты), Нарат (Нарта), Кисәү (Косай), Эсляково (Песләк), Утяганово (Тырна), Гали, Исәнбай (Җалан оч), Атнагул (хәзер юкка чыккан). Шунда безнең бабайлар да гаиләләре белән тора башлыйлар.

Революциягә кадәр безнең нәселнең күп кенә ирләре мәдрәсәләрдә укып, шул төбәктә төрле авылларда мулла-имам вазифаларын үтиләр. Бер ук вакытта мөгалим булып та эшлиләр, авыл яшьләрен укыталар. Аларның хатыннары – остабикәләр авыл балаларына башлангыч уку-язу дәресләре бирәләр. Шуның өстенә, бөтен гаиләләре белән крестьян хезмәте дә үтәлә, шәхси хуҗалыкларны алып баралар, тормыш кирәкләре белән үзүзләрен тәэмин итеп торалар. Мисал өчен, минем Габделҗәмил бабайның тормышын алырга мөмкин. Аның турында мин әнием Зәйнәп Максудовадан ишетеп калдым (бабай мин туганчы ук туксаннан узып вафат булган). Тирсә мәдрәсәсен бетергән бабайны

Уразай (Кече Салагыш) авылы халкы, беренче мәчет төзеп, шунда имам итеп сайлый (бу турыда аның таныклыгы сакланган). Ул чакта аңарга 59 яшь булган, гаиләсе белән бергә крестьян тормышы белән яшәгән. Габделҗәмил бабай укымышлы, галим булган, унҗиде шәрык телен белгән, шулар арасыннан гарәп, фарсы һәм барча төрки телләр, хәтта инде кулланылмый торган чыгтай һәм урәнхай телләре. Күрше-тирәдәге муллалар, мөгаллимнәр арасында абруе зур булган. Габделҗәмил мулланың ике хатыны булган. Беренчесе – Хөсниҗамал бинт Габдесаттар бинте Сөендек. 48 яшендә тугызынчы баладан үлә. Калган ятим балаларга чит үги ана булмасын дип, тол калган иргә Хөсниҗамалның 16 яшьлек сеңелкәше Шәрифәне (Габдессаттар оныгы) димләгәннәр. Бу хатыннан да сигез бала туа. Барысы 17 баладан өчесе яшь вакытта үләләр. Олырак балалары Зәйнәп I, Гайниҗамал, Габделгазиз, Камал, Өммегөлсем авыл мәктәбен әтисе (әнисе) кул астында тәмамлагач, гаилә коралар, шәхси крестьян хуҗалыгы белән яшиләр. Калганнары мәктәп яки мәдрәсәләрдә укыйлар, күбесе укытучы булып җитешәләр. Бишесе – Габделхәлим, Габдеррахман, Мөхәммәдшакир, Мәгъсүмә, Зәйнәп атаклы Бубый мәдрәсәсен тәмамлыйлар. Газизә, Мөхәммәдзакир мәдрәсәне бетерми калалар. Соңгы балалары – Мөхәммәдгариф һәм Наҗия, Бубый мәдрәсәсе ябылгач, гади урта мәктәп бетерәләр. Алар да, апалары Газизә дә, революциядән соң укытучылар курсларында укыйлар. Шулай итеп, әлеге буынның яшьрәкләре укытучы булып җитешәләр. Ләкин революциядән соң, гражданнар сугышы башлангач, һәр кешенең язмышы кискен рәвештә үзгәрә, илдәге вакыйгалар белән бәйле була. Нәселнең яшьләре, ихлас күңелдән, яңа тормыш төзү идеалларына инана башлый, Кызыл Армия сафына басалар (Закир, Гариф, Наҗия) һәм көрәштә актив катнашалар. Шакир абый, Наҗия апа 1918 елда ВКП(б) партиясенә керәләр. Гражданнар сугышы беткәч, барысы да үз өлкәсендә эшкә керешәләр. Шакир абый, Наҗия апа, Гариф абый – советлар оешмаларында эшлиләр, Газизә апа, Мәгъсүмә апа, минем әни Зәйнәп – укытучы эшен дәвам итәләр.

Кызыл Армия ягында көрәшеп, Гыйльмекамалның улы Габдулла белән аның хатыны Рокыя да гражданнар сугышында һәлак булалар. Алар икесе дә укытучы булганнар. 1918 елда аклар кулына эләгеп, коточкыч җәзаланып, Гайниҗамалның улы укытучы Мөхәммәдкасыйм һәм аның хатыны укытучы Әсма да үтереләләр. Алар турында Тугыз буй авылларында риваятьләр дә сөйлиләр һәм алар һәлак булган җиргә «Касыйм аланы» дигән исем дә бирәләр.

1917 елгы революциядән соң нәселдәге күп кенә кешеләренең тормышы фаҗигале төс ала. Моның сәбәпләре билгеле – гражданнар сугышы афәте һәм Россиядәге яңа хакимиятнең дингә һәм аның әһелләренә карата сәясәте. Мондый шартларда авыр язмыш муллаларның үзләренә генә түгел, ә аларның гаиләләренә, балаларына да кагыла. Бу турыда Г.Ахуновның «Идел кызы» романында Габбас мулланың язмышы сөйли, чөнки бу «образ»ның прототибы итеп Габделҗәмилнең улы Габдеррахман Максудов алынган. Икенче мисал итеп, Габдеррахманның абыйсы Габделхәлим кичергәннәрне искә алырга мөмкин. Раскулачивание башлангач (1928-1929 еллар), шул ук Уразай яки Нарат авылында Габделхәлимнең өенә дә керәләр, үзе белән бергә гаиләсен йорттан куар өчен, милкен алалар. Боларның керүе була, Хәлим абыйның хатыны авырып түшәктә яткан килеш үлеп китә. Зур кайгыга карамастан, гаиләне куып чыгаралар, ә Габделхәлим абыйны Беломорканалга сөреп җибәрәләр. Дүрт бала ятим кала, төрле якка таралалар. Өч елдан соң Хәлим абый шундый аяусыз «стройка»дан исән килеш, хәтта «ударник» булып кайта. Бүтән гаиләләр дә шактый кайгы, югалтулар кичерәләр. Әнинең Газизә апасының гаиләсе, үзе вафат булганнан соң инде, шулай ук Кырынды авылында раскулачиваниегә дучар була. Аның ирен төрмәгә ябалар, балалар йорттан куылган хәлдә, урамда ятим калалар, хәер сорашып, авылдан авылга йөриләр. Бу репрессияләр эшләнә, хәтта кыерсытылган гаиләләр гомер буенча үз көче, үз хезмәте белән яшәсәләр дә.

Нәселдән корбаннар I империалистик, гражданнар сугышында һәм Бөек Ватан сугышында да күп була. Гомумән әйтергә мөмкин, нәселнең сугышка яраклылык яшендә булган һәр ир-аты мобилизациягә кергән. Габделҗәмил бабайның оныгы Лотфулла I империалистик сугышта хәбәрсез югала, икенче оныгы

укытучы Гыйззәтулла да шул сугышта һәлак була. Тагын ике оныгы – укытучылар Мөхәммәдкасыйм (Гайниҗамал улы) һәм Габдулла (Гыйльмекамал улы) Кызыл Армия сафында гражданнар сугышында һәлак булалар. Улы Мөхәммәдзакир да Кызыл Армия сафында көрәшә, Кырымда Сиваш вакыйгаларында катнаша, шуннан каты чирләп (сыпной тиф + туберкулез) кайткач, вафат була. Бөек Ватан сугышында (1941–1945) бабай ягыннан 21 кеше (уллары, кияүләре), әби ягыннан ... кеше катнашкан. Шулардан җиде оныгы һәм биш кияүләре сугышта һәлак булган. Алты кеше инвалид булып калган. Җиде кеше исән кайткан. Исән калганнары, сугыштагы батырлыклары өчен орденнар, медальләр белән бүләкләнеп кайталар. Кайткач, укуларын дәвам иттерәләр. Минем Равил абыем (инде мәрхүм) Артиллерия академиясен бетерде, хәрби инженер-баллист буларак ракета техникасы җитештерүдә катнашты. Полковник званиесендә отставкага чыкты. Улы Рөстәм дә инде полковник, икенче улы – КАИ бетергән инженер.. Мәскәүдә шул ук өлкәдә эшли (). Икенче абыем – Рөстәм (ул да мәрхүм инде), сугыштан соң Ленинградта югары диңгез училищесын бетерде, инженер-теплотехник булып эшләде. Шакир абый Максудовның улы Батыр, сугыштан соң, КАИР бетереп, инде күп еллар вертолетлар конструкцияләү буенча инженер булып эшли. Мәгъсүмә апаның сугышта исән калган балалары Фәүзи абый һәм Фәридә апа сугышка кадәр үк Казанда төзелеш институтын һәм стоматология институтын тәмамлаганнар иде. Алар сугышта да үз белгечлекләре буенча – сапер һәм табиб-хирург булып көрәштеләр. Хәзер икесе дә вафат.

Бара торгач, безнең туганнар соңгы 75 ел дәверендә элекке Советлар Союзында таралып, хәзер инде төрле илләрдә торып калдылар: Россиянең төрле республикаларында һәм өлкәләрендә, Урта Азия илләрендә (Үзбәкстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Төркмәнстан), Украинада, Латвиядә һ.б. Авылда бик азлары калды. Тормышта да югалып калмады алар. Яшьрәкләрдән соңгы 3–4 буынның егетләре-кызлары күбесе югары яки махсус урта белем алдылар, белгеч булып өлгерделәр.

Ни кызганыч, бабайның оныклары арасында катнаш гаиләләр күбәя, нәтиҗәдә, интенсив рәвештә руслашу процессы бара. Кайбер татар гаиләләре инде юкка да чыккан. Ләкин нәселнең күп кенә гаиләләре үз милләтен саклап яшиләр. Шуңа күрә бу татар нәселе үзен югалтмас дип уйлыйм, киләчәге бар аның.



**Гөлнар Ризаэддин кызы Газизова**
медицина фәннәре кандидаты, лаеклы ялдагы фәнни хезмәткәр
(Габделҗәмил Максудовның оныгы, Зәйнәп Максудованың кызы)
1.06.1994 – 3.04.1997

## 1919 ел июнь аенда эвакуациядән авылыбызга кайткач, нәрсәләр күрдем,ниләр ишеттем

Колчак ерткычлары безнең тирә-як авылларыбызда бигрәк тә авыр-каты җинаятьләр эшләгәннәр.

1) Туган авылыбыз Уразайдан 2-3 чакрым ераклыкта Салагыш авылында (хәзерге Әгәрҗе районы) яралы крестьян коммунист Вәҗи аганы һәм аның 70 яшьлек карчык анасын канга батырып, газаплап, кыйнап үтергәннәр.
2) Шуннан 5-6 чакрым ераклыктагы Әрс авылында укытучы булып торган 20-22 яшьләрдәге кардәшебез Шәрифҗан Шәриповны тотып алып, Салагыш авылына китереп, төрмәгә ябып, тәмам хәлләрдән тайганчы кыйнап, канга батырып, газаплап үтереп, гәүдәсен басуга ыргытканнар.
3) Уразайдан 40 чакрым ераклыктагы Нарат авылында үзем белән бертуган Гайнеҗамал тутамның укытучы углы Касыйм Гобәйдулла углы Нигъмәтуллинны һәм аның җан дусты, сабыйлык иптәше – Кызыл гаскәрдән яңа гына кайткан Габденнур Минһаҗ углы Рәсүлевне юлда тотып (Сарапулга качып киткән елларында (юлларында) алып, тәннәрен кискәләп, борыннарын өзеп, тәннәренә кызыл йолдыз рәсемнәрен кисеп, әйтеп бетермәслек ерткычларча газаплап үтергәннәр. Кызыл гаскәр килеп җиткәннән соң гәүдәләре тапталып, авылга алып кайтып туганнар каберенә күмелгән. Уразайдан кырык чакрымнар тирәсендә Кызылъяр авылының карт укытучы, коммунист Дауд абзый Гобәйдинне, шулай ук, газаплап үтергәннәр. Күчек авылының коммунист Харисны һәм иптәше Залитовны (рус) Карәндый авылында үтергәннәр. Үземнең туган сеңлем 16 яшьлек укучы – комсомолканы Алабугадан үз авылына

> Уразайга кайтып килгән чакта Салагыш авылында тотып алып, янындагы китапларын-дәреслекләрен соңгы очларына кадәр яман сүзләр белән хурлап, төрлесен-төрле якка ыргытканнар. Үзен «син – карт коммунистның яшь күсәге» дип кыйнап, үләргә якын хәлендә безнең авыл крестьяннарыннан берничә кеше (шулар эчендә Шакир абзый Зәйнулла углы) очрап, аралап алганнар. Без аны үзебез саклarбыз дип, Колчаклардан тартып алганнар. Үзебезнең өебезгә кереп, 87 яшьлек карт атабызны «Син – коммунистлар атасы» дип тотып, кыйнап, берничә көн караңгы клеткада ябып тотканнар.

Кайбер кешеләрне, атларын җиктереп, хуҗасы-ние белән, подвода дип, ничә йөз чакрымнарга алып киткәннәр. Инде Кызыл гаскәр үкчәләренә басып, артларыннан куып җитә башлагач, күп шәһәрләрне коткаргач, бу Колчак калдыклары үзләре белән алып киткән крестьян олаучыларны кыйнап, җәзалап, талап, ахырда ташлап киткәннәр. Кайбер кешеләрнең өйләрендәге җиһазларын, келәтләрендә табылган азык-терлекләрен талап алып, гаиләләрен ач һәм ялангач калдырганнар.

Шулай итеп, безнең үз туганнарыбыз арасында да, күрше авылларда да Колчак җәфаларыннан, ерткычлыкларыннан күзләрендә – канлы яшьләр, йөрәкләрендә – кайнар әрнүләр, хәсрәтләре тулы вакыт иде. Шуңар күрә, Кызыл гаскәрнең Алабуга, Ижевск, Сарапул шәһәрләрен коткарып, һәнүз алга атлаулары, Урал-Чулман буйларын Колчак ерткычларыннан котылдыру хәбәрләре халыкның күңелен күтәрә, киләчәккә, якты тормышка, Ленин төзегән хөкүмәтнең ышанычлы, ныклы дәүләт булачагына инануын көчәйтә иде. Кызыл гаскәрнең хәрәкәтендә ирешелгән һәрбер уңыш, алга атлаган һәрбер адым, Колчак тырнагыннан коткарылган һәрбер авыл-шәһәр халыкта ниндидер бер югары шатлык тойгыларын кузгата иде. Бу уңышлар халыкта киләчәккә зур өмет баглый, аны эшкә өнди. Кулыннан-көченнән килгән барлык чаралар белән Совет хөкүмәтенә, аның сакчысы гаскәргә булышлык итәргә өнди иде. Ләкин гөлләр арасында үскән тигәнәк кебек, халык арасында да таш йөрәкләр булган. Шулар Совет яклы кешеләрне үтерергә, кыйнарга, талатырга сәбәп тә булганнар. Һәм Совет гаскәре илне Колчактан коткарып килгәнен күргәч, ярыкларга качкан тараканнар кебек, үзләренең түбән җаннарын коткарыр өчен як-якка сугылганнар, таралганнар. Акларга ияреп, Себергә Колчак җәберләре арасына кереп югалмакчы булганнар. Салагыш авылыннан Хөснеддин хаҗиның угыллары, Нәҗмикәй хаҗи угыллары, Җанмирзаның Сәет мелла, Кучек авылының Гатаулла ахунд Яһудев, аның кияүләре, Биектау авылының Салахи хаҗи углы Бәһави һәм шуның кебекләр. Боларга карата халык күңелендә тирән нәфрәт тойгысы урнашкан. Аларга карата ачу-рәнҗү утлары яна иде. Менә шул шартларда мин Уразай авылыбызда унике-унөч көн түздем дә, яңадан Алабугага кайттым. Үз мәктәбемдә (№ 7) ремонт кирәкләре тирәсендә эшкә керештем.



### Көндәлек дәфтәреннән

Казанда Яңа бистәдә Мансуров Госман кулында байтак кульязма китаплар булган.

Казанда Кызыл мәчет янында Бетховен (?) урамында үз йортында торучы Мөхәммәд Гарифулла углы Салихов кулында кырыклап кульязма китап саклана.

Казанда Кабан буенда 87нче йортта Хәмит мелла Салих углы Монасыйповның подвалында 80ләп кульязма китап череп ята.

Чистай шәһәрендәге кайбер кульязма китаплар:

Шәһәр китапханәсендә саклана икән, намәгълүм язучы тарафыннан 1800 елда татар телендә язылган китап. Шул ук китапның кайбер урыннарында чуваш телендә язылган гыйбарәләр һәм кайбер рәсемнәр дә бар икән.

Шулай ук анда Хикмәтулла ишан Гаффаровтан, Закир Камаледдиновтан калган басма һәм кульязмалар күп икән.

Бу мәгълүматлар Чистай гражданины Мирза Ярмөхәммәдовтан алынды. 1923 елгы. Адресы: Вахитов урамы, йорт № ?

### Көндәлегемнән. 1972

9.12. Иртән торып, пич ягып, чәй кайнатып, азрак йөрәк ялгагач, Гөлнар эшкә китте. Рөстәм йоклап калды. Мин Рөстәмнең керләрен үтүкләдем, идәнне, паласны себердем, савытлар юдым. Шул арада почтальон пенсияне китерде. Шәмсекамәр туганым хәлемне белергә килде. Бик сөендем, бик сөйләштек. «Ана» дастанын укыдык,

чәй эчтек. Ул башымны карады, тарак белән төрткәләве бертөрле массаж сыман булып, рәхәт булып китте. Ул 1:20 ләрдә өенә кайтып китте. Мин калдым.

Рөстәм торып йөри башлады. Мин тагы чәй кайнаттым, ботка җылыттым. Шул арада Камәр ханым күтәренеп килеп керде. Акмай,усайка, алма, прәнник кертә кергән. Үзе бик арыган кебек сиздем. Шул олы яшьле ханымның мине кызганып, минем өчен азык-ашамлык кертә килүе минем җанымны әрнетте, ояларым. Ул минем өчен түгел, мин аның өчен кайгыртып, хезмәт-хөрмәт күрсәтергә тиеш идем. Ләкин ни хәл итим соң?

Мин, тиз чәй әзерләп, хәзинәдә барын өстәлгә куйдым. Мин, Камәр ханым, Рөстәм (3:00 ләрдә) чәй эчтек, ботка ашадык тәмле акмай белән. Рөстәм китте, 2 сәгатьтән кайтам, дип. Әллә кемнең проект эшенә булышам, дип. (Үзе эшсез. Телефон аркылы Глеб Абражев дигән исерек бер инженер аны чакырып, эчәргә кыстап, аптыратып бетерде). Камәр ханым кайтып китте. Мин савытлар юдым. Квартир, яктылык, телефон өчен түләргә 21 сум 17 тиен акча хәзерләп, (10.02 – түләүнең соңгы срогы) Рөстәмне көттем, кайтмады.

Таякка таянып, йөрәк даруларымны да сумкага салып, акчаларны түләргә киттем. Бик акрын гына барып, аларны түләдем. Кайткан уңайга, Кекин кибетенә кереп, сөт, эремчек, 0,5 кг акмай алып, арып-талып, тирләп-пешеп өйгә кайтып җиттем. Сөт кайнаттым, чәй кайнаттым, өстәл хәзерләдем. Аш дисәң, ботка дисәң, – анысы да әзер. Ләкин Рөстәм кайтмады. Урындык алып, өй алды ишеген ачып, тышкы һаваны иснәргә чыктым. Ике мәртәбә чыгып, яртышар сәгать һава иснәп, китап укып утырып тордым. Һава җылы, йомшак, өй алдында лампа уты янып тора иде. Күрше Суфия белән дә азрак сөйләшеп алдык. Аның да энесе Хафиз авырып, Тимер юл шифаханәсендә дәруланып ята икән. Һәркемдә бер сагыш. Минем углым һәнүз (һаман да) юк. Сәгать 8 дә, 9 да, 10 да булды. Минем йөрәктә бик каты аритмия бара. Температураны үлчәдем – 36, 8. ½ табл. валидол суырып карадым. Әле басылмады. Кордиамин эчеп карадым, басылмады. Менә хәзер сәгать: 10:30. Минем йөрәк әле дулый. Ни эшләргә, кемнән булышлык көтәргә? Минем көчлерәк вакытымда канат астымда булган 11 бала – кайда алар?



Мөхлисә, Сәлимә, Әлмәтша, Фәүзия – Горьки өлкәсендә, Хәлимә вафат, Миңнеәхмәт сугышта вафат, Мәгъфүрә әле кичә генә ирен җирләде, 2 ел элек 28 яшьлек кызын җирләде, 4 ел элек углы автоһәлакәткә очрап аягын кистерде, шунлыктан кайгы баскан ана үзен-үзе көчкә йөртә. Гайшә Әгерҗе районында пенсионер һәм тулыксыз ир белән мәшәкатьле. Үземнең зур углым Равил – полковник, ул елга бер мәртәбә дә килеп күрешми, сукыр бер тиен белән булышлык итми, хәлең ничек дип, хат язып сорашмый. Бер марҗага өйләнгәч, безгә синең кирәгең юк, дип уйлады ахры туган анасына карата. Рөстәм эчә дә эчә. Атасына барып, бергә эчәләр. Минем хакта дөньяга сыймаслык кабахәт, сүгенү сүзләре төзиләр. Рөстәм исереп кайтып, көн дими, төн дими, мине, хәкарәтләп, колагыма килеп кычкыра-кычкыра, рәнҗетеп, инде ике колагым да ишетү көчләрен югалттылар. 1928 елда Риза сугып, уң колагымны имгәткән. Шуның аркасында «воспаление среднего уха» белән авырып, ишетү тойгысы бик зәгыйфьләнеп калган иде. Проф. Трутнев бик тырышып дарулап караса да, колагым зәгыйфь булып калган иде. Инде хәзер исерек Рөстәмнең гадәттән тыш каты, тупас кычкырулары аркасында сул колагым да бик начар ишетә.

Бу бала айныса, миннән һәр көн тәмәкегә, тегеңә-моңар дип, акча сораудан башканы белми. Бирсәң, азсынып кына алып чыгып китеп югала, бирмәсәң, – кабахәт сүзләр белән сүгә, хәкарәтли. Я, сорамыйча гына, берәр нәрсәмне алып чыгып юк итә.

Рәмзинең үзен балам кебек карадым, гәрчә бик авыр сугыш елларында да, аның атасы авырган чакларда да. Мин аларны ташламадым. Кулымда барынча уртаклаштым. Ләкин Рәмзи, олы кеше булып алгач, минем хәлемне барларга да уйламый. Январь аенда алты айга беренче мәртәбә килде. Июль аенда больницада яткан чагымда 200 грамм бал күчтәнәче китергән иде, январьда 250 грамм башкорт балы китерделәр, күчтәнәч диеп. Миңа баллары да кыйммәт түгел. Үзләренә экономия итеп калдырсыннар. Хәлем яхшырса, үзем үк аларга бүләк итәрмен, һич саранлашмам. Таза гына булсам иде, балаларым тәүфыйклы булып, җаным тыныч булсын иде.

Инде иң ышанычлы терәгем – кызым Гөлнарым. Ул ни эшләсен?! Беркөн кич минем яныма кайтса, икенче көнне үз квартирына коры, җылы ятакка кайтып (Ленин районына), ял итәргә мәҗбүр.

Чөнки ул бик тирән киткән бөер авыруы белән җәфалана. Ярым подвалда урнашкан минем юеш, салкын квартирамда тоташ берничә көн-төн яшәү аның исәнлеген бөтенләй җимерә, аны фаҗигале хәлләргә илтеп җиткерү куркынычы бар. Шунлыктан аны һәр көн яныма кайтып йокла, дип кыстарга һич бертөрле көчем җитми, вөҗданым риза булмый. Кичә ул минем янымда булган иде, бүген инде үз квартирына кайтачагын иртән эшкә киткәндә белдереп китте. Ул хаклы. Рөстәм шуны белде, үч итеп кайтмады. Хәзер 11:15 сәгать. Мин ялгыз. Йөрәк начар. Панангин эчтем. ½ стакан сөт эчтем. Хәл шәп түгел. Ашыгыч ярдәм сорап телефон белән хәбәр итәр идем, каршы алырга, озатып калырга, үлә калсам – авызыма су салырга бер кешем юк. Инде булса да, хәерле булсын дип, Аллаһыга тапшырасы гына калды. Шулай икән бу: «Уңар булса, Зәйнел бәшәрдер. Уңалмаса, газиз башың ашардыр».

### Язган дәфтәрләрем

1) Борынгы уку йортлары хакында материаллар.
2) Каләм тотып, үзеннән [соң] эз калдырган кешеләребез.
3) Көнчыгыш телләрендә төзелгән төрле сүзлекләр,
4) Җырлар,
5) Бәетләр.
6) Шигырьләр, шигъри парчалар буенча татар сүз сәнгате ияләре.
7) Тәрҗемәи хәлләр хакында (гасырлар һәм хәрефләр тәртибендә) белешмәләр.
8) Көнчыгыш дөньясында гарәп, фарсы, төрки телләрендә төзелгән китаплар исемлеге (китапларның исемнәрендәге баш хәрефләре буенча).
9) Болгар-Казан тарихларына бәйләнешле кайбер материаллар.
10) Үземдәге кулъязма китаплар, сәхифәләр каталогы.
11) Үземдәге басма китаплар, сәхифәләр каталогы.
12) Борынгы Болгар-Казан төркиләре телендә сирәк очрый торган сүзләр.
13) Болгар-Казан төркиләрнең шәһәр – авыл – елга – күл – тау һәм башка географик атамалары.



### Эшләнгәнне эшләдем

1. «Об уходе за здоровыми и больными детьми» исемле китабыма рус теленнән татарчага тәрҗемә.
2. Кооператив хуҗалыгында планлаштыру эшләре хакында «Днепропетровский» китабыны рус теленнән татарчага тәрҗемә.
3. «За общим домом» исемле китапны рус теленнән татарчага тәрҗемә.
4. «Балалар бакчасында җанлы почмак» (Живой уголок в детском саду) исемле китапны рус теленнән татарчага тәрҗемә.
5. «Агачлар кешегә нәрсә бирәләр».
6. «Үсемлекләр кешегә нәрсә бирәләр» исемле китапларны русчадан татарчага тәрҗемә.
7. «Татар мәдрәсәләрендә нәфис әдәбият» журналында басылган.
8. Татар мәдрәсә шәкертләренең Пугачев хәрәкәтендә катнашулары. «Мәгариф» журналында басылган.
9. «Татар мәдрәсәләрендә нәфис әдәбият». «Безнең юл» журналында басылды.
10. Татар мәктәпләре өчен «Учебник-книга по русскому литературному чтению в VII классе» в татарской школе.
11. Татар мәктәпләре өчен «Учебник русского языка – Синтаксис для V–VII классов татарских школ».
12. Татар мәктәпләрендә рус теленнән сүзлекләр баету методлары. Татарстан укытучылар белемен күтәрү. Институтлар тарафыннан чыгарылган мәҗмугалар(ны) бастыру.
13. Шул ук темада РСФСР автономчылар съездында докладым тегәлләнде.
14. Татар мәктәпләрендә рус теле укыту эшләре хакында «Красный Татарстан» газетасында басылды.
15) Борынгы әдәбият тарихыннан материаллар. 1968 ел, «Казан утлары», № 1 басылды.
16. XIX йөз галиме Мөхәммәдкәрим Мөхәммәдрәхим углы Бикташиның өч теленең сәфәрлеге (гарәб, фарсы, төрек) турында доклад 1967/8 елда Казан дарелфөнүнендә СССР күләмендәге Тюркология съездында сөйләнде.

17. XIX йөз кыпчак әдәбиятыннан «Хөсрәү вә Ширин». Х. Госман белән берлектә эшләп, 1969/71 елда басылды.
18. XVIII–XIX гасырдагы татар шигырьләренең үрнәкләре. Университет укучыларына занятиеләр өчен кулланма итеп әзерләдем.
19. XIX гасыр кыпчак шагыйре Сәеф Сараиның «Гөлестан бит-төрки», ягъни Шәйхи Сәгъдинең «Гөлестан» исемле әсәренең төркичәгә тәрҗемәсе. Х. Госман белән бергә эшкәртелде.
20. XII–XIX гасырларда Идел-Уралда төрки-татар халкының файдаланган уку йортлары (чит илләрнең дә кайбер уку йортлары алынды. Әгәр дә аларда безнең татарлардан кем дә булса укыганы ачылса).
21. Иң борынгы гасырлардан башлап XIX гасыргача исемнәре сакланган галим, әдип, шагыйрь һәм җәмәгать хадимнәре хакында кыскача белешмәләр.
22. Безнең татарлар арасында исемнәре билгеле булган каләм әһелләре һәм эшләре хакында язмалар.
23. Татар мәктәпләре өчен рус теле дәресләре программасы: башлангыч, җиде-еллык һәм унъеллыклар өчен.
24. Тәртибе начар булган курсант ... хакында. «Татарстан яшьләре» газетасында басылган.
25. 1813 елда сатылган татар керәшеннәре хакында.
26. Ногайның Идел буе шагыйрьләренә иҗади йогынтысы. «Үзбәк мәдәнияте» газетасында басылды. 1968 ел. 15/III номеры.
27. XV йөз шагыйре Лотфиның Идел буе төрки шагыйрьләре иҗатына йогынтысы. «Үзбәк теле һәм әдәбияты» журналында басылды.
28. Шагыйрь Вәлиулла бине Хәбибулла Алкаев чүпрәк хакында мәкаль. Чүпрәле районы газетасында басылды.

## Автобиография З.А. Максудовой

Я родилась в 1897 г. 15 марта в деревне Уразаево Елабужского уезда Вятской губ. в семье муллы Максудова Абдулжамиля.

Отец родился в 1832 г. в семье крестьянина и жил исключительно крестьянином до 1891 г. В этом, т.е. 1891, году в деревне Уразаево



впервые построили мечеть, и моего отца назначили муллой, как старика грамотного. Он отказался от своего сана в 1907 году по физическим недостаткам (в старости ослеп на один глаз).

Отец имел всего 17 детей; из них 10 дочерей и 7 сыновей. После смерти первой жены выдали мою мать замуж за него, 54-летнего старика, имеющего 9 детей, по старой традиции татар и в силу того, что она была сирота.

Отец умер в 1925 г. В избир. правах поражен не был. Перенес побои 1917 года от белобандитов за то, что три сына и дочь находились в Красной Армии, другая дочь 16 лет, Назия Максудова, числилась членом Союза молодежи, работала в партизанском отряде.

Воспитывалась я в этой семье до 1904–05 года. Немного училась грамоте. А в 1904–05 году поступила в Ижбобинскую учительскую семинарию, которую окончила в 1911–12 уч.г.

Во время учебы в семинарии зимой жила оторвано от родителей, а летнее время со всеми остальными членами семьи работала в поле. Некоторое лето проводила у сестры в дер. Шаршады, ухаживала за ней – больной туберкулезом кости. Несколько летних каникул проводила в деревне Сосново Сарапульского уезда у сестры матери и других родных, которые меня одели-обули, а я репетировала их детей.

Осенью 1912 года я уехала от родителей в деревню Тарханы бывшего Симбирского уезда на школьную работу, где осталась до 1916 года.

Осенью 1916 года уехала в Сибирь, в город Атбасар Акмолинской области, где учительствовала до конца 1917–18 уч.г.

С первых дней революции работала во всех общественно-массовых работах по укреплению советской власти, за что подвергалась репрессиям со стороны местной буржуазии; это могут подтвердить члены партии: Гадеев Абдурахман, Файзуллина Магинур, Сармсакова Бибинур и ряд других товарищей, знающих меня по работе в Атбасаре.

**З.М. 1938 год**

## Автобиография

Я родилась 15 марта 1897 года в деревне Уразаево Красноборского района Татреспублики в семье крестьянина (мулла, служивший с 1894 по 1907 год и скончавшийся в 1925 году). Образование имею незаконченное среднее.

В 1911 году окончила Ижбобинскую женскую учительскую семинарию в бывшем Сарапульском уезде Вятской губернии.

В 1911–12 году стала работать в качестве учительницы при той же семинарии.

С 1912 по 1916 год работала учительницей в деревне Н. Тарханы Б. Тархановского района Татреспублики.

С 1911 по 1918 год учительствовала в городе Атбасаре быв. Акмолинской области (ныне Казахстан).

С 1918 по 1920 год учительствовала в городе Елабуге.

С 1920 по 1922 год училась в Ташкентском государственном университете. Вынуждена была оставить учебу с 3-го курса в связи с переездом в Казань из-за заболевания легких.

С 1922 по 1924 год работала учительницей в детдоме № 2 города Казани. С 1924 года, ввиду обострения легких, я вынуждена была оставить работу среди детей.

С 1924 по 1926 год – работа в Селькредпромсоюзе.

С 1926 по 1929 год – в школе ликбез при Татсоюзе.

В 1936–37 учебном году училась в Казанском вечернем университете марксизма-ленинизма. Вынуждена была оставить из-за болезни.

С 1929 по 1931 год преподавала на курсах Татсоюз.

С 1931 по 1937 год преподавала в техникуме Советской торговли.

С 1937 года по настоящее время работаю в школе (с 1937 по 1941 год в школе № 50 Бауманского района, с 1941 по 1944 год в школе № 35 Сталинского района, с 1944 года по сей день – в школе № 80 Сталинского района).

Имею некоторые печатные труды по вопросам методики обучения русскому языку в татарской школе.

Общественную работу выполняла по линии месткома своей школы, а также по линии Министерства просвещения.

Вдова. Имею трех детей. Старший сын – подполковник артиллерии, член партии с 1941 года. Младший сын – инженер-механик, член партии с 1943 года. Дочь – научный работник (микробиолог), член ВЛКСМ.



Повышением идейного уровня и своей квалификации занималась путем самостоятельного образования: чтением периодической литературы, художественной, научно-методической и педагогической литературы.

С 1.10.1912 по 1.09.1916 (4 года) – учительница в восьмилетней женской школе в дер. Тарханы Большого Тархановского р-на ТАССР.

С 1.04.1916 по 1.04.1918 (2 года) – учительница в Татарской школе г. Атбасаре Акмолинской области Казах. ССР. Справка №39 от 2.04.1918 г.

С 1.09.1918 по 1.09.1920 (2 года) – учительница в Татарской школе в г. Елабуге ТАССР. Справка № 48 от 25.07.1942 г.

С 2.10.1920 по 1.09.1922 – учительница Ташкентского женского института просвещения. Удостоверение № 238 от 14.10.1920; № 320 от 25.07.1922.

С 1.09.1922 по 1.09.1924 (2 года) – учительница в детдоме № 2 города Казани. Справка 14.06.1949 г.

С 1.10.1924 по 15.08.1926– на курсах по ликбезу среди работников Селькредпромсоюза. Докум.: расчетный лист.

С 1.09.1926 по 1.06.1928 г. (2 года) – в школе взрослых (ликбез) при Татсоюзе. Документ: Справка от 29.07.1940 г.

С 1.10. 1929 по 1.09.1931 (2 года) – на курсах Татсоюза. Документ: справка от 25.10.1936.

С 1.09.1931 по 1.09.1937 – в техникуме Советской торговли г. Казани. Преподаватель. Удостов. № 73 от 8.03.1940.

С 1.09.1937 по 15.08.1941 (4 года) – учительница в школе № 50 Бауманского р-на г.Казани. Справка № 98 от 10.06.1941.

С 15.08. 1941 по 1.09.1944 (3 года) – учительница средней школы № 35 Сталинского р-на г. Казани. Удостов. № 28 от 2.08.1948.

С 1.09.1944 по настоящее время – учительница средней школы № 80 г.Казани.

С 1.09.1928 по 1.07.1929 – училась на курсах по переподготовке школьных работников. Удостоверение № 113 от 21.12.1928.

**[без даты]**

## Укытучы–галим

## Зәйнәп Габделҗәмил кызы Максудованың тормыш юлы

Зәйнәп Максудова 1897 елның 28 мартында элекке Вятка губернасы Алабуга өязе Уразай авылында туган. Әтисе Габделҗәмил Габделманнан улы Максудов – авылның имамы, бик укымышлы, абруйлы кеше була, 17 ләп шәрык телен белә. Әтисе дә, әнисе Шәрифә абыстай да – борынгы мулла нәселләреннән. Икесе дә авыл балаларын башлангыч мәктәптә укыталар. Тормышларын алар, барча гаиләсе белән бергә, крестьян хезмәте белән алып баралар. Иген игәләр, мал асрыйлар, шуның белән көн күрәләр.

Зәйнәп бишенче бала булып туа, әтисе, әнисе инде олы яшьтә булганнар. Алар Зәйнәпне укырга-язарга өйрәткәч, җиде яшендә Сарапул өязендәге Иж-Бубый мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр. Бала бик зирәк, уку-язуны яхшы үзләштергән булганга, аны турыдан-туры өченче сыйныфка алалар, апасы Мәгъсүмә белән бер класста укый башлый. 1911 елда шул мәдрәсәне барлык фәннәрдән 10 билгесе белән тәмамлап, Зәйнәп укытучы дәрәҗәсен ала.

1911 елның башында, Ишми ишанның доносы буенча, Буби мәдрәсәсен патшага каршы фикерләрдә гаеплиләр. Мәдрәсә һәм мәктәп укытучыларыннан унлап кеше патша жандармнары тарафыннан кулга алына. Шулай да мәктәпләрдә укыту туктамый, югары классларны тәмам иткән укучылар Бубиның үзендә укыта башлыйлар. Зәйнәп тә 1911–1912 уку елын шунда укытып үткәрә.

Буби мөдәррисләре 1912 елдан соң илдән сөрелгән хәлдә дә укытучылык хезмәтләрен дәвам иттерәләр. Габдулла Буби Кытайга Кулҗа шәһәренә сөрелгән хәлдә, дарел мөгаллимат ачып, укыту эшләрен алып бара.

1912 елда Зәйнәп Максудова элекке Сембер губернасында бер ел Юнәдә укыта, аннан Түбән Тархан авылына күчә. Анда ул 1916 елга кадәр 8еллык татар мәктәбендә укыта. 1910–1911 еллардан башлап Юнә мәктәбендә аның белән бергә, апасы Мәгъсүмә һәм аның ире Фәтхеррахман Әфләтунов укыталар. 1914 елда алар Акмола өлкәсендәге Атбасар шәһәренә укытучы булып китәләр, Зәйнәпне дә үзләре янына чакыралар.

1916 елдан 1918 елга кадәр Максудова Атбасарда татар мәктәбендә эшли. Сеңлесе Нажия белән әнесе Гариф шул ук мәктәптә укыйлар, апалары янында тәрбияләнәләр. Мәктәптәге эшләреннән тыш, яшь укытучы үзенең гомуми һәм профессиональ белемнәрен күтәрергә тырыша, рус телен өйрәнә, ике еллык педагогик курсларда укый, гимназия программасы буенча «аттестат зрелости»га имтихан тотарга хәзерләнә. Атбасардагы югары педагогия училищесы советында экстерн рәвештә шул имтиханны тота һәм «учитель русского языка» званиесен ала. Шул вакыттан ул татар мәктәпләрендә ана телен генә түгел, рус телен дә укыта башлый. Атбасарда Зәйнәп Максудова иҗтимагый эшләрдә дә бик актив катнаша. Бүтән яшь укытучылар белән бергә драмтүгәрәк оештыра һәм укучылар белән спектакльләр куялар. Бу эшләр өчен Зәйнәпне Атбасар муллалары, байлары «безнең кызларны аздырасың» диеп гаеплиләр, аңа каршы халыкны котырталар. Бөек Октябрь революциясе булгач, Совет хөкүмәтенең беренче декретларын, урындагы оешмаларын күтәреп чыккан митингларда актив катнаша, чыгышлар ясый.

Җәйге каникуллар вакытында авылына кайтканда яки укыта торган авылларына китеп барганда, Казанда туктала. Анда ул заманның алдынгы фикер ияләре – Нәҗип Думави (Бубый укытучысы), Маһруй Мозаффария (Казанда Татар кызлары өчен мәктәп ачучы һәм шунда укытучы), «Сөембикә» журналының редакторы Якуб Хәлили, язучы Әхмәт Урманче һәм башкалар белән таныша. Якуб ага Хәлили 1912 елда Зәйнәпне Габдулла Тукай белән таныштыра («Совет мәктәбе»нең 1977 елгы дүртенче санында бу турыда аның хатирәләре басылды).

1918 җәендә Зәйнәп туган авылына – Уразайга кайта. Анда балалар бакчасы оештыра. Аннан соң Алабугада җидееллык татар мәктәбендә татар һәм рус телләрен укыта. 1919 елда Колчак һөҗүме вакытында З. Максудова, бүтән укытучылар белән бергәләп, Алабугадан эвакуациягә чыгып китәләр, 28 нче Азин дигән политотдел составында кызылармиячеләр арасында политик-тәрбия алып баруда катнашалар. 1920 елда ул Ташкентка китә, анда баргач, Алабугада ук сүз куешкан егетенә, Риза Газизовка кияүгә чыга. Ташкент университетының социаль-экономик факультетына укырга керә. Бер үк вакытта үзбәк хатын-кызлары өчен оештырылган Мәгариф институтында эшли, төрки телләрне укыта. Үзбәк хатын-кызлар мәгариф институтында эшләгәндә Максудованың җитәкчеләре зур галимнәр булалар – тарихчы профессор С.П. Покровский,

проф. Спасский, проф. Чердынцев, проф. Трапезников. Аларның кул астында фәнни-тикшеренү эшләрендә шактый тәҗрибә ала. Алар җитәкчелеге астында ул аспирант Лурье белән бергә «Әлфе ләйлә вә ләйлә» дигән гарәп әкиятләре мәҗмугасен тәрҗемә итү өстендә эшли башлый, ләкин бу эшне ахырына җиткерергә аңарга насыйп булмый. Русчага тәрҗемәсен Лурье үзе генә бетерә.

Университетның өченче курсын бетергәндә, нибары бер генә ел укыйсы калганда, үзе һәм бер яшьлек улы Равил бик каты малярия белән авырыйлар. Шул сәбәпле, 1922 елның көзендә гаиләсе белән Казанга кайтырга мәҗбүр булалар.

Казанга кайткач, Зәйнәп Максудова ике ел 2 нче балалар йортында эшли. Авыру сәбәпле, 1924 елдан башлап, өлкәннәр арасында эшләргә күчә. Берничә ел ул Татарстан «Центрархив»ында гыйльми хезмәткәр булып эшли. «Мәгариф» журналында тикшеренү материалларын (татар шәкертләренең Пугачев бунтында катнашулары турында) һәм «Юный педагог» журналында әдәби материаллар бастыра. 1924–1929 елларда «Селькредитпромсоюз» һәм «Татсоюз» янындагы ликбез һәм башка курсларда дәресләр биреп йөри, тәрҗемә эшләре белән шөгыльләнә, сигезләп китапны русчадан татарчага күчерә. 1931–1937 елларда совет сәүдә техникумында укыта. Шуннан соң ул яңадан мәктәпкә, үзенең яраткан эшенә кайта. Башта 1937–1941 елларда Казанның – 50 нче мәктәбендә, 1941–1944 елларда – 35 нче мәктәбендә, соңгы ундүрт елын 80 нче мәктәптә укыта. Бу елларда укучыларга рус телен өйрәтү методикасы өстендә күп эшли, татар мәктәпләре өчен рус теле буенча дәреслекләр, программалар төзүдә катнаша (җиденче класс өчен рус теле синтаксисы һәм төрле методик ярдәмлекләр), аның утызлап методик һәм фәнни хезмәте матбугатта басылып чыга.

1957 елда мәктәптән пенсиягә киткәч, Зәйнәп Максудова ун ел буена Казан дәүләт педагогия институтында һәм Казан университетында гарәп теле факультатив курсын алып бара. Университетның һәм Фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни хезмәткәрләре белән бергә, борынгы төрки-татар кульязмалары өстендә күп эшли. Бу эшләрнең максаты – борынгы әсәрләрнең эчтәлеген, аларның тел, әдәбият, татар халкы тарихындагы әһәмиятен ачып бирүдән гыйбарәт. Күп телләр белгече, шулар арасында борынгы төрки теле, гарәп, фарсы телләре, төрки филология өлкәсендә күренекле галим, археограф буларак, Зәйнәп Максудова яшь фән хезмәткәрләренә фәнни эзләнүләрендә, борынгы әдәби җәүһәрләрне ачуда, дөньяга чыгаруда күп ярдәм итте. Ул әдәбият, тел белгечләре белән бергә эшли. Мәсәлән, профессор Хатип ага Госман белән Алтын Урда заманындагы шагыйрь Сәиф Сараиның әсәрен хәзерге татар теленә транскрипцияләп, комментарийлар белән язып бирделәр һәм башка әсәрләр өстендә эшләделәр. Кирәк чакта бу әсәрләрне гарәп шрифтына күчерү өчен, Зәйнәп Максудова көне-төне үзенең матур каллиграфиясе белән язып утыра иде. Бу әсәрләр матбугатта басылып чыккач, студентларга уку китаплары булып хезмәт иттеләр. Шакир ага Абилов белән борынгы болгар шагыйре Лотфи әсәрен (XIII гасыр, Зәйнәп Максудованың коллекциясендә саклана иде, хәзер Татарстан милли музеенда, Зәйнәп Максудованың архивында) тикшереп, мәкалә яздылар. Шундый материаллар белән Зәйнәп Максудова җыелышларда, конференцияләрдә докладлар белән чыга, журналларда аның мәкаләләре басыла.

Зәйнәп Максудова гомер буе тикшеренү материаллары нигезендә биографик-библиографик каталог төзеде. Бу каталог-белешмә эченә көнчыгыш галимнәре, әдипләре, шагыйрьләре һәм аларның әсәрләре кертелгән. Гарәп, фарсы, төрки телләрдәге әсәрләр – татар халкының мәдәниятенә кергән яки йогынты ясаган әсәрләр. Бу уникаль хезмәткә мондый исем бирерлек: «Татар халкының һәм көнчыгыш халыкларының мәдәни бәйләнешләре». Каталогта җыелган материаллардан күренгәнчә, бу элемтәләр гасырлар буена – IX гасырдан хәзерге елларга кадәр барган. Каталог хронологик, тематик һәм алфавит принциплары нигезендә төзелгән, анда җиде меңнән артык авторның карточкалары тупланган һәм аларның 30 меңләп әсәрләре җыелган. Һәр автор турында кыска гына биографик мәгълүмат бирелгән: тулы исеме, кушаматы (псевдонимы), туган урыны, туган һәм үлгән еллары, билгеле әсәрләре, алар кайда саклана, яки алар турында кайда мәгълүмат бар, татар халкына кайчан билгеле булган һәм кемнәр файдаланган. Бу био-библиографик каталог хәзер Татарстан милли музее фондында саклана. Бер өлеше – Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульязмалар бүлегендә. Каталогтан башка, музейда

аның борынгы кулъязмаларны һәм гарәп имлясында басылган китапларны үз эченә алган зур коллекциясе саклана. Күренекле педагог, ярты гасыр стажлы укытучы Зәйнәп Максудова меңләгән укучыны белем белән коралландырып, зур тормыш юлына хәзерләүдә катнашты. Алар илебезнең төрле төбәкләрендә халкыбызга намуслы хезмәт күрсәтәләр. Ачык дәресләр биреп, «Совет мәктәбе» журналында (хәзерге «Мәгариф» журналы) мәкаләләр язып, «Педагогик укулар»да докладлар ясап, ТИУУда җәйге курсларда лекцияләр укып, укытучыларга күп ярдәм күрсәтте. Гомер буе үз эшенә бирелеп, үз халкының телен, әдәбиятын, тарихын өйрәнүгә зур көч куйды. Бу эшләре белән ул соңгы көннәренә кадәр шөгыльләнде. Авыруы көчәеп, 1980 елның 3 февралендә вафат булды. Казанда Яңа бистәнең татар зиратында (бишенче юл) җирләнде.

**Зәйнәп Максудованың кызы Гөлнар Газизова**

Казан, 5 июль, 2003 ел

### [Зәйнәп Максудова төзегән Коръән багышлау догасы]

Илаһи, йә Рабби, шушы укыган Кәлям шәрифнең савабын багышладым пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәләм рух шәрифенә. Шулай ук, аның гаиләсенең һәм барлык сәхабәләренең рухларына багышладым. Үзеңнең рәхмәтең белән васыйл мөтәвасыйл, шулай ук, бу укыган Кәлям савабын барча пәйгамбәрләрнең, рәсүл һәм нәбиләрнең рухларына, барлык изгеләрнең, вәлиләрнең, шәһитләрнең, остазларның, барча мөэмин-мөселман ирләрнең рухларына багышладым. Хосусан, газиз әткәем Габделҗәмил Габделмәннан углының, газиз әнкәйләрем Хөсниҗамал Габдессәттар кызының, Шәрифә Нигъмәтулла кызының рухларына багышладым. Аллаһым васыйл мөтәвасыйл кыл рәхмәтең берлә.

Шулай ук, әткәем ягыннан бабаем Габделмәннан Максуд углына, әбиләрем Әсхабҗамал һәм Миңлеш хатыннарның рухларына; анам ягыннан бабайларым Габдессәттар Сөендек углының, әбием Мөхибҗамал ханымның, Нигъмәтулла Сәйфулла углының һәм Сахибҗамал Габдессәттар кызының рухларына багышладым. Йә Рабби, Үзеңнең рәхмәтең белән аларга васыйл мөтәвасыйл кыл. Шулай ук, шушы укылган Коръән шәрифнең савабын багышладым атам ягыннан гүр иясе булган барлык мөэмин-мөэминә туганнарның



рухларына, анам ягыннан гүр иясе булган мөэмин һәм мөэминә туганнарның рухларына, хосусан, үземнең туганнарым Габделгазиз, Габделхәлим, Мөхәммәдгариф беренче, Габдеррәхман, Мөхәммәдшакир, Мөхәммәдзакир, Мөхәммәдгариф икенче – Габделҗәмил угылларының рухларына багышладым. Йә Рабби, Үзең васыйл мөтәвәсыйл кыл. Шулай ук, бу укыган Кәлам Шәрифнең савабын багышладым гүр иясе булган кыз туганнарым Зәйнәп, Гыйльмеҗамал беренче һәм икенче Гыйльмеҗамал, Өммегөлсем, Газизә, Нәҗия, Нәсимә – Габделҗәмил кызларының рухларына багышладым. Йә Рабби, Үзең лотфың, рәхмәтең белән васыйл-мөтәвасыйл кыл.

Шулай ук, бу Коръән шәрифнең савабын бездән дога өмет итеп ятучы барча дусларның рухларына багышладым. Ходаем, рәхмәтең берлә васыйл мөтәвасыйл кыл. Шулай ук, никах буенча туганлашкан ир-хатын кардәшләрнең рухларына багышладым. Шулай ук, ошбу Коръән шәрифнең савабын балаларым Равил, Рөстәм, Гөлнарның һәм балаларның рухларына багышладым. Аларга тәүфыйк-һидаять, бәхет-сәгадәт бир, хәләл ризык, тугры кәсеп белән дөньяларын киң кыл. Йә Рабби, Аллаһым, Коръән шәрифне дөньябызда иптәш кыл, каберебездә юлдаш кыл. Кыямәттә шәфәгатче кыл. Тәмуг утларыннан, җәһәннәм газабыннан саклаучы пәрдә кыл. Дөньяда һәртөрле яманлыклардан саклаучы, һәртөрле изге эшләргә дәлаләтче-юлбашчы кыл, иман кыл.

Йә Рабби, Аллаһы! Үзеңнең фазыйлең берлә, йә Рабби, иң юмартларның да юмарты Син. Укыган Коръән шәрифнең савабы белән безне җәннәткә керт, күңелләребезне төзек кыл. Гөнаһларыбызны ярлыка. Соңгы сулышларыбызны бакый иман белән үткәр, Үзеңнең киң рәхмәтең, вөҗүдең берлән. Әй Аллаһым, шушы Коръән шәриф белән безнең күңелләребезне зиннәтләндер, күзләребезне нурландыр, иманыбызны даим, нык кыл, мөхәккәм кыл, Коръән бәракәтендә мизаныбызны авыр кыл. Мөбарәк Коръән бәракәтендә авыруларыбызга шифа бир, үлгәннәребезгә рәхим, мәрхәмәт кыл. Тәвәккәлләребезгә тән тазалыгы, күңел шатлыклары, мәгыйшәт киңлекләре белән бәрәкәтле тормыш бир. Ахыр сулышта хәерле хәтимә бир. Ике дөньяның хәерлесен бир. Ике дөньяның яманлыкларыннан Үзең сакла. Иман белән, мөселманлык белән дөньядан үткәр, изгеләр төркеменә урнаштырып, җәннәт-сәлам йортын насыйп ит. Амин. Йә Раббел галәмин.

# Указатели

## Исемнәр күрсәткечләре

**А**

Ахун б. Хисамеддин әл-Әтавый *168*

**Ә**

Әбү Бәкер б. Биктимер *168, 295*
Әбү Бәкер б. Ибраһим Казанлы *321, 331, 332*
Әбү Бәкер б. Шәмгүн *45, 333*
Әбү Мөхәммәд Гарифулла әс- Салихи *41, 314, 349*
Әбү Наср Курсави *12, 22, 34, 44, 76, 103, 312, 313, 319, 336*
Әбүлфарук Мөхәммәдшакир б. Габделҗәббар *313–314*
Әбүш б. Сибгатулла *46*
Әхмәд б. Кәмал *274, 277*
Әхмәдсадыйк б. Сәфәргали *147*
Әхмәтҗан б. Әхмәди *44*
Әхмәтҗан б. Хәмзә *61*
Әхмәтсафа б. Фатхулла әз-Зәдури *80–83*
Әхтәм б. Габделлатыйф *196*

**Б**

Байморад б. Мөхәррәм әл-Мәңгәри *84, 294*
Баттал б. Җүрти *57, 333*
Батырша *217, 221*
Бәһадир б. Сийаркол *331*
Бәшир б. Габдулла *131-133, 134, 320, 334*
Бәшир б. Уразай *327*
Биби-Хәнифә Исмәгыйль кызы *247*
Бикмөхәммәд б. Бикбау *199*
Бикчәнтәй б. Ибраһим Бәрәскәви *324*
Бикчәнтәй б. Юлдаш *116, 292, 334*
Борһанеддин б. Баһауддин *44*
Борһанеддин б. Ибраһим әл-Болгари *286*

**В**

Вәлид б. Сәгыйд әл-Минзәләбаши *311*

**Г**

Габделәхәд б. Фәйзулла *182*
Габделбәдигъ б. Котлыәхмәд әд-Динсәви *46*
Габделвахид б. Габдулла әл-Буави *92–93*
Габделвахид б. Файзулла әл-Мазарасты *211, 213, 219–220*
Габделваһаб б. Габделмәҗид *94–95*
Габделваһаб б. Мостафа *115–116, 292, 328*
Габделвәли б. Габделгаффар Яңачокали *98*
Габделгазиз б. Бәхетгәрәй *167*
Габделгазиз б. Гайсә әл-Көнәри *74, 165, 172, 310, 342, 343*
Габделгалим *184*
Габделгалләм б. Нигъмәтулла *66*
Габделгалләм б. Фазлулла *119*
Габделгафур б. Кушай *276*
Габделгафур б. Сәйфулла *332*
Габделҗәббар б. Мөхәммәд Әмирхан Милгафури *254*
Габделҗәмил б. Габделмәннан *65–73, 96, 106, 117, 122, 176, 221, 228*
Габделкадыйр б. Гобәйдулла *210*
Габделкәрим б. Мөхәммәд *102*
Габделкәрим б. Хәлил *51–52, 166, 319, 333*
Габделлатыйф б. Габдесәлам *322*
Габделлатыйф әс-Сокмани *197*
Габделман б. Габделкәрим *225–226*
Габделхак Латыйпов *272*
Габделхалик б. Китаб *96*
Габделхаликъ б. Ибраһим әл-Курсави *312*
Габделхәер б. Габделкәрим *60, 151*
Габделхәлим б. Габделҗәмил *48*
Габденнәфикъ б. Сөендек *49, 55*
Габдерәкыйб б. Габдерәшид *191*
Габдеррәшид б. Габдесәлам *323*
Габдеррәшид б. Мөхәммәд *328*
Габдеррәхим Утыз-Имәни *123*
Габдеррәхим б. Габдеррәшид әл-Болгари *143, 147, 317*
Габдеррәхим б. Яркәй *328*
Габдеррәхман Курсави *230*
Габдессәлам б. Габделваһаб *206*
Габдессәттар б. Сөендек *43, 51, 52, 94, 104, 125, 165, 166, 181, 217, 221–222*
Габдешөкер б. Габдеррәхим *145*
Габдәш б. Габдессәлам *149, 151, 162, 199, 202, 319, 323, 334*
Габдулла б. Гатаулла әл-Казани *123, 191*
Габдулла б. Нур *273*
Габид б. Габделгазиз әл-Көнәри *53, 166, 181, 221, 342*
Гайнулла б. Фәйзулла *171, 332*
Гайсә б. Тимер Пәслакый *94, 96*
Галулла б. Гөрелбай әл-Казани *196–197*
Гатаулла б. Мөхәммәди әл-Курсави *239–240, 249, 258–259*
Гатаулла б. Яһүдә *330, 349*
Гобәйдулла б. Госман *148*
Гобәйдулла б. Мәүлед *325*
Гомәр б. Габделгазиз *291*
Гөзенфәр б. Фәзаил *316*
Гыйльман б. Үтәш *325*
Гыймадеддин б. Кәмаледдин *144–146*

**Д**

Дәүләтшаһ б. Илбәк *334*

**Ж**

Җамаледдин б. Сәйфелмөлек әл-Мәскәви *58*
Җамаледдин б. Сөбханкол *315*
Җәгъфәр б. Салих Кулаткый *317*
Җәлаледдин б. Сәгъдәддин әз-Задури *294*

**З**

Затый б. Габдеш *293*
Заһиреддин Әбулфәез Габдеррәхман әл-Бохари әл-Болгари *315*
Зәйнеддин б. Мөнәсиб ән-Нуркәви *45*
Зәйнелгабидин б. Габделкәрим *327*
Зияддин б. Кәмаледдин әл-Хуҗаши әл-Болгари *88*
Зияддин б. Мөхәммәдшакир Сөендеков *124–125*

**И**

Ибраһим б. Габдулла ән-Нократый *143, 147, 213, 317*
Ибраһим б. Йосыф Казани *330–332*
Ибраһим б. Мөхәммәдгали әл-Кәнәви ән-Наласавый *231–234, 238, 241, 249–250, 253, 259–261, 263, 266, 268*
Ибраһим б. Мөхәммәд Түләк *325–326*
Илкәй б. Мостафа *168, 321*
Исмагыйль б. Габделвәли *252–253*
Исмагыйль б. Муса *198*
Исхак б. Габделкәрим *322*
Исхак б. Годәйдулла Юнусов әл-Казани *63*
Ишбай б. Ишмирза *327*
Ишмөхәммәд б. Заһид әл-Күбаки *312*
Иштуган б. Морат *125*

**Й**

Йосыф мирза б. Котлымөхәммәд *326*

**К**

Кәмаледдин б. Нәҗмеддин *87–88*
Котлымөхәммәд Мирза б. Тәвәккел *325–326*

**Л**

Лотфулла б. Гатаулла Әлмәти *215, 302*
Лотфулла б. Фәез *310*

**М**

Максуд б. Корбангали *334*
Мансур б. Әби Нүх әл-Мәгъриби *89–90*
Мәгъсүм Садыйков *218*
Мәннангол б. Имангол *131–132*
Мәсгүд б. Мөхәммәд *332*
Мәхбүбә б. Сөендек *174, 341*
Миңле Гази б. Миңле Хафиз әс-Сәфәри *127*
Мозаффар б. Мортаза *328*
Морадбакый б. Мәмәкәт әл-Болгари әл-Казани *321*
Мортаза б. Габделгазиз *324*
Мортаза б. Котлыгуш әс-Симети *125, 276, 328*
Мортаза б. Мөхәммәд *328*
Мортаза б. Хәмзә әл-Җәбәли *79*
Мөгаз б. Габдеррәшид *140, 142*
Мөнасиб б. Муса *190*
Мөхәммәд б. Әхмәд әл-Болгари *161*
Мөхәммәдәмин б. Мөхсин *228*
Мөхәммәдәмин б. Сәйфулла *77, 78, 168*
Мөхәммәдвәли әл-Казани *197*
Мөхәммәдгали б. Гирай (?) Гали
Мөхәммәдҗан б. Кадырмөхәммәд әл-Вәриши *314*
Мөхәммәдзакир б. Мөхәммәдгали *261*
Мөхәммәдкәрим б. Мөхәммәдрәхим *61–62*
Мөхәммәдрәхим б. Йосыф әл-Ашытый *279, 313, 320*
Мөхәммәдсадыйк б. Габделвахид *219*
Мөхәммәдсадыйк б. Динелислам Качимов *213*
Мөхәммәдсадыйк б. Таҗеддин әл-Карлавый *160*
Мөхәммәдсафа б. Мөхәммәдгали Наласавый *231–232, 238–241, 249–250, 253, 259–261, 263, 266, 268*
Мөхәммәдфатыйх б. Габделхалик *57*
Мөхәммәдфатыйх б.
Мөхәммәдшөкүр әл-Яхъя *248*
Мөхәммәдшакир б. Габдессәттар *338–339*
Мөхәммәдшакир б. Мостафа *145*
Мөхәммәд Шәриф б. Ибраһим *46–47*
Мөхәммәдшәриф б. Мөхәммәдрәхим *279*
Муса Исхак Уразаев *160*

**Н**

Нәҗмеддин Кубра *199, 288*
Нәҗмеддин б. Хафизеддин Тукаев *128*
Нигъмәтулла б. Бәшир *329*
Низамеддин б. Сәлимҗан *114*

**Р**

Разыйэддин Әбү Әхмәд әш-Шәфигый *318*
Рәфыйк б. Уразай *109, 334*

**С**

Сабирҗан б. Габделбәдигъ әл-Мәчани *244*
Сатый б. Габдәш *162, 164*
Сәед б. Мөхәммәд әл-Болгари *324*
Сәгыйд б. Ибраһим Барышый *310*
Сәгыйд б. Хәмиди Бәрәскәви Бистәви *314*
Сәгъдеддин б. Габделмәҗит *329*
Сәгъдеддин б. Хәйреддин *139*
Сәйфелмөлек б. Сәлим *125, 260*
Сәлахеддин б. Габделгазиз *145–146*
Сәлимҗан б. Дусмөхәммәд әл-Газани әл-Кавали *228*
Сәфәр б. Гомәр *327*
Сибгатулла б. Лотфулла *187*
Сөендек б. Габделгазиз әл-Көнәри *53–54, 125, 334, 341–342*
Сөендек б. Исергәп *327*
Сөләйман Саксини *107, 181, 200*



**Т**

Таҗеддин б. Габдеррәшид әл-Иштирәки *107, 181, 200*
Таҗеддин б. Гыйсмәтулла *320*
Таҗеддин б. Мөхәммәд Бәшир әл-Болгари *55–56, 61, 84–86, 151–152, 157, 294*
Төхфәтулла б. Җәгъфәр *212*
Тулмөхәммәд б. Дусмөхәммәд *320*

**Ф**

Фәтхулла б. Хөсәен әл-Оры *235, 258, 314, 321*
Фәхреддин б. Габдеррәшид *323*
Фәхреддин эн-Наратбашы *88*

**Х**

Хаҗи Әхмәд б. Хаҗи Мөхәммәд *278*
Хәбибулла б. Рәхмәнкол *87–88*
Хәбибулла б. Фәзлулла *188*
Хәзинә, Ибраһим җәмәгате *100*
Хәлил Ырынбургый *220*
Хәлилулла б. Зәйнулла *315–316*
Хәмит б. Ислам *274*
Хәмит б. Ишимбай *109*
Хәмит б. Мортаза *329*
Хөсәен б. Габделкәрим әл-Болгари *321*
Хөсәен б. Газиз *221*
Хөсәен б. Мәскәү *91–92, 160, 332*
Хөсәен б. Нигъмәтулла *315*
Хөснеддин б. Габдулла Янтугани *92, 93, 112, 332*
Хуҗаәхмәт б. Мозаффар Гурникави *99*

**Һ**

Һибәтулла б. Сәет Баттал Салихый *280*
Һилаледдин б. Әсәдулла *112*

**Ш**

Шаһиәхмәд әл-Болгари әл-Бохари *265*
Шәйхислам б. Тимербәк *316*
Шәйхулла б. Вәлиулла әл-Әкыйгәнти әл-Болгари *65*
Шәмседдин б. Габдеррәшид әл-Казани *323*
Шәмседдин б. Ишмөхәммәд *91–92, 160, 162*
Шәмседдин б. Тимеркәй *260*
Шәрәфеддин б. Кадыр *61-62*
Шиһабеддин б. Бәһаэддин *208, 238, 244, 270, 330*

**Я**

Ягъкуб б. Нигъмәтулла *65, 96, 121–122, 186*

## Китап исемнәре

احياء علوم الدين 61
اداب القرآن 168
اصول المنار متن زبدة الاسرار 265
الارشاد للعباد 265
التلويح الى كشف حقائق التنقيح 262
القرآن الكريم 100
المنقذ عن الضلال 264
امالى 164
انموذج 290, 294
باقرغان 204
بخار زاده 69 ,115
بدان 290
بستان العارفين 94
بستان القدس و گلستان الانس 207
پند نامه 114, 121
تأريخ الاسلام 110
تحفة الفقهاء 163, 293, 294
تحفة المريد 78
تحفة الملوك 69, 115
تخليق آدم 277
تركيب المنصورية 128
تركيب و عوامل مائة 192
تعريفات 89
تعليقات فى مسائل العقائد 244
تفسير القرآن [نعمانى] 44, 103

تفسير سورهء القدر 70
تلقيح العقول فى الفروق 214
تنبيه العافلين 217
تواريخ بلغاريه 112, 165, 166, 177, 207, 208
ثبات العاجزين 108
جامع الرموز 229
جامع الفتاوى 151
جامع الفتاوى فوائد اسلامية 101
جلاء القلوب 111
چوپان نامه 119, 121
حاشية الآقكرمانى 52
حاشية الشرح الرسالة العضدية 270
حاشية بر تهذيب 230
حاشية عبد الحكيم الاهورى
السيالكوتى على شرح ايساغوجى 231
حاشية على الفوائد الضيائية 190
حاشية على رسالة الشمسية 238, 244
حاشية على شرح التهذيب 254
حاشية على شرح ايساغوجى 50, 122, 196, 231, 232, 234, 292
حاشية على شرح سلم العلوم 197
حاشية على شرح عقائد 257
حاشية ملا صادق على شرح
ايساغوجى 249
حكاية في بنياد القدس 127
خريدة العجائب و خريدة الهرائب 176, 247
خلاصة الحساب 241
داستان چنگيز خان و احوال
آقساق تيمر 169
دلائل النبوت محمدى شمائل
فتوة احمدى 107
دله خاتون 118
راحت دل 108
رسالة المتعلقة بشرح الشمسية 239
رسالة برهانية لمولانا برهان
الدين فى حاشية اداب المناظرة 286
رساله توحيديه 276
رسالة علم 238
رسالة علم فى تحقيق العلوم
والمعلوم 199
رسالة فوقه ناجية 265
رسالة فى بيان علم تصوف
و اهل تصوف 199
رسالة فى حق اداء صلوة العشاء
فى الليالى القصر فى بلدة البلغار 265
رساله مهمة 202
رسالهء عزيزه 282
رسالهء مدنية 190
رسالهء منظومه فى بيان التوحيد 129
روضة العلماء 291
روضة العلماء و نزهة الفضلاء 42
رونق الاسلام 164
رياض النفس 247
زبدة الاسرار فى شرح مختصر
المنار 97
سراج الوهاب فى اتنأ مراتب
سلم العلوم 245
سلم العلوم 67, 240
سوانح الحجاز في الترقى الى
الحقيقة عن المجاز 117
سورهء اخلاص تفسيرى 63
شرح اسماء الله 130
شرح الشمسية 252
شرح العقائد الغضدية محمد
ابن اسعد 284
شرح العقائد النسفي 49, 129, 258, 291
شرح الكافية 149
شرح النقاية 183
شرح امالى 87
شرح تعريفات 78
شرح تهذيب التفتازانى 266



شرح سلم العلوم لقاضى
محب الله 198, 268
شرح شمسية فى قواعد المنطقية 83, 219, 294
شرح عقائد 86, 92, 272
شرح عقيدة السنوسية 76, 77
شرح على 268
شرح على الفوائد الضيائية 191, 225
شرح عوامل 128, 135
شرح فرائض سراجية 53, 240
شرح فقه الاكبر 86, 226, 263
شرح قدورى 291
شرح كتاب وصاياى پير على 75
شروط الصلوة 115
شمسية متن مختصر فى
قواعد المنطق 79
صدق الكلام الجلى حاشية
على شرح عقائد النسفى 242
طريقة محمدية 192, 225
عقود المنظومة 73, 91
عوامل المائة 128, 192
فتاوى مجوعه سى 235
فتوحات الوهمية 130
فتوحات الهى 189
فرائض سراجية 44, 152
فصول عشرة 189
فوائد ضيائية فى شرح الكافية 61, 65, 294
قاضى مبارك فى شرح سلم العلوم 68
قافيه 119
قصهء ابو شحمه 168
قصهء زرقوم 160
قصهء سيف الملوك و بديع
الجمال 109
قصيدهء الامالى 71
قصيدهء برده 194
قواعد الاعراب 135
قول المحيط 253
كاليندار 134
كتاب اسلامية 134, 140
كتاب الايساغوجى 48, 49, 233, 291
كتاب التوحيد 205
كتاب التوضيح 42, 213, 227
كتاب الفرائض من الفتاوى
العالمگير هنديه 156
كتاب اللوائح 264
كتاب النصائح 264
كتاب بهترين 117, 119
كتاب عقائد نسفية 55
كتاب عين العلم 45, 124, 184, 209
كتاب فى المواعظ 246
گل و نوروز 174
گلستان 96, 129
مثنوى شريف 123
مجالس الابرار 79
مجالس الشهور 124, 188, 211, 246
مجمع الاحاديث 147
مجمع الاوراد 110
محمدية 102
مختصر الوقاية 42–40, 44, 49, 57, 87, 203, 295
مختصر الوقاية فى مسائل
الهداية 106
مختصر من كتاب القانون
فى الطب 112
مختصر وصية البرككولى 206
مداقعة 220
مسائل العقائد 126
مسلك المتقين 186
مشكاة الانوار فى لطائف الاطبار 71
مشكاة مصابح فى شرح مصابيح 228
معجزات النبى 64, 225
معراج الفهوم في شرح سلم العلوم 56

معراج النبى 200
مفاتح الجنان فى شرح شرعة الاسلامية 160
منافع الناس 170
منتخبات من الكتاب الحياة الحيوان 127
منية المصلى و غنية المبتدى 66, 228
مواقت الصلوة 166
مولوى قاسم 60
مير سيد شريف 122
مير سيد شريف 79, 143
نصائح الاخبار 105
نصاب الاخبار لتذكير الاخيار 162, 292
نفحات الانس ترجمه سي 172
نوادر الاصول فى معرفة احتار الرسول 280
وصيت نامهء الامام الاعظام 138
وصية الامام الاعظام 106
وصية پيرگلى 279
هدية الصعلوك فى شرح تحفة الملوك 51
يا ايها الولد 136, 202
يك حكايت 70, 114


## Урыннар күрсәткечләре


Ашыт *313, 314, 320*
Әгәрҗе *147, 184, 341–342, 347*
Байлар *332*
Бай уланнар *328*
Бизнә *328–329*
Бикбау *184*
Буа *92, 112, 329, 333*
Бубый *43, 51–53, 65, 165, 166, 272, 319, 333*
Бүрә Киртә *46–47*
Дәвек *46–47, 112, 292, 328*
Динсә *46*
Иске Задур *99*
Иске Рәҗәб *327*
Йортыш *274*
Казаклар *57, 187, 205–206, 333–334*
Кавал *199, 320*
Казан *41, 62, 67, 84, 86, 199, 222, 294, 302, 313–314, 318, 324, 328, 331*
Каргалы *148, 187, 310, 322–323*
Карлы *311*
Карыйл *54*
Качмакты *311*
Кура Алычык *125, 260*
Курса *103, 157, 313, 316, 319*
Кышкар *166, 181, 222, 310–311, 324, 342*
Мәчете *44*
Мәчкән *279*
Мәчкәрә *198, 313, 319, 335*
Наласа *168*
Нарат *54, 124, 128, 160, 165, 174, 180–184, 217, 221–222, 293, 332–345*
Олуг Мәңгәр *56, 86, 157*
Пәслаке *94*
Салагыш *50, 162–163, 293, 347–349*
Салих *261*
Сарай *315, 327*
Сарда *252–253*
Сәман *103*
Сибай *147*
Ташкичү *325*
Ташлыяр *333*
Тәкермән *97*
Тимәш *104*
Тирсә *48, 65–66, 69, 96, 106, 121–122, 132–134, 137, 141, 147, 184, 186, 197, 291, 293, 316, 320*
Тукай *94, 96*
Туралы *145*
Шахмай *46, 48, 123*
Ура *266, 314*
Уразай *16, 25, 100, 109, 171, 176, 322, 332, 338–340*
Урбар *143, 147, 317, 319, 334*
Ургенч *288*
Үрнәкбаш *61*
Чабатлы *280*
Чалкан *218*
Чишмә *320*
Хәерби *149, 151, 202, 319, 334*
Янгол *320*
Яңа Иштирәк *311, 322*
Яуширмә *144–145*


## Мөһерләр күрсәткече


... عريف 83
احمد صفا بن فتح الله 80
اسماعيل بن محمد على 263
افوض مرى الله الى فحر الدين بن عمر 207
خاطب امير حانف / Хатыпъ Вильдановичъ Амирхановъ Казань 57
شاه مراد بن احمد 57
شهاب الدين بن بهاء الدين 208
عماد الدين بن كمال الدين 146
محمد شاكر القورصاوى 194
محمد شاكر بن محمد شريف 1840 84
ملا عبد الحق بن عطاء الله 269
Указн.мулла Абдулхакъ Файзуллинъ в д. Казый /
ملا عبد الحق بن ملا عطاء الله فيضوللين 271
ملا عبد الخلق ابن ملا عطأ الله ... 242
موسى تمشو (؟) بن صابر جان 60


## Кыскартулар исемлеге

| | |
|---|---|
| **ВС ОРРК НБ КФУ** | Восточный сектор Отдела рукописей и редких книг Научной библиотеки Казанского федерального университета |
| **ИВР РАН** | Институт восточных рукописей РАН |
| **ИЯЛИ АН РТ** | Институт языка, литературы и искусства АН РТ |
| **КГУ** | Казанский государственный университет |
| **НМ РТ** | Национальный музей Республики Татарстан |
| **GAL** | Carl Brockelmann. Geschichte der arabischen Litteratur. 5 vols. Leiden, E.J. Brill: 1937–1949. |
| **Hofman** | Henry Hofman. Turkish Literature: A Bio-bibliographical Survey, Volumes 1–3. Utrecht, 1969. |

# X. Факсимиле письма Шихаб ад-Дину ал-Казани

**НМ РТ 18369-173**






ТЕТРАДЬ



























# IX. Факсимиле документов Кутлуг Мухаммад мирзы Тефкелева

**НМ РТ 18369-140**



تاتار میودالی قطلغ محمد مرزا تفکیلف
هم توقومالاری حقنده





# VIII. Факсимиле *фатава* Муртазы ас-Симети

**Описание рукописи: 362 (9)**

























# VII. Факсимиле йасавийского агиографического сочинения

**Описание рукописи: 360 (59)**








# VI. Факсимиле сочинения «Рисала фи байан ʻилм тасаввуф ва ахл тасавввуф»

**Автор: Наджм ад-Дин ал-Кубра**
**Описание рукописи: 233 (83)**



















# V. Факсимиле сочинения «Кыссаи Әбу Шихмә»

**Автор: Ахун бине мулла Хисамеддин әл-Әтавый**
**Описание рукописи: 176 (191)**































# IV. Факсимиле сочинения «Дилә хатын»

**Описание рукописи: 97 (87)**











# III. Факсимиле сочинения «Тәфсир сүрәи Кадер»

**Автор: Габделҗәмил Габделмәннан углы Максуд**
**Описание рукописи: 32 (57)**























































№9

1822 نچی یلدا 7/س

نارات آول جماعتی نڭ اوز آوللارنداغی
بالقلی سوئی کورشی آول روسلارنا آرینداغا
بیروله‌ری حقنده دوگوور یازووی

1822-нче елда 7 сентябрьдә
Нарат авыл җәмгыятенең үз авылларындагы балыклы суны күрше авыл урысларына арендага бирүләре хакында договор язуы.










1825 (1835) елда (Вятка губернасы)
[illegible] правлениесенең ясаклы [illegible]
Алабуга өязе Нарат авылы граж-
данарының үз авылының (җәмәгатьнең)
Көтмәс елгасындагы һәм
җирендәге күлләрдән балык аудагы
(тотып) файдалану өчен Сарапул өязе
Мостовое авылының русларына
– Мирон Григорий улына һәм Осип улына
арендага бирүләре һәм шуның шарт-
лары хакында язылган приговорның
нөсхәсе.
Саны – 1 дана
Күләме – 1 кәгазь.
Кул куючылар: 1) авыл выборы Сагындык
Колмәт улы; 2) Сәйфулла Сәйд Кол улы,
3) Ильяс Сәйд Кол улы; 4) Тимершаh
Рәфикъ улы; 5) Габделлатиф Юлдаш
улы, 6) Габдулла Хәмзә улы; 7) Бикбау
Пулат улы.

Искәрмә: Сәйфулла Сәйд-Кол улы минем
туган әнкәм Шәрифә бинте Нигъмәтулла
бине Сәйфулла бине Сәйд-Кол, бин Айт Кол
бин Кадрач бине **Зәйтай** кең иң якын бабасы
минем прадед – икенче буын бабам була.
З. М.

# II. Факсимиле документов, относящихся к ʻАбд ал-Джамилю Максудову (1832–1925)

**ИЯЛИ, Ф. 32. Папка 2**

























1251
1835




1834



## I. Факсимиле документов, относящихся к ʿАбд ас-Саттару б. Суендуку (1792–1870)

**ВС ОРРК НБ КФУ, 287Д**



*Редактор*
Е.С. Борисова

*Дизайн, подготовка к печати*
Д.Н. Залялетдинов

*Верстка*
Л.К. Залялетдинова

*Корректор*
Н.Н. Грибенюк

*Корректор татарских текстов*
Фирая Муратова